# ШУРА

№ 43
2024



2007114582253

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ШУРА

№ 43

2024



ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Рәгаиб кичәсе — җир йөзендә күркәм никах туган көн . . . . . . 14
Рамазан аена әзерлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Бүгенге көндә финанс гыйлемен өйрәнүнең әһәмияте . . . . . . 26
Иң хәерле мирас — тәрбия . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Төшенкелек — Аллаһы Тәгаләгә карата канәгатьсезлекме? . . . . 39
Аллаһы Тәгаләнең Әл-Гафур исеме . . . . . . . . . . . . . . 44
Госман радыяллаһу ганһе — оялчанлык үрнәге . . . . . . . . . 54
Рамазан ае фазыйләте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Хәдичә радыяллаһу ганһә — яхшы хатын-кыз үрнәге . . . . . . 63
Ләйләтел-Кадер — Рамазанның асыл кичләренең берсе . . . . . . 70
«Интернеттан фәтва алма!» . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Монафикълык һәрвакыт ачык булмаска мөмкин . . . . . . . . . . 84
Рамазан ае белән саубуллашу . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы . . . . . . . . . . . 93
Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . . . 95
Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . . . . . . . 97
Ураза гаете вәгазе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Сентябрь–Ноябрь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Казан,
Габдулла Тукай урамы, 38нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Исламия Хәбибрахманова

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ильяс Гарифуллин

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Тышлыкның 1нче битендә Кыя гөмбәзе мәчете сурәтләнгән, 2нче ягында гарәпчә «Рамазан мөбарәк» дип язылган.
Olexstudio // elements.envato.com/ru/beautiful-mosque-JUPUTDG
Tasnim Ahmad //shutterstock.com/ru/image-vector/ramadan-mubarak-arabic-calligraphy-greeting-card-1054208579

**«ШУРА» дини альманах, № 43** **12+**

январь–март 2024
җөмәдәл-ахыр–рамазан 1445

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 12.12.2023
Чыгу көне: 27.12.2023


*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*


*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*


*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*


**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللهِ ❁ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ ❁ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ ❁ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ ❁ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ❁ دَاعِينَا إِلَى اللهِ ❁ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ ❁ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ ❁ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ ❁ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ ❁ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ❁ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ❁ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ ❁ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ ❁

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ:

________________________________ ❁

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

____________________________________________ ❁

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ
تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞
أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسْلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞
اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ
الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ
وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ
عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:
إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞
اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ
إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا
بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәә-нә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү'миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ________________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге до-ганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәрраахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүүн. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмас-сыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ______________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгеләү.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*12нче гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 1нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Рәгаиб кичәсе — җир йөзендә күркәм никах туган көн

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә. Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез булса иде.

Аллаһы Тәгалә барча мәхлукларны парлы итеп яратты. Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай дип әйтә:

وَخَلَقْنَاكُمْ أَزْوَاجًا

**«Дәхи, сезне парлы** [ирле-хатынлы] **итеп халык кылдык».**

«Набә / Хәбәр», 78:8

Кояш белән ай, җир белән күк, ут белән су, җәннәт белән җәһәннәм — барысы да парлы. Кошлар, хайваннар дөньясында да ир һәм хатын җенесләре бар. Атабыз Адәм галәйһиссәламне яратканнан соң, Аллаһы Тәгалә аның кабыргасыннан Хавва радыяллаһу ганһәне ярата. Шул вакыттан бирле ир-ат белән хатын-кыз пар булып, гаилә булып яши. Ислам дине гаиләне нык саклый. Гаилә — ул калкан. Ә гаиләнең башлангычы исә — никах. Шәригатебез ир-ат белән хатын-кызның никахсыз мөнәсәбәтләрен катгый тыя:

وَلَا تَقْرَبُوا الزِّنَىٰ ۖ إِنَّهُ كَانَ فَاحِشَةً وَسَاءَ سَبِيلًا

**«Зинага якын да бармагыз, аның сәбәпләреннән дә ерак булыгыз, чөнки ул пычрак эш вә бик яман юлдыр».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

Никах — Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте. Һәм Раҗәб аеның беренче атнакиченә туры килә торган Рәгаиб кичәсе безгә шул хакта искә төшерә. Раҗәб ае быел 11нче гыйнвар көнне ахшамнан соң башлана.

«Рәгаиб» дигән сүз гарәп телендәге «рәгабә» фигыленнән алынган, ягъни «нәрсәнедер теләү, шул теләгәнеңә ирешү өчен тырышу» мәгънәсен бирә. Шәргый яктан караганда, бу расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе белән әнисе никахлашкан көн. Ягъни бу — Пәйгамбәребезнең әнисе Әминә белән әтисе Габдуллага никах укылган һәм алар, ир белән хатын булып, Әминә безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә авырга узган вакыт.

Күп кеше шушы кичәдә нишләргә дигән сорау бирә. Догада булыйк, намаз укыйк, садака бирик, җәмәгать. Гомумән, бер көнгә дә гыйбадәтләребезне киметмик. Аеруча шушындый мөбарәк кичәләрдә нәфел гыйбадәтләребезне арттырыйк. Аллаһы Тәгалә каршында иң сөекле гыйбадәт — кыска, әмма дәвамлы булганы.

Шуны да искә алыйк — Рәгаиб кичәсе раҗәб аеның беренче атнакиченә туры килә, ягъни пәнҗешәмбедән җомгага каршы кич була. Быел ул милади буенча, иншәАллаһ, 11нче гыйнвардан 12сенә туры килә. Илебездә бу көн рәсми рәвештә ял булып санала. Димәк, пәнҗешәмбе уразага кереп була. Нәфел, өстәмә ураза өчен иң хәерле көннәр булып дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе санала. Кич, кояш баегач, фарыз намазларыннан соң нәфел намазларын да укырга була. Төнге тәһәҗҗүд намазлары аеруча саваплы санала. Икенче көнне госелләнеп, җомга намазына барасыз. Ялны файдалы, саваплы үткәрү өчен бу бик яхшы форсат.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм раҗәб аенда уразаларын күбәйтә иде. Хәдис-шәрифләрендә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Раҗәб — ул утырту ае, шәгъбан — ул су сибү ае. Аннан соң килә торган Рамазан — уңышны җыю ае. Раҗәб ае җитте икән, без Рамазан-шәриф аена якынлашабыз. Димәк, Рамазанга инде ныгытып әзерләнү кирәк», — дип әйткән.

Рәгаиб кичәсеннән без нинди дәрес-гыйбрәт алырга тиеш? Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы Габдулла бай нәселдән, затлы, белемле егет булган. Әнисе Әминә дә күркәм, матур нәселдән. Алар Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән никахлашканнар. Без, шушы мәчетләрдә утыручы ир-атлар, — гаилә башлыклары, хатын-кызлар — йорт учагын саклаучылар, балаларыбызны никахка әзерлибезме? Үзебезгә иң элек шушы сорауны бирик әле. Кызыбыз йә улыбыз укырга дип шәһәргә китеп, күпмедер вакыттан кайтып төшә дә: «Әтием, әнием, менә бу минем булачак ирем яки хатыным», — дип, кисәк кенә хәбәр бирсә? Шунда гына, аһ-ваһ килеп, мулла табырга, никахка әзерләнергә тотынабызмы? Аллаһы сакласын, никахка кадәр үк балага узган очраклар да бар бит. Никахларга барабыз, ә килен инде бала көтә, шуны мулладан ничек яшерик икән дип тырышалар. Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын.

Монысы беренче мәсьәлә. «Әйе, без балаларыбызны никахка әзерлибез», — дип җавап бирсәк, сезгә икенче сорауны бирәм: без аларны кайсы вакыттан алып никахка әзерлибез? Мәктәптәнме? Әллә шул кызыбыз яки улыбыз университет-институтка киткән чакта гынамы? Нинди сүзләр белән әзерлибез? Үзебезнең милләттән мөселман булсын дибезме?

Безгә, хәзрәтләргә көн саен диярлек әти-әниләр килә дә: «Менә бит, хәзрәт, егет тә яхшы, әти-әнисе дә бик тәрбияле, ләкин безнең милләттән, безнең диннән түгел, нишлик?» — дип зар елый. Хөрмәтле әти-әниләр! Балаларыбызны никахка әзерләү — безнең бурыч! Телибезме, теләмибезме — без моны үтәргә тиеш. «Хәзрәт, нишлик инде, башка милләттән, башка

диннән; никахсыз яшиләр, никахсыз балага узганнар», — дип елап киләбез икән, димәк, без, әти-әниләр буларак, үз вазифабызны үтәмәгәнбез. Рәгаиб кичәсе шуның белән кыйммәтле: Габдулла белән Әминәне ничек итеп тәрбияләделәр, ничек итеп никахка әзерләделәр, ничек итеп никахландырдылар — бу безнең өчен үрнәк, искә төшерү. Без дә шулай итәргә тиеш: ул үстерәбез икән, аны ир-ат итеп тәрбиялик, якын-тирәбездә, дусларыбыз-танышларыбызда кайсыларында кыз үстерәләр — шуларны өйрәник. Нәселе, җиде буыннары нинди — тикшерик. Нәсел шәҗәрәсе дип күпме авыз корытабыз, ул бит матур агач кына түгел. Ул — нәселнең тарихы. Кемнәр булганнар, нинди булганнар — өйрәник, белик. Кыз үстерәбез икән — әдәпле, әхлаклы, тәртипле, иманлы, чын мөслимә булырлык итеп тәрбиялик. Балаларыбызны кечкенә чакларыннан ук дөрес итеп үстерик.

Рәгаиб кичәсе безгә нинди дәрес бирә? Никахтан соң күп вакыт та үтми, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе сәфәргә чыккач, вафат була. Бала дөньяга ятим булып туа. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бабасы, Габдулланың әтисе киленне беркая да куып җибәрми: «Баланы табасың, сине карыйбыз, баланы тәрбиялибез», — дип әйтә. Ул вакытта гарәп кабиләләрендә гадәтләр кырыс булган. Ләкин бу гаиләдә берәү дә киленне куып чыгармый. Бала тугач, Кәгъбәтуллаһ янына алып барып, бабасы аңа Мөхәммәд дип исем куша. Рәгаиб кичәсенең безгә искәртә торган тагын бер мәсьәләсе: без балабызга хәерле, матур, мәгънәле исем сайларга тиеш. Балаларыбызга да шуны өйрәтергә тиешбез.

Яңа туган сабыйларны мәчетләргә алып киләләр: нинди генә исемнәр юк! Моннан тәүбә итү кирәк. Шушы Рәгаиб кичәсендә Аллаһы Тәгаләгә ялварыйк, оныкларыбыз, аларның балалары һәм нәселебезнең киләсе буын дәвамчылары хәерле исемнәр йөртсен, әдәпле-әхлаклы, тәрбияле булсын, дип сорыйк. Раббыбыз әле никахлашмаган яшьләргә хәерле ирләр, хатыннар бирсен.

Рәгаиб кичәсе безгә гаилә тәртипләрен күрсәтә торган кичә. Габдулла белән Әминәнең никахлашуы, шушы никахтан Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тууы, аның хатыннары белән ни рәвешле никахлашуы, гаиләдә мөгамәлә кору рәвеше — болар барысы да мөселманнар өчен үрнәк булып тора. Без алардан өйрәнеп, аны үз балаларыбызга да җиткерергә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә имин тормыш, бәрәкәтле гомер бирсә иде. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*
*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*19нчы гыйнвар вәгазе,*

*рәҗәб аеның 8нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Рамазан аена әзерлек

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле мөэмин-мөселман кардәшләр, әлхәмдүлилләһ, һәрберебезне Аллаһы Сөбеханә вә Тәгалә янә Үзенең йортында җомга көнендә, иң хәерле көнендә фарыз гамәленә, җомга намазын укырга җыйды.

Йә Раббым! Ике җомга арасында кылган гамәлләребезне Үзең кабул әйләп, кимчелекләребезне, белеп һәм белмичә кылган, олы һәм кече гөнаһларыбызны Үзеңнең рәхмәтең белән гафу әйлә.

Әлхәмдүлилләһ, җәмәгать, мөбарәк изге Рамазан Шәриф ае җитәргә ике айдан кимрәк вакыт калып бара. Әлхәмдүлилләһ дип әйтәбез, чөнки адәм баласының бу дөньяга килү максатын истән чыгармаска кирәк. Аллаһы Тәгалә бу дөньяга безне йорт салып, ашап, эчеп, йоклау өчен, баю өчен, киенер өчен яратмады! Кешегә Аллаһы Тәгалә берничә дистә ел гомер бирә һәм Үзе үк Коръәндә нигә барлыкка китерелүебезне аңлатып китә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яралттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Ягъни, Аллаһы Тәгалә безне бары тик Аңа гыйбадәт кылсыннар, Аны искә алсыннар, Ул кушканнарны үтәсеннәр һәм Ул тыйганнардан тыелсыннар

өчен дөньяга китерде. Гыйбадәт кылу максаты белән яшәгән вакытта, адәм баласы, һичшиксез, уңышка ирешәчәк.

Белгәнебезчә, бик күпләребез машина йөртә, кемдер очкыч, поезд, теплоход белән сәяхәт кыла, кемгәдер көн саен диярлек автобус кебек җәмәгать транспортында йөрергә туры килә. Әйтик, кеше әле генә өр-яңа машина сатып алган ди. Күз алдына китерегез, чит ил машинасы булса бигрәк тә, анда 10 яки 15 мең чакрым йөрдеңме, аңа техник хезмәт күрсәтергә, ягъни тикшерергә алып керергә кирәк. Очкыч белән дә шул ук хәл: фәлән кадәр сәгать очтымы, аны ангарга кайтартып, тиешле өлешләрен алыштырырга, майлыйсы җирен майларга, ватылган-искергән җирләрен ремонтларга кирәк. Теплоходлар да фәлән кадәр чакрым үткәннән соң гаваньга кайтырга тиеш. Кайтармасагыз да була, әлбәттә, ләкин бу очракта гарантия калмый, бөтен җаваплылык үз өстегезгә төшә. Әгәр тиешле вакытта теплоходны тикшермәсәгез, диңгез уртасында аңа бер хәл булса, гаеп үзегездә. Очкыч белән һавада берәр бәла-каза килеп чыкса да, кемне гаепләргә? Әйтелгән техник таләпләрне үтәмәгән өчен гаеп сездә, вакытында карап-тикшереп торырга кирәк иде. Көн-төн юлда йөргән машинаны да, «әй, йөреп тора бит әле», дип кул селтәп, вакытында тикшертмәсәгез, берәр хәл булып, Аллаһы сакласын, кемнеңдер тормышы өзелсә, янә гаеп үзегездә була. Шулай итеп, машина булсынмы ул, башка төр транспортмы, аны тиешле вакытта тикшертеп, яңартып, ремонтлап, алыштырып торырга кирәк. Гәрчә әлеге транспорт төрләренең максаты кешене бер урыннан икенче урынга илтү генә булса да, һәрнәрсәнең вакыты бар, механизмнар туза, искерә, ул мәңгелек түгел. Шул ук вакытта, вакытында аңа тиешле игътибар биреп, кайгыртып торсаң, ул озак еллар дәвамында сине сөендереп, исән-имин эшләп торуы ихтимал.

Адәм баласы да шулай ук: ел дәвамында, 11 ай эчендә аның калебе туза, искерә, тәне ялыга. Кем беләндер әрләшә дә, гайбәтен дә сөйли, ачуланыша, ялганын да ычкындыра, хатасын да кыла, гөнаһ капчыгы да тула башлый. Беребез дә фәрештә түгел, иманыбызны аларныкы кебек пакь-чиста саклап

тота алмыйбыз шул. Кемгәдер катырак та әйтеп ташлыйбыз; телибезме-юкмы, кемнедер рәнҗеткәнебез дә булырга мөмкин; намазларны вакытында үтәмәгән очраклар да була — ихтыяр көче җитеп бетми, нәфес өстенлек ала. Ләкин Аллаһы Тәгалә безгә Рамазан аен бүләк иткән. Безнең иманыбыз һәм тәнебез өчен Рамазан ае яңару, тикшеренү, чистарыну, пакьләнү, көч җыю вакыты: ул ангар яки гавань ролен үти.

Әгәр дә мөселман кешесе шушы утыз көн буена үзен яңартмаса, аннан соң киләсе тормышында югалырга һәм тугры юлдан читләшергә мөмкин. Шуңа күрә мин менә бу сүзләремне әйтәм: ел буена җыелган пычраклардан арыну вакыты җитте.

Кайвакыт күп кенә кешеләрдән: «Уразага керергә куркабыз, сәхәрдән ахшамга кадәр ач торуы авыр», — дигән сүзләр ишетергә туры килә. Шайтан алдан ук хәстәрен күрә: мөселманнарның күңеленә коткы сала! Югыйсә, болай да гөнаһларыбыз күп, инде шул Рамазаннан да колак кагыйкмы?!»

Уразага куркып түгел, шайтан коткысыннан арынып, әлхәмдүлилләһ, чистарып чыгам, дип керергә кирәк. Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән, шушы изге ай дәвамында без пакьләнәбез, калебләребезне төзәтәбез, тәнебез, малыбыз һәм йөрәгебезне гөнаһлардан арындырабыз.

Рамазан ае 4 матдәңне чистарта: җан, тән, мал һәм калеб. Шуңа да без бу айны шулкадәр көтеп алабыз, аның өстенлекләренә ирешергә телибез.

Рамазан аеның фазыйләтләре бихисап. Беренчедән, шушы мөбарәк шәриф айда Коръәни Кәрим иңдерелде. Димәк, Рамазан — ул чистарыну ае гына түгел, Коръән ае да: Коръәнгә  мәхәббәте булган, Коръәнне хөрмәт иткән кешеләр Рамазан аенда үзләре дә хөрмәтле булалар. Бу айда Коръәнне күбрәк укырга тырышырга кирәк. Булдыра алганда, хәтем чыгарга, йә булмаса, белгән сүрәләрне булса да кабатларга, тәфсирләре белән укып, мәгънәсенә төшенергә омтылырга кирәк.

Икенчедән, Рамазан Шәриф аенда мең айдан да хәерлерәк булган мөбарәк Кадер кичәсе бар:

لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ

**«Кадер кичәсе** [Кадер кичәсе булмаган] **мең айдан да хәерлерәк.** [Шул сәбәпле, аңарда кылынган изге гамәл сиксән өч ел да дүрт ай буена бертуктаусыз кылынган гамәлгә тиң генә түгел, аннан да фазыйләтлерәк]**».**

«Әл-Кадр / Кадер киче», 97:3

Мең айга караганда хәерлерәк, ә мең ай, үз чиратында, 83 елга туры килә. 83 ел кешенең гомере, шушы кичәдә ураза тотып килеп, бер Кадер кичендә бер дога кылсагыз, гомер буе кылган гыйбадәттән әҗер-савап алырсыз, иншәАллаһ.

Өченчедән, Рамазан Шәриф ае малларыбызны пакьли. Күз алдына китерегез: без, гадәттә, төркем-төркем яшибез, ләкин күпләрнең ел дәвамында гына түгел, гомере буена да бер фәкыйрь бәндә белән бер өстәл артына утырып ашаганы, махсус аны эзләп табып хәлен сорашканы юк. Ник дигәндә, әйләнә-тирәсендә күбрәк бай һәм хәлле кешеләр. Ул аңа кунакка бара, аның янына килә, аның белән эшли, аңа шалтырата-язышa, дуслаша, чөнки аның белән эш алып бара. Шул рәвешле 11 аен яшәдек ди, ләкин, җәмәгать, җәмгыятьтә безгә бер тиене белән дә файда китерә алмаган мескен-фәкыйрь бәндәләр дә бар бит. Безгә алардан бу дөньяда файда тимәсә дә, без аларга шушы тормышыбызда ярдәм итә алабыз, файда китерә алабыз, ә алар, үз чиратында, безгә Ахирәтебездә файда китерерләр, иншәАллаһ. Югыйсә, шул фәкыйрь бәндәдә синең хәлле дустыңда булмаган олуг бер файда бар: ул синең малыңны пакьли ала. Шәт, аның калебе синекеннән яки башка берәүнекеннән чистарактыр, синең өчен ихлас дога кылып, Аллаһы Тәгалә сиңа тиешле бәла-казадан сине йолып калыр. Рамазан аенда булса да, шушы мөмкинлекне кулдан ычкындырмасак иде.

Аллаһы Тәгалә Рамазан аенда йөзләребезне шушы фәкыйрьләргә юнәлтә. Ел дәвамында тук яшәп, без ачлыкның ни икәнен белми яшибез, шөкер. Ләкин Рамазан аенда гына түгел, ел буе ачлы-туклы яшәгән кешеләр

барын да онытмаска кирәк. Алар өчен вакытында зәкятләребезне чыгарсак иде, 2,5 процентны кызганмасак иде. Рамазан аенда булса да, әйләнә-тирәгезгә ныграк игътибар бирсәк иде. Бәлки үз тирәбездә үк мохтаҗ кешеләр бардыр: аларның ихтыяҗларын без күпмедер күләмдә хәл итә ала, йә булмаса, хәленә кереп, аңларга тырышып, хәл-әхвәлен булса да сорашсак иде.

Йосыф галәйһиссәлам җиде ел ачлык дәвамында Мисыр патшасы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Шул дәвердә ашлыкны тутырган һәм бүлгән вакытында Йосыф галәйһиссәлам җиде ел ураза тоткан. Әгәр дә ашасам, миннән сорап килгән фәкыйрьнең хәлен аңламас идем дип, ул ризыкны үзе ач килеш бүлгән, чөнки тук кеше ач кешенең хәлен аңлый алмый. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә Рамазан ае хакында Коръәндә болай дигән:

لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

**«...бәлки,** [Аллаһының газабыннан үзегезне коткарып] **саклана алырсыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:21

Карыныгыз бераз гына булса да ач торса, мескен-фәкыйрьләрнең хәлләрен аңлый башлыйсыз. Аллаһыга шөкер, бүген безнең сәламәтлегебез дә, ризыгыбыз да, мөмкинлекләребез дә бар. Исән-сау, йөгереп торабыз, акча эшли алабыз, теләгән әйберебезне сатып ала алабыз, ләкин күпләрнең мондый мөмкинлеге юк икәнен онытмаска кирәк. Берүк үзебезне алардан өстен дип уйлый күрмик, алар да түбән дәрәҗәле кешеләр түгел, ялкаулык сәбәпле акчасыз яшәмиләр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди:

لَا يَسْخَرْ قَوْمٌ مِّن قَوْمٍ عَسَى أَن يَكُونُوا خَيْرًا مِّنْهُمْ

**«Берәүләр икенче бер кешеләрне мыскыл итмәсен, кем белә, бәлки, алар болардан хәерлерәктер».**

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:11

Ягъни, түбән халык дип аларны мәсхәрә итмәгез, шәт, аларның калебләре чистарак булып, Аллаһы каршында алар сезгә караганда хәерлерәктер ди.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бай кеше җәннәткә фәкыйрь-мескеннән биш йөз елга соңрак керер», — дип әйткән. Фәкыйрь бәндә җәннәткә кереп киткәндә, бай кеше үз урынынннан кузгала алмыйча басып калыр, һәм шул рәвешле биш йөз ел көтәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ни өчен нәкъ менә биш йөз ел, дип сораган булганнар, чөнки аның бу дөньяда җыйган малын, аны кая сарыф итүен биш йөз ел дәвамында тикшерәчәкләр. Бу дөньяда рәхәттә, муллыкта яшәгән булсаң, Кыямәт көнендә әлеге нигъмәтләр өчен җавап тотарга туры киләчәк: каян керде һәм кая чыкты? Шуңа күрә Рамазан Шәриф ае малларыбызны да, тәнебезне дә пакьли.

Дүртенчедән, ураза тотып, тәравих намазларын укысак, алар йөрәкләребезне пакьли. Чистарынып, киләсе елны яңа көч белән үткәрер өчен, туры юлдан барыр өчен, Рамазан аеның безгә файдасы бик зур.

Әлбәттә, болар барысы да җиңел генә бирелми. Шуңа Рамазан аена, көне килеп җиткәч түгел, алдан әзерләнә башларга кирәк.

Аллаһы Тәгалә безгә газап һәм авырлык теләми, Үзенең рәхмәтен ирештерергә тели. Шуңа күрә күңелдә бер дә шик-шөбһә, курку, шайтан вәсвәсәсе булырга тиеш түгел. Әлхәмдүлилләһ, җиңеллек белән шушы көннәрдә үзебезнең уразаларыбызны тотарга Аллаһы Тәгалә насыйп әйләсен. Кылган гамәлләребезне кабул әйләп, киләчәк уразаларыбыз мөбарәк булып, шушы изге айларда да күрешеп, бер-беребез белән аралашып, тәравих намазларында күрешергә насыйп итсен, йә Раббым! Хәерле сәхәрләр, бәрәкәтле ифтарлар булса иде, йә Раббил-гааләмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Госманов,*

*Кукмара Үзәк мәчетенең икенче имамы*

*26нчы гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 15нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Бүгенге көндә финанс гыйлемен өйрәнүнең әһәмияте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, безне халык кылып, һәрдаим тәрбияләп, ризыкландырып һәм киендереп торучы Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булса иде. Мөхәммәд бине Габдулла — Аллаһының хак Расүле, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы, сөекле Пәйгамбәребез, остазыбыз — Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифләрен бирсә иде.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдән Мәдинә шәһәренә күченгәч, аның янына кешеләр килеп, шәһәр сәүдәгәрләре үлчәп сатканда харамлашкан дип зарландылар. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә әлеге аятьләрне иңдерде, һәм сәүдәгәрләр сатуларын төзәттеләр. Бу аятьләрдә Аллаһы алдап, киметеп яки кимчелекләрен яшереп сатучы сәүдәгәрләргә: «Сез бит Минем каршыма килеп басачаксыз», — дип аларны Кыямәт көненең хисабы белән кисәтте.

وَيْلٌ لِّلْمُطَفِّفِينَ ۞ الَّذِينَ إِذَا اكْتَالُوا عَلَى النَّاسِ يَسْتَوْفُونَ ۞ وَإِذَا كَالُوهُمْ أَو وَّزَنُوهُمْ يُخْسِرُونَ ۞ أَلَا يَظُنُّ أُولَٰئِكَ أَنَّهُم مَّبْعُوثُونَ ۞ لِيَوْمٍ عَظِيمٍ ۞ يَوْمَ يَقُومُ النَّاسُ لِرَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Киметеп үлчәүчеләргә ни үкенеч! Алар** [үзләре өчен] **кешеләрдән үлчәткән вакытларында, тулысынча алалар. Ләкин аларга үлчәгәндә яки** [бизмәнгә салып үлчи торган нәрсәләрнең] **авырлыгын билгеләгәндә, киметәләр. Алар терелтеләчәк дип уйламыйлармы? Бөек көн өчен. Бөтен кешеләрнең галәмнәр Раббысы** [булган Аллаһы Тәгаләнең хөкеме һәм җәзасы] **өчен** [каберләреннән] **кубарылган көнне** [күз уңында тотам]**».**

«Әл-Мутаффифин / Киметеп үлчәүчеләр», 83:1-6

Хөрмәтле җәмәгать, бу аятьләр сәүдәгәрләр сәбәпле, алар өчен иңсә дә, шул ук вакытта, бу аятьләр безгә, барыбызга да кисәтү булып тора. Без дә вакыт-вакыт нидер сатабыз, кемгәдер ниндидер хезмәтләр күрсәтәбез. Әйтик, үзебезнең машинабызны сатканда, ватык җирләрен күрсәтәсебез килми, аларны яшерәбез, машинабызны мактыйбыз. Шулай итеп, кыйбаткарак сату өчен гөнаһка кереп, «шөкер, миннән китте, алучы теләсә нишләсен», дип саткан акчаларыбызның бәрәкәтен югалтабыз. Әмма бу явызлык үзебезгә үк әйләнеп кайтасын аңламыйбыз.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм базарда йөргәндә бодай сатучы янында тукталды. Капчыктагы бодайга кулын тыккач, ул анда дым сизде һәм сатучыга: «Нәрсә бу, әй, ризык сатучы?» — дип сорау бирде. Ул: «Бодаем яңгырга эләккән иде шул, әй, Аллаһының Расүле», — дип җавап бирде. Шунда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Алай булгач, нигә син юеше өстенә корысын салдың соң? Кем харамлаша, шул бездән түгел», — диде. Адәм баласы, шулай шул, кеше, алдап сатсам, керем күбрәк булыр дип уйлый, әмма ризык һәм бәрәкәт сәүдәдән түгел, ә Аллаһыдан икәнен аңламый. Әгәр Аллаһы бәрәкәт бирмәсә, бернинди сәүдә дә алга китә алмаячак. Бернинди ялган, харамлашу да кешегә бәрәкәт, шатлык китерә алмаячак. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр сәүдә кылучылар тугры булсалар һәм товарның гаебен әйтеп сатсалар, сәүдәләре бәрәкәтле булыр. Әгәр алдасалар һәм яшерсәләр, бәрәкәте юк ителер», — дип әйтте.

Сәүдә — ул ике як та отышта калырга тиеш булган килешү. Сатып алучы үзенә кирәкле нәрсәгә ия булганы өчен, сатучы исә, товары сатылып, эше алга баруы өчен шатлана. Шушы гаделлек бозылмасын өчен, галимнәр Коръәнгә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә таянып, тырышлык куеп, хөкемнәр чыгардылар, кагыйдәләр билгеләделәр, шулай итеп, зур бер фән пәйдә булды. Анда сәүдә килешүләрен ничек төзергә, аларны ничек бозарга икәнен аңлаттылар. Анда сәүдә кылучылар, ике як та гөнаһка кермәсен өчен, нинди сәүдә төрләре харам, кайсылары бозык яки мәкруһ икәннәрен билгеләп куйдылар. Алынган товар кимчелекле булса, гаебе килеп чыкса, мәсьәләне ничек хәл итәргә, моны ничек исбат итәргә икәнен күрсәттеләр. Товарны әҗәткә сату мәсьәләләрен, боларны һәм башка бик күп мәсьәләләрне аңлаттылар. Бу кагыйдәләр, хөкемнәр барысы да бер як икенче якка зыян китермәсен, сәүдә гадел булсын, ике як та отышта калсын өчен куелган. Сатучының да, сатып алучының да хаклары бар. Бу хаклар бозылырга тиеш түгел. Ислам шәригате исә болар сагында тора. Сәүдә итүчеләрдә бу белемнәр булырга тиеш.

## Бәяләрнең артуы

Хәзерге көндә безнең һәрберебезне бәяләрнең артуы борчый. Ашамлыкларга, төзелеш материалларына, бензинга гел бәяләр артып тора. Бәяләрнең артуы элек тә булган, хәзер дә шулай. Галимнәр әйтүенчә, Аллаһының «Әл-Мүсәггир» дигән исеме бар. Мәгънәсе: Ул һәрнәрсәнең үз кыйммәтен билгеләүче, бәя куючы. Әнәс бине Мәлик хәбәр итүе буенча, бервакыт базарда бәяләр кыйммәтләнгән. Кешеләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Әй Аллаһының Расүле! Безнең өчен базар бәяләрен билгелә әле», — диделәр. Ул: «Дөреслектә, бәяләрне билгеләүче (Әл-Мүсәггир) — ул Аллаһы Тәгалә, Ул чикләүче дә, киңәйтүче дә, ризыкландыручы да. Мин Раббым каршына килеп баскач, сезнең берегез дә миңа килеп, миннән кан хакын яки мал хакын таләп итмәссез дип өметләнәм», — диде.

Базардагы бәяләр үзләре табигый рәвештә көйләнә. Яңгырлар явып, уңыш күп булса, бәяләр төшә, корылык булып, уңыш аз булса, бәяләр күтәрелә. Шулай ук сугышлар, фетнәләр башланса, ризык килү кими һәм бәяләр табигый рәвештә күтәрелә. Шулай ук, хәзерге вакытта бәяләр бензинга һәм долларга карап үзгәрәләр. Нефть бәясе артса, бензинга бәяләр арта, бензинга бәяләр артса, башка товарларга да бәяләр артачак. Базар бәяләре шулай үзләре көйләнә, әмма бәяләрне ясалма рәвештә күтәрү (карабодайга һәм тозга арттырган кебек) Ислам шәригатендә тыела.

## Хәерле кәсеп

Совет заманнарында, алып-сатарларны «спекулянт» дип гаепләп, җәзага тарта торган булдылар. Бер урыннан алып, икенче урында сату зур җинаять булып саналды. Әмма Ислам кануннары буенча сатып алган әйбер сатып алучының шәхси милке булып санала. Ул бу милкен үзенә кулланырга, кемгәдер бүләк итәргә яки үзе теләгән бәягә, үзе теләгән кешегә сатарга хакы бар. Сәүдәгәрләр сәбәпле төрле илләрдән күп төрле товарлар кайта, күп төрле кибетләр ачыла һәм кеше, ни теләсә, шуны сатып ала. Бу элек тә шулай булган. Кәрваннар бер континенттан икенчесенә товарлар, ризыклар ташыганнар. Мәсәлән, бездәге «чынаяк» дигән сүз «кытай савыты» дип тәрҗемә ителә. Димәк, аларны Кытайдан китергәннәр; яки элекке Болгар дәүләтендә бик сыйфатлы читекләр ясаганнар. Чит илләрдә бу читекләргә «болгари» дип әйткәннәр.

Борынгы заманнардан ук берни дә үсми торган, ком һәм ташлы чүл уртасында урнашкан Мәккә шәһәре халкы да күп очракта бары тик сәүдә итү сәбәпле генә көн күргәннәр. Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәндә аларның кышын һәм җәен бергәләшеп сәүдә сәфәрләрендә йөрүләрен искә ала:

لِإِيلَافِ قُرَيْشٍ ۞ إِيلَافِهِمْ رِحْلَةَ الشِّتَاءِ وَالصَّيْفِ ۞ فَلْيَعْبُدُوا رَبَّ هَٰذَا الْبَيْتِ ۞ الَّذِي أَطْعَمَهُم مِّن جُوعٍ وَآمَنَهُم مِّنْ خَوْفٍ

**«**[Раббылары] **Корәешне** [һәм Мәккә халкын Әбрәһәнең филле гаскәреннән] **берләштерер өчен. Аларны кыш** [Йәмәнгә] **һәм җәй** [Шамдагы сәүдә сәфәрләрендә] **берләштерер өчен** [саклады]**. Шушы Бәйтнең Раббысына гыйбадәт кылсыннар** [Кәгъбәтулланы фил гаскәреннән һәм бөтен куркынычлардан Ул гына саклады]**.** [Үләксә ашарга мохтаҗ иткән] **Ачлыктан соң аларны ашаткан,** [махау һәм ваба кебек йогышлы авырулар кебек] **куркудан аларны имин иткән Затка** [гыйбадәт кылсыннар]**».**

«Кураеш / Кораешләр», 106:1–4

Безнең динебездә сәүдә кылу мактаулы кәсепләрдән санала. Сәүдәгәрләр сәбәпле илләргә, шәһәрләргә күп төрле ризыклар һәм товарлар китерелә. Без, сатып алып, сәүдәгәрләрне баетабыз дип уйларга кирәк түгел, ә без үзебезгә кирәкле нәрсәне ала алдык, дип шөкер итәргә кирәк. Сәүдәгәрләр булмаса, халыкның тормышы бик авыр булыр иде. Икенчедән, дөрес сәүдә итүе белән сәүдәгәрнең Аллаһы каршында дәрәҗәсе күтәрелә, аның эше мактаулы эшкә әйләнә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тугры, әманәтле сәүдәгәр Кыямәт көнендә пәйгамбәрләр, изгеләр һәм шаһитләр белән бергә булыр», — диде. Әйе, әгәр алар сатып алучыларны алдамыйча, аларга хыянәт кылмыйча, дөрес сәүдә кылсалар, аларга шундый югары дәрәҗә булачак. Шул вакытта Аллаһының ризалыгы да, бәрәкәт тә булачак.

Сәүдә сүзе эченә төрле хезмәт күрсәтүләр дә, нидер ясап, җитештереп сатулар да керәдер. Аллаһы әйтте:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَأْكُلُوا أَمْوَالَكُم بَيْنَكُم بِالْبَاطِلِ إِلَّا أَن تَكُونَ تِجَارَةً عَن تَرَاضٍ مِّنكُمْ

**«Ий, иман китерүчеләр! Үзара килешенгән** [һәм динебез тарафыннан рөхсәт ителгән] **сәүдә юлы белән булмаса,** [шәригать кушмаган риба, отышлы уен һәм талау кебек] **бозыклык белән арагызда** [берберегезнеке булган] **малларыгызны ашамагыз...»**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:29

Дин кардәшләребез, хөрмәтле мөселманнар! Ризыгыбыз киң, мул, бәрәкәтле булуын теләсәк, гөнаһка, кеше хакына кермичә, сәүдә эшендә дә зирәклек, тәкъвалык күрсәтеп яшәргә насыйп булсын.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*

*Балтач Үзәк мәчетенең имамы*

*2нче февраль вәгазе,*
*раҗәб аеның 22нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Иң хәерле мирас — тәрбия

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, шул галәмнәргә рәхмәтен һәрдаим ирештереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә шөкерләребез һәм зикерләребез булсын, һәм дә Аның Расүле, иң күркәм әхлак мисалы булган остазыбыз Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Хөрмәтле җәмәгать, тормыш җиңел нәрсә түгел. Тормышның һәр чоры безгә баскычны хәтерләтә: төшәргә дә, күтәрелергә дә туры килә. «Аллаһыга шөкер, уңышка, дәрәҗәгә ирештек», — дип сөенәсең, хәтта горурланасың. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бу уңышны, дәрәҗәне кайдан бирә, ул кайдан килә?

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә әмер бирә, васыять кыла:

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ إِحْسَانًا ۖ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ كُرْهًا وَوَضَعَتْهُ كُرْهًا ۖ وَحَمْلُهُ وَفِصَالُهُ ثَلَاثُونَ شَهْرًا ۚ حَتَّىٰ إِذَا بَلَغَ أَشُدَّهُ وَبَلَغَ أَرْبَعِينَ سَنَةً قَالَ رَبِّ أَوْزِعْنِي أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ الَّتِي أَنْعَمْتَ عَلَيَّ وَعَلَىٰ وَالِدَيَّ وَأَنْ أَعْمَلَ صَالِحًا تَرْضَاهُ وَأَصْلِحْ لِي فِي ذُرِّيَّتِي ۖ إِنِّي تُبْتُ إِلَيْكَ وَإِنِّي مِنَ الْمُسْلِمِينَ

**«Без кешегә ата-анасына игелек күрсәтүне әмер иттек. Анасы аны мәшәкать белән** [тугыз ай карынында] **йөртте һәм аны авырлык белән тудырды. Аны йөртүе һәм** [имчәктән] **аеруы — утыз ай.**

**Нәтиҗәдә, ул** [бала яшәп] **куәтле чагына ирешкәч һәм** [шуннан соң] **кырык яшенә җиткәч: «Ий, Раббым! Миңа һәм ата-анама биргән** [сансыз] **нигъмәтеңә шөкер итүемне, Син разый булган изге гамәлләр эшләвемне миңа күндер. Минем өчен минем** [үземнән соңгы] **нәселемне изгеләрдән кыл. Һичшиксез, мин Сиңа тәүбә иттем һәм мин** [гамәлләрен сиңа тапшырган] **мөселманнарданмын», — диде».**

«Әл-Әхкаф / Ком таулары», 46:15

Сәгыйть бине Мәлик исемле әнисен бик яраткан бер сәхабә булган. Ул Ислам кабул иткәч, анасы аңа: «Син Исламнан чыкмыйча торып, мин ашамыйм-эчмим, юынмыйм», — дип шарт куйган, нәзер әйткән. Сәгыйть аңа катырак итеп: «Син теләсә нишлә, мин Исламнан чыкмыйм», — дип кырысрак җавап кайтарган. Шуннан соң Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә «Локман» сүрәсеннән аять иңдерә:

وَإِن جَاهَدَاكَ عَلَىٰٓ أَن تُشْرِكَ بِي مَا لَيْسَ لَكَ بِهِۦ عِلْمٌ فَلَا تُطِعْهُمَا ۖ وَصَاحِبْهُمَا فِي ٱلدُّنْيَا مَعْرُوفًا

**«Әмма ул икәү** [үзләре турында] **синең бернинди гыйлемең булмаган** [потлар һәм гаҗиз] **нәрсәләрне** [күрә торып] **Миңа ширек кылуың өчен сине көчли калсалар, аларга итагать итмә. Әмма дөньяда ул икәү белән** [дини һәм кешелек ягыннан] **яхшы күрелгән рәвештә бергә бул. Ләкин син** [ата-анаңның юлына түгел, тәүхид һәм ихлас белән] **Миңа юнәлгәннәрнең юлына ияр...»**

«Локман», 31:15

Галимнәр аңлатуынча, ата-ананы рәнҗетә, күңеленә тия торган юл белән түгел, ә йомшаклык белән аларга хөрмәт кыласың, шул ук вакытта тыңламыйсың да. Безнең өчен олы үрнәк — ул Ибраһим галәйһиссәлам. Әлеге пәйгамбәр турында, аның потларга табынучы атасына нинди мәрхәмәтле булуын Аллаһы Тәгалә Коръәндә дә искәртеп үтә.

Раббыбыз ананың атага караганда аерылып тора торган ролен күрсәтеп, болай диде:

أُمُّهُ وَهْنًا عَلَىٰ وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ

**«...Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән** [бу көчсезлек чоры авырга узуы белән башланып, нифасы беткәнче дәвам итә]**. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә.** [Боларның барысы өчен дә, иң элек, Яралтучың буларак] **Миңа һәм** [шуннан соң барлыклар арасыннан яралтылыш сәбәбең булган] **ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту — Миңа** [булачак]**».**

«Локман», 31:14

Ана кешегә ни өчен игелекле булырга кирәклекне Аллаһы Тәгалә шушы аять аркылы: «Анаң сине күтәргән, имезгән, җанын, җылылыгын биргән чоры утыз айга сузылды», — дип аңлата. Ни өчен Аллаһы Раббыбыз утыз ай: тугыз ай күтәрү һәм ике ел имезү дип әйтте?

Хөрмәтле җәмәгать, шушы урында хатын-кызның табигатенә, үзенчәлегенә тукталып китик. Корънәндә аерым «Хатыннар» сүрәсе бар, Раббыбыз анда хатыннар хакын кайгыртырга куша. Анда хатыннар темасын күтәргәч, Аллаһы Тәгалә ятим балалар турында әйтә:

وَآتُوا الْيَتَامَىٰ أَمْوَالَهُمْ ۖ وَلَا تَتَبَدَّلُوا الْخَبِيثَ بِالطَّيِّبِ ۖ وَلَا تَأْكُلُوا أَمْوَالَهُمْ إِلَىٰ أَمْوَالِكُمْ ۚ إِنَّهُ كَانَ حُوبًا كَبِيرًا ۝ وَإِنْ خِفْتُمْ أَلَّا تُقْسِطُوا فِي الْيَتَامَىٰ فَانكِحُوا مَا طَابَ لَكُم مِّنَ النِّسَاءِ مَثْنَىٰ وَثُلَاثَ وَرُبَاعَ

**«Ятимнәргә үз малларын бирегез. Пычрак булганын пакь булган белән алмаштырмагыз. Аларның малларын үз малларыгыз белән бергә** [хәләл-харамны кушып] **ашамагыз. Һичшиксез, бу** [рәвештә ятим малын ашавыгыз] **бик зур гөнаһ булды. Ятимнәргә** [өйләнергә ниятләп, аларга] **карата гадел була алмавыгыздан курыксагыз,**

**сезнең өчен хәләл булган хатыннарга — икегә, өчкә һәм дүрткә никахланыгыз...»**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:2-3

Әлеге хатыннарны алуның төп мәгънәсе — ул бала. Хатын-кыз баланың анасы буларак яктыртыла.

Хәдискә карасак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дурт кызы булган. Кызы Фатыйма тугач, мөшрикләр: «Синең кызлар, улың юк», — дип хурлап әйткәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул минем рәйхан гөлем (хуш исле чәчәгем), мин аны исним», — дип әйткән. Ул кыз балаларны бик яраткан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тагын бер хәдисендә: «Кем дә кем ике кыз баланы балигъ яшенә кадәр күркәм рәвештә тәрбияли, Кыямәт көнендә ул кеше минем белән бергә булыр», — дигән.

Бервакыт Гайшә радыяллаһу ганһә янына ике кызы белән бер хатын керә. Гайшә анабыз аңа хөрмә бирә, ләкин ул хатын, үзе ашамыйча, шушы ике кызына бүлеп бирә. Гайшә радыяллаһу ганһә бик гаҗәпләнеп, моны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйли, һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем кыз бала биреп сынала, аларга күркәмлек кыла икән, бу кыз балалар аңа Кыямәт көнендә уттан пәрдә булырлар», — дип әйткән. Монда кызларның дәрәҗәләре турында әйтелә. Җәмәгать, игътибар итик, монда сүз бала турында гына түгел, ә кыз бала турында бара! Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай үк: «Аллаһы Тәгалә сезгә әниләрне рәнҗетүне һәм кызларны тереләй күмүне харам кылды», — дип әйткән.

Мөхтәрәм җәмәгать, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә кыз балаларга аеруча игътибар итә.

Коръәнгә карасак, Аллаһы Тәгалә анда һәрбер нечкәлекләренә кадәр Ислам тарихында булган иң яхшы хатын-кызларның берсе — Мәрьям турында сөйли.

Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы әмере буенча Һаҗәр анабызны бала белән чүл уртасында калдырырга мәҗбүр була. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә Исмәгыйльнең аяк астыннан Зәм-Зәм суы чыгара. Җәмәгать, Һаҗәр анабыз аның пәйгамбәр буласын белгәнме? Юк, белмәгән.

Ә Муса галәйһиссәламнең әнисе Аллаһы Тәгаләнең әмере белән Мусаны сандыкка салып, суга агызып җибәргәндә аның пәйгамбәр икәнен белгәнме? Юк, белмәгән.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, һәр ананың баланы яратуы — бер төрле. Тәҗрибәләр нигезендә шуны гына әйтәләр: хатын-кыз нинди генә чибәр булмасын, аның иң көчле җинаяте — ул бала яратмау. Ә хатын-кызның иң көчле, күркәм сыйфаты — ул бала теләү, хатын-кызның бөеклеге — бала ярату.

Татарның бөек шагыйре Габдулла Тукайның анасы Бибимәмдүдә, шагыйрьгә 3 яшь тулгач, вафат була. 3 яшенә кадәр бу балага салган мәгълүмат, җылылык, ярату безнең хәзер «Тукайлы» булуга сәбәпче булган. Тукай гына түгел, имам Әхмәд, имам Әл-Бохари һәм башкалар да шулай ук. Җәмәгать, карап китсәк, зур-зур галимнәрнең ата-аналары алар бала чакта ук вафат булган, әмма аларны нәкъ тә галим итә торган кешеләр, сәбәпчеләр аларның аналары булган.

Бервакыт тәненең бер ягы гарип булган бала туа, анасы аңа: «Бу гариплегең белән физик эшләр эшли алмассың, гыйлемгә бар», — дип киңәш бирә. Бу бала олы яшькә җиткәч, Мәккәнең зур галименә әверелә. Ул — Гата бине Әби Рабаһ була. Кем сәбәпле? Ана сәбәпле!

Газиз дин кардәшләрем, шушы югарыда әйтелгән аятькә карасак, ананың балага салган мәхәббәте, баланы яратуы 40, 50 яшь тулгач ир-атның яки хатын-кызның рухи яктан ныклы шәхес булуына сәбәпче икән.

Кеше өйләнгән вакытта матурлыгына карап кызга өйләнә, әмма беренче баланы алып кайтканнан соң, ул хатын гына түгел, киләчәк буынны тәрбияләүче шәхескә әйләнә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен иң яраткан гамәл — ул никах. Ни өчен? Никах килешүендә сүз хатын

белән ирнең бер-берсен яратуы турында гына бармый, ә бу йорттагы киләсе 40–50 ел эчендә формалашачак шәхес турында да сүз бара.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 20, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһегә 18 яшь булганда, алар бергә Шамга сәфәргә баралар. Шушында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер агач янында туктый да, ял итәргә утыра. Агач янында бер монах була, Әбү Бәкер аның белән сөйләшеп китә. Әбү Бәкер аннан христиан дине турында сораша башлый. Шуннан соң теге монах: «Агач янында кем утыра?» — дип сорый, Әбү Бәкер: «Габделмоталлиб улы Габдулла улы Мөхәммәд», — ди. Тегесе: «Ул — пәйгамбәр! — ди. — Чөнки ул агач янында Гайсә галәйһиссәламнән кала башка кешенең утырганы юк иде, анда пәйгамбәр генә утыра», — дип әйтә. Шуннан соң, 18 яшеннән башлап, Әбү Бәкер Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне калдырмаган.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйткән: «Әбү Бәкер — әтисе, әнисе, үзе, хатыны һәм бөтен балалары пәйгамбәребезне күргән, сәхабәләр булган берләнбер кеше».

Кырык яшенә җиткән кеше уйлап караса, бөтен ирешкән уңышың синеке түгел, ә әниең рухият салган, әтиең юнәлеш, тәрбия биргәннең нәтиҗәсе икәнен аңлый.

Әниләрне тыңлау, аларның хәлен белү әнигә түгел, балага кирәк! Безне күтәргән, тапкан, тәрбияләгән вакытта булган барлык авырлыкларны без белмибез, шуңа күрә: «Раббым, Сиңа шөкер итәргә ярдәм бир миңа, киләчәктә Син миннән риза булырлык итеп яшәргә, гамәл кылырга ярдәм бир миңа, гаиләмне, нәселемне төзек, сәҗдә әһеле кыл», — дип сорыйбыз.

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга да безнең шәхес булып формалашуыбызда олы хезмәт куйган әти-әниләребезгә игелек кылырга насыйп әйләсә иде. Кечкенәдән алып, авыр вакытларыбызда безне тәрбияләгән, кеше иткән әти-әниләребезгә миһербанлы булсак иде. Аллаһы Раббыбыз безгә әти-әниләрнең кадерен белеп, балаларыбызның аналарының кадерен белеп,

киләчәктә безнең өчен догада була торган, бездән дә игелеклерәк, бездән дә артыграк сәҗдә әһеле, галимнәр була торган буыннар тәрбияләргә насыйп әйләсен. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рамил хәзрәт Бикбаев,*

*Балтач районының Үзәк мәчете имамы*

*9нчы февраль вәгазе,*

*ражәб аеның 29нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Төшенкелек — Аллаһы Тәгаләгә карата канәгатьсезлекме?

Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәс-сәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән остазыбыз, үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп кылган гыйбәдәтләребезне кабул кылсын. Атлап килгән һәрбер адымнарыбыз саен әҗер-савапларын насыйп итсен.

Хөрмәтле җәмәгать! Бүген без бүгенге көннең бер проблемасы булган төшенкелек, башкача әйтсәк, депрессия турында сөйләшеп китәрбез. Депрессия — ул кешенең эчке дөньясындагы тискәре халәт. Аның артык борчылу, курку хисләре, тормышка карата битарафлык, тынычсызлык, пессимизм, йокының һәм аппетитның бозылуы кебек билгеләре булырга мөмкин. Ислам дине аңлатуынча, мондый халәт барлыкка килүнең төп сәбәбе — иманның зәгыйфьлеге, ягъни Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, Аның чиксез рәхмәтенә, кодрәтенә, белеменә ышануның түбән дәрәҗәдә булуы. Шулай ук кешедә мондый халәт яшәү мәгънәсен белмәүдән, тормышта үз урынын тапмаганлыктан яки куйган максатына ирешә алмаганлыктан барлыкка килергә мөмкин. Гадәттә, кеше төрле тышкы факторлар һәм нәфесе аркасында

канәгатьсезлек белдерә башлый һәм, нәтиҗәдә, ул төшенкелеккә бирелә. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Үзегездән матди яктан өстенрәк булган кешеләргә түгел, ә түбәнрәк дәрәҗәдә булган кешеләргә игътибар итегез», — дип әйткән[1]. Бу хәдистән аңлашылганча, кешедә шөкер хисе югалмас, ризасызлык, көнчелек кебек тискәре сыйфатлардан сакланыр өчен, кеше һәрвакыт үзеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булган кешеләргә игътибар бирергә тиеш. Рухи яктан байрак, ягъни ихласлырак булган кешеләргә игътибар итү, алардан үрнәк алу бик мөһим.

Төшенкелек һәр кешедә, шул исәптән, мөселманда да була ала. Беркем дә хата-кимчелекләрдән азат түгел, ләкин мөселманга бу халәттән чыгарга күпкә җиңелрәк, чөнки аның иманы бар. Иман кешене күп кенә начар халәтләрдән саклый. Иманлы кешегә бу халәттән чыгуга Аллаһы Тәгаләнең Изге китабы Коръән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәте һәм олуг галимнәрнең, изгеләрнең мирасы ярдәм итә. Төшенкелеккә бирелгән кешегә динебез тарафыннан нинди киңәшләр бирергә кирәк соң?

Кайбер төшенкелеккә бирелгән кешеләр янында яхшы киңәш бирә ала торган якын дуслары, аларны тыңлый алырлык кардәшләре булмаска да мөмкин. Шуңа күрә динебез андый кешеләргә әхлаклы, тәкъва кешеләр белән дуслашырга, алар катнашындагы мәҗлесләргә барырга, алар белән аралашырга өнди. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөэмин — икенче мөэминнең көзгесе», — дип әйткән[2]. Изге, әхлаклы кеше белән аралашканда, аның рухи халәте янында булган кешеләргә уңай йогынты ясый һәм аның эчке дөньясында чагыла башлый. Шулай итеп, тискәре энергия, төшенкелек юкка чыга: халәт үзгәрә, кәеф күтәрелә, күңеленә яхшы фикерләр килә. Изге кешеләр белән аралашуның, алар белән элемтәдә булуның әһәмияте турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

---

1 Тирмизи.

2 Әл-Бохари.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ اتَّقُواْ اللّهَ وَكُونُواْ مَعَ الصَّادِقِينَ

**«Ий, иман китерүчеләр!** [Разый булмаган нәрсәләренә якын килү мәсьәләсендә] **Аллаһтан куркыгыз һәм** [иманда, вәгъдәгә тугры калуда, тән һәм рух белән үзе һәм сүзе] **тугры кешеләр белән бергә булыгыз».**

«Әт-Тәүбә», 9:119

Борынгылар: «Яхшы белән юлдаш булсаң, җитәрсең син морадка, яман белән юлдаш булсаң, калырсың син оятка», — дип әйткәннәр.

Шулай ук төшенкелеккә бирелгән кешегә ешрак Коръән укырга, күп зикер, салават әйтергә, догалар кылырга киңәш ителә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтендә күңелсезлектән, төшенкелеккә бирелүдән түбәндәге дога китерелә:

اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ الْهَمِّ وَالْحَزَنِ وَالْعَجْزِ وَالْكَسَلِ وَالْبُخْلِ وَالْجُبْنِ وَضَلَعِ الدَّيْنِ وَغَلَبَةِ الرِّجَالِ

Аллааһуммә иннии әгүүҙү бикә минәл-һәмми вәл-хәзәни вәл-гаҗзи вәл-кәсәли вәл-бухли вәл-җүбни вә-далаги-д-дәйни вә-галәбәтир-риҗәәл.

Тәрҗемәсе: «Йә Раббым, Синнән тынычсызлыктан, сагыштан, көчсезлектән, ялкаулыктан, саранлыктан, куркаклыктан, әҗәт колы булудан һәм кешеләрнең кимсетүеннән саклавыңны сорыйм»[1].

Изге Коръәннән Юныс галәйһиссәламнең догасын укырга мөмкин:

لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ

Ләә иләәһә иллә әнтә сүбхәәнәкә иннии күнтү минәҙ-ҙаалимин.

---

1 Әл-Бохари.

**«...Синнән башка һичбер илаһ юк! Син пакь! Һичшиксез, мин залимнәрдән булдым!»**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:87

Дога кылганда гаурәт капланган булырга тиеш, тәһарәтле булу да мөһим. Дога кылганда Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәтенә, Аның ярдәменә нык ышанырга, өметләнергә кирәк. Ихластан кылынган дога җавапсыз калмый: иртәме-соңмы нәтиҗәсе булачак, иншәАллаһ.

Төшенкелеккә бирелгән кешене тыңлау, аның проблемаларын аңларга тырышу, аны гаепләмәү бик мөһим. Хикмәт ияләре әйтүенчә, андый кешегә киңәшне үзе сораса гына бирергә кирәк.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый хәдисен китерә: «Әгәр берәү икенче кешене дөньялыктагы берәр кайгысыннан азат итсә, Аллаһы Кыямәт көнендә аны бер кайгысыннан коткарыр. Әгәр берәү бурычлы фәкыйрьнең хәлен яхшыртса, Аллаһы ул кешенең хәлен бу дөньяда да, Ахирәттә дә яхшыртыр. Әгәр берәү мөселманны яман эшләрдән коткарып кала икән, Аллаһы ул кешене яман эшләреннән бу дөньяда да, Ахирәттә дә коткарыр. Ул кол үзенең туганына ярдәм иткән кебек, Аллаһы Үзенең колына ярдәм итәр»[1].

Дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгалә тәкъдиренә канәгать булып, Аның ризалыгына омтылып яшәргә насып булсын. Раббыбыз барчабызны да тәүфыйк-һидаятьтән аермасын!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен,

[1] Мөслим.

халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*
*«Апанай» мәчетенең имам-хатыйбы*

*16нчы февраль вәгазе,*

*шәгъбан аеның 6нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Аллаһы Тәгаләнең Әл-Гафур исеме

Әлхәмдүлилләһи раббил-гааләмин вәл-гаакибәтүл муттәкыйн вәссаләтү вәссәләәмү галә расүлинәә мүхәммәдиү вә галә әәлиһи вә-әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактауларыбыз, хәмед-сәналәребез безне юктан бар кылып, күңелләребезгә иман салган галәмнәрнең Раббысы, тәрбиячесе Аллаһы Тәгаләгә булса иде.

Галәмнәргә рәхмәт итеп иңдерелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түребездән чыккан салават-сәламнәребез ирешсә иде.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем, һәрберебезгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм бәрәкәте булса иде. Ике гаеттән дә олуг булган җомга көнебез мөбарәк булсын. Аллаһы Тәгалә укылачак җомга намазыбызны кабул итсә иде. Ике җомга арасында эшләгән изге гамәлләребезне кабул итеп, белеп һәм белми кылган хата-гөнаһларыбызны киң рәхмәте белән гафу итсә иде.

Иманның алты шартының беренчесе — Аллаһының барлыгына һәм берлегенә ышану, Аның күркәм исемнәрен һәм сыйфатларын өйрәнү.

Коръәннең «Әл-Хәшр» сүрәсенең 24нче аятендә Аллаһы Тәгалә болай дигән:

هُوَ اللَّهُ الْخَالِقُ الْبَارِئُ الْمُصَوِّرُ ۞ لَهُ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَى يُسَبِّحُ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَهُوَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ.

**«Ул Аллаһ —** [һәрнәрсәне бер хикмәт белән] **Барлыкка китерүче,** [кимчелекләрсез] **Бар итүче,** [бар нәрсәгә] **калып, рәвеш бирүче.**

**Иң күркәм** [мәгънәләрне белдергән] **исемнәр дә — Аныкы. Күкләрдә һәм җирдә булучылар Аны** [мактап] **тәсбих итә. Ул Бөек** [Җиңелмәс], **Хикмәт иясе».**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:24

Аллаһы Тәгалә иң күркәм исемнәргә һәм иң югары сыйфатларга ия. Аллаһыга барлык камил сыйфатлар хас һәм, шул ук вакытта, Ул барлык җитешсезлек сыйфатларыннан пакь. Моның белән Ул барлык мәхлукларыннан аерылып тора, бу сыйфатларга бары тик Ул гына ия.

Без Раббыбызны Коръәндә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтендә китерелгән сыйфатлары аша beләбез. Раббыбыз Үзен ничек аңлаткан һәм Аның Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аны ничек сыйфатлаган — Аны шулай сыйфатлыйбыз.

Аллаһының исем-сыйфатларын, Ул Үзе бу хакта хәбәр иткәнчә, тулысынча да, өлешләтә дә кире какмыйча, сүзләрнең мәгънәсен үзгәртмичә, мәхлукларның сыйфатларына охшатмыйча һәм аларныкы белән чагыштырмыйча, «ничек?», «ни рәвешле?» дигән сораулар бирмичә кабул итәбез.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلِلَّهِ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَىٰ فَادْعُوهُ بِهَا ۖ وَذَرُوا الَّذِينَ يُلْحِدُونَ فِي أَسْمَائِهِ ۚ
سَيُجْزَوْنَ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ

**«Аллаһыда —** [иң матур һәм иң шәрәфле мәгънәләрне белдергән] **күркәм исемнәр. Аңа шулар белән ялварыгыз.** [Шәригатьтә билгеләнмәгән исемнәр уйлап чыгарып] **Аның исемнәре хакында дөреслектән тайпылган кешеләрне калдырыгыз. Һичшиксез, алар кылган нәрсәләре өчен җәзаландырылачаклар».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:180

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Аллаһының 99 исеме бар. Кем аларны әйтеп чыга, шул җәннәткә керә»[1].

Шул 99 исеме аша кеше Раббысын таный; әлеге исем-сыйфатлар Аллаһының камиллеген күрсәтә. Аллаһы Тәгаләнең мәгълүм булган бер исемен дә инкарь итәргә ярамый. Кызганычка, кайберәүләр наданлыклары аркасында мәгънәләрен аңламыйча, Аллаһының исемнәренә икенче аңлатмалар бирәләр яки мәхлукларга кушалар.

Балага да Аллаһы исемен кушарга ярамый. Мәсәлән, Рахман дип түгел, ә Габдрахман дип кушарга кирәк.

Аллаһы Үзе юктан бар кылган мәхлукларга барлыгы белән дә, сыйфатлары белән дә охшамаган. «Әш-Шура» сүрәсенең 11нче аятендә:

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ

**«...Аңа** [Аллаһы Тәгаләгә] **охшаш бернәрсә дә юк** [Аның хатыны яки баласы бар дип уйлап та булмый]**...»** — диелә.

«Әш-Шура / Киңәш», 42:11

Бүгенге җомга вәгазендә Аллаһы Тәгаләнең күркәм 99 исеме арасыннан Әл-Гафур — Гафу итүче, күп итеп ярлыкаучы дигән мәгънәне белдергән исеме хакында булыр.

Безгә билгеле булган Аллаһының 99 исеме арасында 34нче күркәм исеме Әл-Гафур — Гафу итүче. Ул чиксез кичерү иясе һәм кешеләрнең гөнаһларын яшерүче, аларга туры юлга кайтырга вакыт бирүче.

Кешенең гөнаһы, никадәр күп булса да, Аллаһы аларны өскә чыгармас, яшерер, гафу итәр.

«Гафәра» (гафу итү) фигеле тамырыннан ясалган Аллаһы Тәгаләнең өч исеме бар, алар мәгънәсе буенча Әл-Гафурга бик якын. Әл-Гафир — Гафу итүче, ярлыкаучы. Коръәндә бу исем бер мәртәбә искә алына:

---

[1] Әл-Бохари.

غَافِرِ الذَّنبِ وَقَابِلِ التَّوْبِ شَدِيدِ الْعِقَابِ ذِي الطَّوْلِ ۖ لَا إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ ۖ إِلَيْهِ الْمَصِيرُ

«[Мөэминнәргә] **Гөнаһларны гафу итүче, тәүбәләрне кабул иткән,** [инкяр итеп, баш күтәргәннәргә карата] **газабы каты булган һәм** [иман итеп, изге гамәл кылучыларга] **муллык иясе булган** [Аллаһ] **ки, Аннан башка һичбер илаһ юк. Соңгы кайту да Аңа гына** [булачак]**».**

«Гафир / Гафу итүче», 40:3

Әл-Гаффәр — Яшерүче, Ярлыкаучы. Бу сүзнең тамырында «яшерүче» мәгънәсе бар. Аллаһы кешеләр тарафыннан күрелеп, беленергә тиешле булмаган нәрсәләрне яшерер. Әлбәттә, бу, беренче чиратта, гөнаһларга карый. Әгәр бу дөньяда эшләнелгән һәр гөнаһ Ахирәттә фаш ителсә, безнең андагы хәлебезне аңлатырлык сүзләр табылмас иде. Бөек Аллаһы бу исеме белән колларының гөнаһларын яшерер, ягъни гафу итәр. Аллаһының бу исеме Коръәндә биш аятьтә килә:

فَقُلْتُ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ إِنَّهُ كَانَ غَفَّارًا

**«Мин әйттем: «Раббыгыздан ярлыкау сорагыз. Һичшиксез, Ул –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче».**

«Нух», 71:10

Әл-Гафур — Күп итеп ярлыкаучы. Аллаһы мәгъфирәт ияседер. Кешенең гөнаһы, никадәр күп булса да, Аллаһы аларны өскә чыгармас, яшерер, гафу итәр. Әлеге исем Коръәндә туксан бер мәртәбә искә алына.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَاسْتَغْفِرُوا اللَّهَ إِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَحِيمٌ

**«...**[кылган хата-кимчелекләрегез өчен] **Аллаһтан мәгъфирәт сорагыз. Һичшиксез, Аллаһ –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:199

Әл-Гафур исеме Коръәндә Аллаһының башка исемнәре белән бергә очрый:

— Әр-Рахим — Мәрхәмәтле; Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

إِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ

**«...Һичшиксез, Аллаһ —** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:173

Бу сәбәп белән нәтиҗәнең берләшүе, ягъни Аллаһы Тәгалә гафу итәчәк кешегә Үзенең мәрхәмәтен дә күрсәтәчәк икәнлеген белдерә.

— Әл-Газиз — Куәтле, һәрнәрсәдән өстен; Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ

**«...Ул – Бөек** [Җиңелмәс]**,** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче».**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:2

Монда Раббыбыз безне кичерүче икәнлеге һәм шулай ук Аның безне җәзаларга да куәте җиткәне аңлатыла.

— Әл-Вәдүд — Яратучы; Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَهُوَ الْغَفُورُ الْوَدُودُ

**«Ул —** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче,** [Үзенең иманлы колларын] **Яратучы».**

«Әл-Бүруҗ / Йолдызлыклар», 85:14

Бу шуны аңлата: Аллаһы Тәгалә гөнаһны кичерү белән бергә, аның эзен дә бетерә. Без, кешеләр, берәрсен кичерә алабыз, ләкин күңелдә ачу һәм рәнҗү ачысының бер өлеше калырга мөмкин, әмма Раббыбыз андый түгел.

Аллаһы Тәгаләнең Әл-Гафур дигән күркәм исеменең аңлатмасы:

— гөнаһларны күп итеп кичерүче;

— әгәр тәүбә итсәләр, колларының гөнаһларын гафу итүче;

— кешеләрнең гөнаһлары, күплегенә карамастан, аларны ярлыкаучы;

— колларының гөнаһларын яшерүче вә аларны рәхмәт вә юмартлык киемнәре белән киендерүче;

— Ул — Аллаһы, колының гөнаһлы эшен башкаларга күрсәтмәс, вә Ул колының гөнаһын кешеләр алдында күрсәтеп, мәсхәрә кылмас, пәрдә куяр.

Аллаһы Тәгаләнең Әл-Гафур исемен белүнең мөселман тормышында йогынтысын карап китик. Әл-Гафур — Кичерүче икәнлегенә ышану, Аллаһы юлыннан адашып, зур гөнаһларга баткан кешеләр өчен өмет. Әгәр алар тәүбә кылып, Раббыларының туры юлына кире кайтып, Аллаһы кушкан һәм яраткан яхшы эшләрне арттырсалар, Аллаһы Тәгалә, Үзенең олы мәрхәмәте һәм игелеге аркасында, аларның начар эшләрен яхшы гамәлләр белән алыштырачак.

Аллаһының Әл-Гафур — Ярлыкаучы исеме. Ул Аллаһы Тәгаләнең колларына карата олы рәхмәте. Аллаһы Тәгалә бөтен галәмнең хуҗасы һәм барлык мәхлуклар Аның мәрхәмәтенә мохтаҗ. Асылда, колларының гөнаһларын гафу итүе яки гөнаһлары өчен газап бирүе Аллаһының дәрәҗәсен күтәрми дә, төшерми дә, чөнки ул бөтен кимчелекләрдән һәм җитешсезлекләрдән пакь.

Аллаһының бу исеменә ышанучы, башка кешеләрнең дә хаталарын, ялгышларын яки кимчелекләрен башкалардан яшерергә, аларны гафу итәргә омтыла. Әгәр ул башкаларның хаталарын яшерсә, гафу итсә, Аллаһы да гөнаһларын гафу итәчәк.

Чиксез кодрәт Иясе Аллаһының рәхмәтеннән өметне өзмәү. Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзү — иң зур гөнаһларның берсе. Өметсезләнү кылган гөнаһның үзеннән дә зуррак җинаять булырга мөмкин.

Әл-Гафур — Ярлыкаучы икәнлегенә ышану мөселманның йөрәгендә Аллаһы Тәгаләгә карата мәхәббәтен арттыра, ул Аллаһының ярлыкаучы икәнлеген танып, Раббысына гөнаһларын кичергәне һәм колларына мәрхәмәт күрсәткәне өчен шөкер итә. Әгәр Аллаһы ярлыкамаса, кеше үзенең

күп санлы гөнаһлары һәм җинаятьләре аркасында һәлак булыр иде. Кеше хатасыз түгел һәм ул онытучан итеп яратылган.

Әлеге исемгә ышану мөселман йөрәгенә үз-үзен даими контрольдә тотуны һәм Аллаһыга хөрмәт йөзеннән гөнаһлар эшләмәү өчен максималь саклык куя. Гөнаһка юлыккан һәрбер мөселманның күңеленә өмет бирә, шайтан аны өметсезлеккә бирелүен тели, гөнаһлы кеше Аллаһының Әл-Гафур исемен хәтерләп, аның йөрәгенә өмет үтеп керә, тәүбәгә килеп, кабат үзен Барлыкка Китерүчесенә әйләнеп кайта.

Хөрмәтле җәмәгать, нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: Гафу итүче дигән Аллаһы исеменең мәгънәсен белү мөселманны Аллаһыга буйсынырга һәм Аңа якынаерга, Аның кичерүен һәм шәфкатен сорарга этәрә. Раббының кичерүче һәм шәфкатьле булуын белгәч, нинди генә гөнаһ эшләсә дә, ул өметсезлеккә бирелми.

Гөнаһлы кеше тәүбәгә килеп, тормышын яхшы якка үзгәртеп, гаиләсенә һәм җәмгыятькә файда китерүче, дөньяда һәм Ахирәттә дә бәхетле кешегә әйләнә.

۞ قُلْ يَا عِبَادِيَ الَّذِينَ أَسْرَفُوا عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ ۚ
إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا ۚ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ

«[Расүлем! Җаһилият дәверендә бик күп кеше үтергән, зина кылган һәм кол хакына кергән мөшрикләрдән сиңа килеп иман китергән очракларында, тәүбәләренең кабул ителеп-ителмәве һәм элек кылганнарының берәр кәффарәте булып-булмавы турында сораганнарга Безнең исемнән] **Әйт: «Ий, үз-үзләренә каршы зарарда булган колларым! Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһ** [ширектән тыш] **барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул —** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53

Аллаһы Тәгалә — Әл-Гафур, Әр-Рахим (Ярлыкаучы һәм Рәхимле). Тәүбәгә килеп, иманга кайткан, намазга баскан, уразасын тоткан, башка гыйбадәтләренә керешкән кешеләрнең гөнаһларын гафу итеп, аларны савапка әйләндерә. Бу хакта «Әл-Фуркан» сүрәсенең 70нче аятендә болай дип әйтә:

إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا فَأُولَٰئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ۝

**«Тик** [көферлектән] **тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына! Аларның** [тәүбәләре сәбәпле сөртелгән] **начарлыкларын Аллаһ күркәм нәрсәләр белән алмаштырачак. Аллаһ Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әл-Фуркан / Аеручы», 25:70

Бу безнең барыбыз өчен дә сөенечле аять. Һәрберебезгә әлеге аятькә игътибар салып тәүбәгә килергә, иманга кайтырга насыйп булса иде.

Бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

«Гөнаһтан тәүбә итүче — гөнаһсыз кеше кебек»[1].

Кеше белән Аллаһы Тәгалә арасында нинди генә гөнаһ булса да, Раббыбыз кичерүче. Фәкать барына да тәүбә-истигъфар кылып, иман юлына басарга кирәк.

Ә менә ике кеше арасында булган гөнаһларны Раббыбыз, бу кешеләр берсен-берсе гафу итеп бәхилләшми торып, кичерми. Шуңа күрә исән чагыбызда үзебез аралашкан һәр кешедән гафу үтенеп, бәхиллеген сорарга кирәк.

Тәүбә-истигъфар кылуның фазыйләтләре күп. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хакта шулай дигән: «Кем тәүбә-истигъфарны даими рәвештә әйтеп йөрсә, Аллаһы Тәгалә аңа сынау килгәндә төрле

1 Ибне Мәҗе.

юлларын ачып җиңеллекләр тудыра, кайгырганда аны Үзе тынычландыра һәм хисапсыз җирләрдән ризык яудыра»[1].

Бу Коръән аятьләреннән һәм хәдисләрдән аңлашылганча, кеше үзенең кылган һәрбер гөнаһ эшеннән тәүбә итәргә тиеш.

Аның кылган гөнаһы Аллаһы белән ике арада булса, тәүбәсе өч шартка нигезләнә:

1) тәүбә иткән гөнаһ эштән ваз кичү, үзен тыю;

2) кылган гөнаһына, хатасына үкенү;

3) тәүбә иткән гөнаһ эшне башка кабатламау.

Шул өч шартның берсе генә булмаса да, тәүбә хакыйкый булмый.

Кешеләр белән ике арада булган гөнаһ эшләргә тәүбә дүрт шартка нигезләнә: өчесе югарыда әйтеп үтелгән шартлар, дүртенчесе — әгәр берәүнең малын тартып алган булса, ул малны хуҗасына кайтарып бирү, хуҗасы исән булмаса, гаиләсенә, туганнарына бирү.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, пәйгамбәр булуына да карамастан, ягъни Аллаһы Тәгалә аның кылган һәм кылачак бөтен гөнаһларын гафу итсә дә, барыбер тәүбә итүдән туктамаган. Аллаһының илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әй, кешеләр, Аллаһыга тәүбә итегез, мин һәркөнне йөз мәртәбә тәүбә итәм», — дигән.

Йә Аллаһым, белеп һәм белмичә, ният белән һәм ялгыш кылган гөнаһларыбызның барчасын да кичер!

Йә Аллаһым! Элек һәм соңрак, яшертен һәм ачык кылган гөнаһларыбызны, тыелганны, үтәмәгәннәребезне һәм дә Үзеңә генә мәгълүм булган гөнаһларыбызны кичер!

Син бирүче һәм Син кичектерүче! Синең бөтен нәрсәгә көчең җитә!

Йә Аллаһым! Җаннарыбызны пычрактан арындыр, аңа иман иңдер! Син генә аны арулаучы, Син генә аның хуҗасы һәм хөкемдары!

---

[1] Әбү Давыд.

Йә Аллаһым! Бозык белемнәрдән, сабырсызлыктан, бозык нәфесләрдән, җавапсыз ялварудан Үзең сакла!

Йә Аллаһым! Безгә камил акыл бир һәм нәфесебезнең бозыклыгыннан сакла!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Мухлисов,*
*«Казан Нуры» мәчете имамы*

*23нче февраль вәгазе,*
*шәгъбан аеның 13нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Госман радыяллаһу ганһе — оялчанлык үрнәге

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәнәләребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түреннән чыккан салаватшәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек биреп, сау-сәламәт хәлебездә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт, Аңа шөкер яшәргә насыйп итсә иде! Аллаһы Тәгалә җомга көнебезне хәерле һәм мөбарәк кылсын!

Дүрт тугры хәлифләрнең хаклыгына иман китерү, аларны хөрмәт итү, аларның Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлыннан баруларына ихластан ышану — безнең игътикадыбызның нигезен тәшкил итә. Без аларны һәрвакыт Аллаһы Тәгалә алардан риза булсын — радыяллаһу ганһу — дип искә алабыз.

Госман радыяллаһу ганһе милади ел хисабы буенча 574 елда дөньяга килгән. Риваятьләрдә аның Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән 3–4 яшь кече булуы хакында хәбәр ителә. Госман радыяллаһу ганһенең нәселе өченче буында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәселенә килеп тоташа.

Госман радыяллаһу ганһе сәүдәгәрләр гаиләсеннән була. Мәккә шәһәрендә алар яхшы, мул тормыш алып барган, дип хәбәр ителә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә пәйгамбәрлек килгәннән соң, беренчеләрдән (алар әүвәлиннәр дип аталып йөртелгәннәр) булып, Ислам кабул итүчеләр арасында Хәдичә анабыз, Зәйд, Әбү Бәкер һәм Гали радыяллаһу ганһүм булса, икенчеләрдән булып (аларны сәбикыйннәр дип атаганнар), Ислам динен Госман радыяллаһу ганһе кабул итә. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе, үзе Исламга килгәч, башкаларны да дәгъват кыла башлый. Ул дәгъват иткән кешеләр арасында Госман радыяллаһу ганһе дә була.

Көннәрдән бер көнне, Госман радыяллаһу ганһене очратып, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе аңа: «Әй, Госман, син безнең арада акыллы, хикмәтле кеше. Күрче, күпме халык җансыз, файда да, зыян да китерә алмый торган потларга гыйбадәт кыла», — дип әйтә.  Госман радыяллаһу ганһе, уйга калып: «Син миңа ни тәкъдим итәсең соң?» — дип сорагач, Әбү Бәкер аңа: «Син Габдулла улы Мөхәммәдне тыңлап кара әле, ул бер илаһлыкка чакыра, үзен Аллаһының илчесе ди, аның сүзләре сиңа тәэсир итмичә калмас», — дип әйтә. Нәкъ шул вакытта алар яныннан Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үтеп бара һәм, Госманны күреп, аны кочаклап: «Әй, Госман, Аллаһы Тәгалә сине җәннәткә чакыра, мин сиңа Ислам динен кабул итәргә тәкъдим итәм», — дип әйтә һәм Ислам турында сөйләп-аңлатып китә. Госман радыяллаһу ганһе: «Мине ул көнне Ислам динен кабул итүдән берни дә, беркем дә тыеп тора алмады», — дип шәһадәт китерә. Карагыз әле, җәмәгать, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм нинди матур сүзләр әйтә: «Аллаһы Тәгалә сине җәннәткә чакыра!» Ә без үзара вәгазьләр сөйләгәндә кешене җәһәннәм белән куркытабыз: «Утка

эләгәсең, тәмугъта янасың, фәлән...» Ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй, Госман, Аллаһы Тәгалә сине җәннәткә чакыра», — ди. Аллаһы Тәгалә безне һәрбарчабызны җәннәткә чакыра. Аллаһы Тәгалә залим һәм куркыныч зат түгел, Ул безгә начарлык теләми, Ул — рәхимле, шәфкатьле Бөек Зат! Шуңа күрә дәгъват кылган вакытта Аллаһының күркәм сыйфатларын искә алыйк, кешеләрне хикмәт белән, матур итеп, йомшаклык белән Ислам диненә чакырыйк, аларны күркәм дин белән кызыктырыйк.

Госман радыяллаһу ганһе Ислам динен кабул иткәннән соң, аны абыйлары һәм башка туганнары диннән яздырырга теләп, төрле газап-җәфалар чиктерә: башта аяк-кулларын бәйләп, тирән базга ташлыйлар, төтен белән буалар, ләкин Госман радыяллаһу ганһе Ислам диненә тугры кала, туры юлдан тайпылмый. Соңыннан, пәйгамбәрлекнең бишенче елында, динен саклап калу өчен, Госман радыяллаһу ганһе, 12 ир һәм 4 хатынны ияртеп, Хәбәшкә һиҗрәт кыла. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, аның бу гамәлен хуплап: «Син Лут галәйһиссәламнән соң динен саклап, һиҗрәт кылучы икенче кеше», — дип әйтә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әүвәл Рокыя, соңыннан, Рокыяның вафатыннан соң, Өммегөлсем исемле кызларына никахланганнан соң, аны «Госман Зин-нүрәйни», ягъни «ике нур иясе» дип атыйлар. Мөселман чыганакларында хәбәр ителгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ике кызы да вафат булып, Госман радыяллаһу ганһе тол калгач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Әгәр өченче кызым да булса, аны да сиңа кияүгә бирер идем», — дип әйтә.

Госман радыяллаһу ганһе Ислам динен кабул иткәннән соң иң күп гыйбадәт кылучылардан була: ул төнге намазларга тора, бик күп уразалар тота, аның бер намазда Коръәнне тулысынча укып чыгуы хакында хәбәр ителә. Ул: «Калебе пакь булган кеше Коръән укудан һич туймас», — дип әйтә торган булган.

Госман радыяллаһу ганһенең бик матур телле булуы, йомшак сөйләве, беркайчан да сүзен уйламыйча әйтмәве хәбәр ителә. Ул, Аллаһы Тәгаләдән

куркып, бик еш елый торган булган. Үзенең дәрәҗәсенә карамастан, бөтен кешегә дә хөрмәт белән, бер дәрәҗәдә сөйләшә торган булган. Шулай ук аның бик оялчан һәм тыйнак булуы билгеле. Сәхабәләр арасында ул юмартлыгы белән дә аерылып торган.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе хәлифәлеге вакытында Мәдинәдә ачлык башлангач, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе, халыкны тынычландырырга теләп: «Аллаһы Тәгалә безгә бу афәттән чыгу юлын бирми калмас», — дип әйтә. Шул ук төнне Мәдинәгә ризыклар төялгән мең дөялек Госман радыяллаһу ганһенең кәрваны кайтып керә. Алып-сатарлар, аны чорнап алып, бер дөягә ике дөя бәясен тәкъдим итәләр. Госман радыяллаһу ганһе аларга: «Миңа күбрәк бирүче бар», — дип җавап кайтара. Алар гаҗәпләнеп: «Кем ул?» — дип сорагач, хәзрәти Госман радыяллаһу ганһе: «Аллаһы Тәгалә», — дип җавап бирә һәм бөтен кәрванын мөселманнарга бүләк итеп тарата, шуның белән ул кешеләрне ачлыктан коткарып калуда сәбәпче була.

Мөселманнар Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылгач та, ул бик зур изгелек эшли. Мәдинәдә су кытлыгы башлангач, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм иң күп сулы кое хуҗасы булган Бәни Гыйбар гаиләсәнә килеп, тәкъдим ясый: «Бу коегызны җәннәттәге коега алмаштырырга теләмисезме?» — дип әйтә. Бәни Гыйбар кабиләсе: «Бу кое — безнең бердәнбер табыш чыганагыбыз. Әгәр аны сиңа бирсәк, без малсыз калабыз», — дип тәкъдимне кире кагалар. Госман радыяллаһу ганһе, бу хакта ишетеп, алар янына килә һәм бу коены 35 мең динарга сатып алып, мөселманнарга бүләк итә. Соңыннан Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Йә, Расүлуллаһ, син миңа Бәни Гыйбарга вәгъдә кылганны вәгъдә итәсеңме?» — дип сорый. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әйе», — дип әйтә.

Госман радыяллаһу ганһе хәлифәлеккә 70 яшендә килә һәм ул барында Ислам җәмгыяте чәчәк ату чорын кичерә: ул Коръәнне бер мөсхәфкә туплап, аннан 7 күчермә ясарга боера, соңыннан аларны җиде төбәккә тараттыра; Госман радыяллаһу ганһе чорында мөселманнарның 600 көймәлек

флотилиясе төзелә; аның үз акчасына Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчете янындагы җирләр сатып алынып, мәчет зурайтыла һәм бизәкләндерелә; Мәккә шәһәрендәге әл-Харам мәчете киңәйтелә; мөәзиннәргә махсус эш хакы билгеләнә; аның дәверендә Ислам дине бик күп җирләргә тарала, шул исәптән безнең хәзерге Татарстан, элекке Болгар җирләренә дә сәхабәләр әүвәл аның заманында килеп җитә. Шул рәвешле сәүдәгәрләр ярдәме белән безнең татарлар арасында да Ислам дине Госман радыяллаһу ганһе заманында ук тарала башлый. Мөселманнарның тәэсире шулкадәр үсүе, әлбәттә, эзсез калмый, шул ук дәвердә төрле фетнәләр башлана. Госман радыяллаһу ганһене хаҗ аенда, риваятьләрдә әйтелгәнчә, 15 меңгә якын кеше камап алып, Коръән укыган вакытында, 82 яшендә үтерелә. Шул рәвешле, ул шәһит үлеменә дучар була. Бу аяныч хәлләрнең сәбәбе — мөселманнар арасында килеп чыккан төрле фетнәләр була. Шуңа күрә дә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләрне һәм безне кисәтеп: «Фетнәләрдән сакланыгыз! Фетнә — ул үтерүдән дә куркыныч әйбер», — дип әйтә торган булган. Аллаһы Тәгалә безне дә зур фетнәләрдән сакласын иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Зөлфәт хәзрәт Габдуллин,*

*«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе остазы*

*1нче март вәгазе,*

*шәгъбан аеның 20нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Рамазан ае фазыйләте

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактау-данлау Аллаһы Тәгаләгә булсын! Без Аңа шөкрана кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Үзебезнең начарлыгыбыздан, бозык гамәлләребездән Аллаһы Тәгаләдә сыену эзлибез. Аллаһы туры юлга күндерсә, берәү дә адаштыра алмас, Аллаһы адаштырганнарны берәү дә туры юлга кертә алмас. Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаеклы илаһи зат юк, «Ул — Берүзе, Тиңдәшсез һәм Мөхәммәд — Аның колы һәм расүле».

Мөхтәрәм җәмәгать! Бүгенге темабыз Рамазан ае, аның фазыйләтләре, ураза һәм бу айда булган башка гыйбәдәтләр хакында мәгълүматлар җиткерербез, иншәАллаһ.

Беренчедән, Рамазан ае — ул адәм балалары Аллаһыны танып, Раббыбызның әмерен үтәү вакыты. Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

> **«Ий, иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә** [фарыз булып] **язылган кебек, сезгә дә** [Рамазан аендагы] **ураза** [фарыз булারак] **язылды. Бәлки,** [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] **тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Газиз дин кардәшләр, Рамазан ае — Аллаһының әмерен үти, буйсына, тыңлый торган ай, итагать кыла торган ай. Кем дә кем, каршы килеп, «мин моны эшләмим, миңа моның хаҗәте, кирәге юк», — дип динебездән көлә,

кем дә кем ураза гамәлен фарыз дип танымый, кимсетә икән, көферлеккә төшәргә, иманын да югалтырга мөмкин. Шуңа күрә, җәмәгать, бу — иманыбыз, тәкъвалыгыбыз өчен имтихан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Өммәтемнең уразасы башка өммәтләрдән сәхәр белән аерылып торыр, сәхәр ашагыз, сәхәрдә бәрәкәт бар», — диде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

وَالْمُسْتَغْفِرِينَ بِالْأَسْحَارِ

**«...һәм сәхәр вакытларында истигъфар кылучылар».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:17

Бу аять сәхәр вакытында истигъфар кылуның фазыйләтле икәненә дәлил булып тора. Шуңа күрә төннең өченче яртысында, тәүбә кылып, өстәмә намазлар укып, Аллаһыны зикер итеп, шушы күркәм, матур вакытларны Раббыбыз каршында гыйбадәттә булсак, бушка уздырмасак иде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кыямәт көнендә ураза белән Коръән Аллаһы колы өчен шәфәгать кылырлар», — диде. Ураза әйтер: «Йә Раббым, бу кеше көн дәвамында уразалы булды, аңа мәрхәмәт кылсаңчы, аны ярлыка!» Коръән әйтер: «Йә Раббым, бу бәндә төннәрен йокламыйча, Коръән укыды», — дип яклап чыгар икән.

Икенчедән, Рамазан ае — ул Коръәнне күпләп укый торган ай, Коръән ае. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә Коръән укыйсыз икән, һәр хәреф саен бер изгелек, бер изгелеккә 10 әҗер-савап, — ди, — «әлиф, ләм, мим» дип укыганда, ул үзе бер хәреф түгел, алар һәрберсе аерым хәреф», — ди. Димәк, башка вакытта шушы 3 хәрефне укыган өчен 30 әҗер-савап алсак, Рамазан аенда бәлки күбрәк күләмдә алырбыз, иншәАллаһ.

Җәмәгать, Коръән укуның дөньялык һәм Ахирәт өчен фазыйләтләре күп. Имам Әш-Шәгъби рахимәһуллаһи: «Кем дә кем Коръән укыса, акылын җуймас», — дигән. Коръән уку адәм баласының акылына, рухи халәтенә нык тәэсир итә. Аллаһының Китабын көйләп укырга тырышырга кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем Коръәнне мәкам белән көйләп укымый, ул бездән түгел», —

дигән. Димәк, әгәр дә без тәҗвид белән һәрбер хәрефне җиренә җиткереп, матур тавышыбыз белән укыйбыз икән, иншәАллаһ бик күп әҗер-савапларга ирешербез.

Мөхтәрәм җәмәгать, күп галимнәр Коръәнне саклау хакында әйткәннәр. Имам Әд-Даххак рахимәһуллаһи: «Шундый заман килер, адәм балалары Коръәнне ташларлар, калдырырлар, хәтта Коръәннәрендә үрмәкүч үзенең оясын корыр, пәрәвез корыр һәм аннан бер файда алмаслар», — дип әйткән. Җәмәгать, чыннан да, Коръән ташланганлыгын, тузанланганын  күрәбез. Пәрәвез кайда барлыкка килә? Әлбәттә, кешеләр йөрмәгән, кешеләр кулы тимәгән урыннарда. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән Мәккәдән Мәдинәгә күчкән вакытта Сәвер тавы куышлыгында качып, яшеренеп торганнар. Артларыннан куа килгән корәеш ирләре алар качкан тау куышлыгы пәрәвез белән әйләндереп алынганын күргәннәр. Бу урында кеше йөрмәгән икән дип, калдырып киткәннәр. Шуңа күрә, җәмәгать, кешеләр булмаган ташландык урында гына пәрәвез оялаганын аңларга кирәк. Хөрмәтле дин кардәшләрем, без дә Изге Китапны шундый хәлдә калдырмасак иде. Рамазан аенда Аллаһы Китабын кулларыбызга алып укысак, өйрәнсәк иде. Һәр сүрә, һәр аятьне укып, күңелләребезгә кертеп, бик күп әҗер савапларга ия булсак иде.

Өченчедән, Рамазан шулай ук юмартлык ае. Сәхабәләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне кешеләр арасында иң юмарты иде дип искә алганнар. Рамазан аенда аның юмартлыгы искән җилнекеннән дә артык була. Искән җил җылы яки салкын һава, яңгыр алып килсә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенә килгән һәр алтын, һәр көмешне таратып бетерә, үзенә кадерле әйберләрне бүлешә торган була. Камәт алдыннан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намазга തоткарлангач, сәхабәләргә: «Мал-мөлкәт бүлеп вакытым узды», — дип әйтә торган булган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм ятимнәрнең, мохтаҗларның, фәкыйрьләрнең хәлләрен белергә тырышкан. Рамазан ае — ул мохтаҗларның, ятим балаларның хәлләрен белә торган ай. Рамазан аенда искиткеч күп әҗерләр эшләп, садака биреп, ифтарлар уздырып

була. Пәйгамбәребез: «Кем дә кем ураза тотучыны авыз ачтырса, ураза тоткан кешенеке кадәр әҗер-савапка ия булыр, ураза тотучыныкы да һич киметелмәс», — дип әйткән. Шуңа күрә, мөхтәрәм җәмәгать, Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәтенә ирешергә ашыксак иде. Йортыңа җыю гына димәгән, бу эшне җәмәгать урыннарында: урамда, транспортта, укыган, эшләгән урыныбызда да эшләп була, кардәшләребезне күрәбез икән, бер хөрмә җимеше белән булса да бүлешсәк, никадәр әҗер-савап алдың дигән сүз, иншәАллаһ. Рамазан аенда игътибарлырак булсак иде.

Рамазан ае фазыйләте турында сөйләшкәндә Кадер кичен искә алу урынлы булыр иде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

إِنَّآ أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةِ الْقَدْرِ ۞ وَمَا أَدْرَاكَ مَا لَيْلَةُ الْقَدْرِ ۞ لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ

**«Һичшиксез, Без аны** [мәңгелек могҗиза булган Коръәни Кәримне] **Кадер кичәсендә** [Ләүхелмәхфүздән тулы килеш беренче кат күккә] **иңдердек. Кадер кичәсенең нинди икәнен син каян беләсең? Кадер кичәсе** [Кадер кичәсе булмаган] **мең айдан да хәерлерәк.** [Шул сәбәпле, аңарда кылынган изге гамәл сиксән өч ел да дүрт ай буена бертуктаусыз кылынган гамәлгә тиң генә түгел, аннан да фазыйләтлерәк]**».**

«Әл-Кадр / Кадер киче», 97:1–3

Ягъни, башка вакытка караганда, изге гамәлләрең Кадер кичәнә туры килсә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә: «Кадер кичен Рамазанның соңгы ун көнлегендә, так санлы кичәсендә эзләгез», — дигән. Димәк, шул кичәне табабыз икән, тәгаенләп, сагынып, көтеп, гыйбадәттә үткәрсәк, Пәйгамбәребез хәдисендә әйтелгәнчә: «Кем дә кем Кадер кичен уяу рәвештә уздырса, моңа кадәр кылган гөнаһлары кичерелер», — диде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә гөнаһларыбыздан, кимчелекләребездән, хаталарыбыздан котылырга, имин булырга, чистарынырга насыйп итсә иде.

*Рөстәм хәзрәт Ясәвиев,*

*«Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы*

*8нче март вәгазе,*

*шәгъбан аеның 27нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Хәдичә радыяллаһу ганһә — яхшы хатын-кыз үрнәге

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп, кылган гыйбадәтләребезне кабул кылсын, атлап килгән һәрбер адымнарыбыз өчен әҗер-савапларын насыйп итсен. Аллаһы Тәгалә безгә вәгазьләнеп, дөнья, Ахирәт өчен файдалы сүз, файдалы фикер аңларга һәрбарчабызга насыйп кылсын.

Ислам гаилә коруга аерым игътибар бирә һәм балигъ булган, моңа матди яктан әзер кешенең гаилә коруын төрле яклап хуплый.

Аллаһы Тәгалә ир-атны — кешелекнең атасын Адәмне һәм аның тәненнән хәләл җефетен, «алар бергә тынычлык тапсыннар», дип Хавваны яраткан. Хәләл җефетләр арасында мәхәббәт, шәфкать хисләре туу — Аллаһыдан:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ

**«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яралтуы һәм арагызда сөю** [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] **белән бер шәфкать** [чарасы булган бала] **бирүе дә — Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен** [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] **билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:21

Бүген — 8нче март, илебездә бәйрәм буларак билгеләп үтелә. Бүгенге җомга вәгазебез дә күркәм затларыбыз һәм аеруча, Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә биргән олуг нигъмәтләренең берсе булган Хәдичә радыяллаһу ганһә турында булыр, иншәАллаһ.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөбарәк хәдисендә: «Тормыш — шатлык һәм ләззәт ул, ә тормыштагы иң зур шатлык — изге хатын», — дигән.

Аллаһы тарафыннан ир кешегә бирелгән иң зур бүләк — ул тәкъва хатын. Бу — олы нигъмәт.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш иптәше, беренче хәләл җефете Хәдичә радыяллаһу ганһә — тәкъваларның тәкъвасы була. Хәдичә бинте Хөвәйлид — Корәеш кабиләсенең бай һәм дәрәҗәле хатыннарыннан. Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң беренче хатыны, Ибраһим исемле улыннан кала, аның барлык балаларының анасы, Ислам кабул иткән беренче хатын-кыз.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кияүгә чыкканчы, Хәдичә ике тапкыр кияүдә була. Беренче ире — Әбү Хәүлә — ул вафат була, һәм Хәдичә икенче тапкыр кияүгә чыга, әмма ул ireннән аерыла.

Хәдичә радыяллаһу ганһә Исламга кадәрге чорда ук үзенең яхшылыгы белән дан казанган була. Әхлакый пакьлеге, сафлыгы өчен гарәпләр аны таһирә, ягъни пакь дип атаганнар. Корәеш кабиләсенең күп кенә күренекле кешеләре кияүгә чыгарга дип аңа тәкъдим ясасалар да, Хәдичә аларның тәкъдимнәрен кире кага. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мөхәммәд

салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыны булуын Хәдичә ханымның тәкъдиренә язган булган.

Хәдичә Мәккәнең иң бай кешеләреннән санала иде. Кайбер тарихчылар әйткәнчә, Мәккә кәрваннары юлга кузгалган вакытта Хәдичәнең товарлары бөтен Корәеш сәүдәгәрләренең товарларын кушсаң да, барыбер артык була торган. Иң мөһиме — ул үз байлыгын хак юл белән тапкан, ришвәттән азат булган сәүдә алып барган.

Җәһилият заманында хатын-кызларга, бигрәк тә эшкуар ханымнарга, җиңелләрдән булмаган, хезмәт юлларында авырлыклар очраган. Әмма көчле рухлы Хәдичә, бернәрсәгә дә карамыйча, уңышлы сәүдә алып барган. Исламга кадәрге чорда да Хәдичә беркайчан да потларга табынмаган. Моңа этәргеч булып, христиан идеологиясе артыннан баручы, Инҗилне гарәп теленә тәрҗемә итүче Вәрәка бине Нуфайль исемле кеше була.

Бервакыт Хәдичә Сүриягә бара торган чираттагы кәрванны әзерләп куя. Гадәттәгечә, аңа кәрванны озатып баручы намуслы кеше кирәк була. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу вакытта Корәеш кавеме арасында гадел, ышанычлы һәм тугры булуы белән дәрәҗә казанган була. Аны хәтта «әл-Әмин» (ышанычлы) дип тә йөртәкән булганнар. Хәдичә аңа зур хак биреп, Шамга сәүдә белән чыгарга күндерә. Аның янында Хәдичәнең колы Мәйсәрә дә була. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу сәфәреннән күп табышлар белән әйләнеп кайта.

Бу сәфәр барышында Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең оста итеп эш алып барганын, холкын, инсафлыгын, тәкъвалыгын, шулай ук аның белән булган могҗизаларны күреп (ике фәрештә аны эсселектән канаты белән каплый), Мәйсәрә соклана. Алар Мәккәгә кире кайткач, Мәйсәрә күргәннәрен Хәдичәгә сөйләп бирә. Хәдичәнең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күзе төшүенең сәбәбе бәлки шушындадыр.

Хәдичә, кияүгә чыгу нияте белән, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Нәфисә бинте Мүнәййә исемле хатын аркылы үзен димли.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә акыллы, абруйлы, өстәвенә тәрбияле бу хатынның үтенечен кире какмый, ризалыгын белдерә. Шулай итеп, Хәдичә Мөхәммәднең никахы илә мәңгелек бәхеткә ия була. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Хәдичәгә мәһәр итеп егерме дөя бирүе риваять ителә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ул вакытта — 25 яшь, хәзрәти Хәдичә анабызга 40 яшь була. Яшь аралары 15 ел булса да, алар бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яшәгәннәр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 40 яшь тулгач, күп кенә расүлләр югарыдан вәхи кабул итә башлагандагы кебек, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә пәйгамбәрлек вазифасы килүенең беренче билгеләре күренә башлый. Аңа ялгызлыкны ярату бирелә, ул бик еш Хира тавының мәгарәсендә аулакта калып, берничә көн буена Аллаһыга гыйбадәт кылу белән мәшгуль була һәм аннан соң гаиләсе янына кайта торган була.

Хира тавында Аллаһы аңа беренче аятьләрне иңдергәч тә, ул куркуыннан өенә, Хәдичә янына йөгерә, урынына ятып: «Каплагыз мине, каплагыз мине!» — дип кычкыра. Куркуы басылгач, ул Хәдичәгә барысын да сөйләп бирә: «Миңа ни булды? Мин куркам», — ди. Хәдичә аны юатып: «Юк, юк, валлаһи, Аллаһы Тәгалә сине хурлыкка калдырмый. Син кардәшләрең белән бәйләнештә торасың, мескеннәргә ярдәм итәсең, кешеләргә кунакчыллык күрсәтәсең, аларга язмышның сынауларын күтәрергә булышасың», — дип әйтә.

Шуннан соң хәзрәти Хәдичә аны Әһле Китапны белүче Вәрака янына алып бара. Аларны тыңлаганнан соң, Вәрака: «Бу фәрештәне Аллаһы Тәгалә Мусага да җибәргән иде. Җаным аның кулында булган Зат белән ант итәм, син — бу өммәтнең пәйгамбәре. Синең халкың сиңа ышанмаячак һәм сине куачак», — ди.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Алар мине куачаклармыни?» — дип сорый. Вәрака аңа: «Әйе, әгәр бер кеше син китергән нәрсә белән килсә, аның белән һәрвакыт дошманлашканнар. Эх, әгәр мин шул вакытка кадәр яшәсәм, сиңа, һичшиксез, ярдәм итәр идем!» — ди. Әмма озак та үтми Вәрака вафат була.

Хәдичә радыяллаһу ганһәнең акыллы сүзләре, дөрес киңәшләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килгән затның фәрештә икәнен ачыкларга ярдәм итә.

Хәдичә радыяллаһу ганһә, иң беренче булып, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлегенә иман китерүче була, аның күңелен күтәреп, көч биреп, ярдәм итеп, киңәшләрен биреп, аның өчен ныклы терәк булып яши.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның хакында болай дип әйткән: «Башкалар каршы килгәндә, ул беренче иман китерде, башкалар мине ялганчы дигәндә, ул миңа ышанды, башкалар миннән борылганда, ул үзенең булганы белән бүлеште һәм, башка хатыннардан минем балаларым булмаганда, Аллаһы аннан миңа балалар бирде»[1]. Пәйгамбәребезнең җиде баласының алтысы Хәдичә анабыздан була.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Хира куышлыгында гыйбадәт кылганда, Хәдичә радыяллаһу ганһәнең иренә ашарга китергән вакыты була. Шул вакытта хәтта Раббыбыз Аллаһы аңа Үзе сәлам җибәрә. Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Аллаһы хәзрәти Хәдичәгә сәлам тапшыра! Хәдичәне куыш энҗедән төзелгән, бернинди борчу һәм ару-талу булмаячак җәннәт йорты белән шатландыр!» — дип әйтә[2].

Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Хәдичә анабыз хакында: «Җәннәттә иң зур өстенлеккә ия булган хатыннар: Хәдичә бинте Хөвәйлид, Фатыйма бинте Мөхәммәд, Мәрьям бинте Гыймран һәм Фиргавеннең хатыны Асия бинте Мозаһим булыр», — дип әйткән[3].

---

1 Имам Әхмәд.

2 Әл-Бохари.

3 Ән-Нәсаи, Имам Әхмәд.

Исән чагында ук Аллаһы Тәгаләнең сәламен алган һәм җәннәт белән сөендерелгән изге хатын — Хәдичә анабызга Аллаһының бөек бу хөрмәте бик күп нәрсәләр турында сөйли.

Хәдичә радыяллаһу ганһәнең кылган изге гамәлләре, сабырлыгы, тәкъвалыгы, тугрылыгы барлык мөслимә хатын-кызлар өчен үрнәк булып тора. Бу камил хатын-кыз Хәдичә анабыз турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тарихында бик күп хәтирәләр язылган.

Пәйгамбәрлекнең унынчы, «кайгы елы» дип аталган елны, Расүлебезнең агасы Әбү Талиб вафатыннан соң, 65 яшендә Хәдичә анабыз вафат була. Бу хәлләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бик зур сынау була. Тугрылыклы, яраткан тормыш иптәшен югалткан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик кайгыра, елый, ләкин аның көчле мәхәббәте сүрелми. Ул хәзрәти Хәдичәне еш искә ала, аның дусларын хөрмәтли торган була.

Хәдисләрдә әйтелгәнчә, Фатыйма радыяллаһу ганһә әтисеннән: «Әни җәннәтле булгач, нигә ул вафат булгач еладың?» — дип сорый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аны сагынып еладым», — дип җавап бирә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең көчле мәхәббәте Гайшә радыяллаһу ганһә тапшырган хәдистә дә ачык чагыла: «Мин Хәдичәгә көнләшкән кебек, бер хатынга да шулкадәр көнләшмәдем. Пәйгамбәребез гел аны искә ала иде, әгәр сарык чалса, аны өлешләргә бүлеп, Хәдичәнең дусларына да җибәрә иде. Бервакыт мин Пәйгамбәребездән: «Хәдичәдән башка бу дөньяда бүтән хатын юкмы әллә?» — дип сорадым. Ул миңа: «Ул шундыйшундый иде һәм аннан минем балаларым булды», — дип җавап бирде»[1].

Хәзрәти Хәдичә — Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы Тәгаләдән бирелгән нигъмәт. Ислам динен тарату һәм ныгыту башлангычында Хәдичә радыяллаһу ганһә барлык мал-мөлкәтен, көч-куәтен сарыф итә.

---

[1] Әл-Бохари.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәти Хәдичә анабыздан бик уңган. Ул шушы авыр елларда Пәйгамбәребезгә нык терәк булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә ирләргә: «Хатын алганда матурлыгына, байлыгына карамагыз, диненә, әхлагына карагыз — уңарсыз», — дип киңәш бирә. Аллаһы Тәгалә барчаларыбызга да хәзрәти Хәдичә анабыз шикелле хәләл җефетләр насыйп әйләсен. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм Хәдичә анабыз арасындагы мәхәббәтне бирсә иде, гаиләләребезне нык кылып, Ислам өммәтен ныгытуда үз өлешебезне кертергә насыйп әйләсә иде!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ришат хәзрәт Мифтахов,*

*Арча районы, Мәмсә мәхәлләсе имамы*

*15нче март вәгазе,*

*Рамазан аеның 5нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Ләйләтел-Кадер — Рамазанның асыл кичләренең берсе

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп кылган гыйбәдәтләребезне кабул кылсын. Атлап килгән һәрбер адымнарыбыз саен әҗер-савапларын насыйп итсен. Ниндидер бик җитди сәбәбләр килеп чыгу аркасында гына килеп җитә алмаган мөселман кардәшләребезгә күңелләрендәге булган ниятләренә, күңелләрендәге булган омтылышларына карап, әҗер-савапларын насыйп кылсын. Вәгазьләнеп, иманнарыбызны куәтләргә, дөнья, Ахирәт өчен файдалы сүз, файдалы фикер аңларга һәрбарчабызга насыйп булсын.

Мөхтәрәм җәмәгать, вакыт, гомер тиз уза. Шулай ук Рамазан аеның калган вакыты да тиз үтеп китәчәк. Шулай безнең гомеребез дә тиз уза. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтә:

قَالَ كَمْ لَبِثْتُمْ فِي الْأَرْضِ عَدَدَ سِنِينَ ۞ قَالُوا لَبِثْنَا يَوْمًا أَوْ بَعْضَ يَوْمٍ فَاسْأَلِ الْعَادِّينَ

**«**[Аллаһы Тәгалә, колларын терелткән көнне кяферләргә] **Әйтте: «**[Бик кайтасыгыз килгән] **Җирдә** [һәм кабердә] **ничә ел булдыгыз?»** [Ахирәттә юлыккан чиксез дәһшәткә төшеп, дөньяда яшәгән озын гомерләрен азсынган кяферләр] **Әйттеләр: «Я бер көн, я көннең бер өлеше кадәр** [дөньяда] **булдык. Син** [төгәл] **санап баручылардан сора** [чөнки без бу газап аркасында хисапны бутап бетердек]**».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:112—113.

Чыннан да, уйлап карасак, монда утыручыларның кайсынадыр 30, кемгәдер 40, 50, 60, 70 яшь, узган гомеребезгә карасак, бер көн кебек кенә, сизелмичә узган да киткән. Тагын шуның кадәр яши алсаң да, ул өлеше дә узган гомеребез кебек, шул бер көн кебек тиз узып китәчәк. Гомеребез үтәчәк, мәңгелеккә күчү вакыты җитәчәк. Шуңа күрә вакытның, гомернең кадерен белеп, изге гамәлләр эшләп үткәрү мөһим. Ахырда, дөньяда иман белән, изге гамәлләр кылып гомерен үткәргән кеше, отучы булып, мәңгелек җәннәткә керәчәк. Ә кемнәрдер дөньяда гөнаһ кылып, имансыз булып яшәп, оттырачак һәм югалтучылардан булачак. Әмма ул югалту мең дә, миллион да, миллиард сум да түгел, мәңгелекне югалту. Кешеләр бу мәсьәләгә дөньяда яшәгәндә бик җиңел карыйлар. Рамазан аеның ничәдер көне узып китте: шушы көннәрне ураза тотып, изгелекләр эшләп үткәрүчеләр — отучылар, бәхетле кешеләр. Рамазан аенда сәбәпсез ураза тотмаучы бик күп саваплар югалтучы булыр. Кыйммәтле вакыт узып китеп бара, һәм бу саваплы вакытны берничек тә кире кайтарып булмый: Рамазан аеның бер көне дә бик кыйммәтле. Моның турында сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем Рамазан аенда сәбәпсез бер көн уразасын калдырса, шул уразаның савабын гасыр буе, ягъни гомер буе ураза тотса да, кире кайтара алмас», — дип әйткән.

Вакыт ничек үткәрсәң дә үтә. Отучылар булу өчен тырышыйк, җәмәгать! Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шушы айда күбрәк изгелекләр эшләргә өндәп: «Аллаһы (Аның рәхмәте) бу айда сезгә килә,

сезнең белән була, сезнең яхшылык эшләгәнегезне күзәтә һәм фәрештәләр алдында сезнең белән горурлана», — ди. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аеның соңгы ун көненә аеруча игътибар биргән. Шул хакта хатыны Гайшә радыяллаһу ганһә: «Рамазанның соңгы ун көне җиткәч, Мөхәммәд төннәрен йокламыйча, намазда үткәрә иде, үзенең якыннарын да намазга уята иде», — дип әйткән.

Нәкъ менә соңгы 10 көннең, так төннәренең бер төне Кадер төненә, Кадер кичәнә туры килгәнне беләбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә: «Кадер кичәсен Рамазанның соңгы 10 көннең так төннәреннән эзләгез», — дип әйткән. Табарга, туры китерергә тырышырга, ягъни шул төннәрне гыйбәдәттә үткәрергә, догалар кылырга куша. Ул бәрәкәтле төндә гыйбәдәт кылучыларның догалары кабул була, гөнаһлары ярлыкана, Аллаһының рәхмәте төшә. Кайбер кешеләр шушы максатка ирешү, Кадер кичен туры китереп, гыйбәдәттә үткәрү максатыннан, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үтәгән, аның сөннәте булган игътикаф гамәлен кылалар. Андый кешеләр Рамазанның соңгы 10 көнен мәчеттә үткәрәләр, намаз укыйлар, Коръән укыйлар, ифтар-сәхәрләрен дә шунда үткәрәләр, шунда гөнаһларыннан пакъләнергә тырышалар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөендереп әйкән: «Кем Кадер кичәсен иман белән, Аллаһыга өмет белән, ихлас гыйбәдәттә үткәрсә, ул кешенең элеккеге гөнаһлары ярлыканыр».

Коръәни Кәримдә «Әл-Кадр» (Кадер) сүрәсе бар. Ул Кадер кичәсенә багышланган.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةِ الْقَدْرِ ۞ وَمَا أَدْرَاكَ مَا لَيْلَةُ الْقَدْرِ ۞ لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ ۞ تَنَزَّلُ الْمَلَائِكَةُ وَالرُّوحُ فِيهَا بِإِذْنِ رَبِّهِم مِّن كُلِّ أَمْرٍ ۞ سَلَامٌ هِيَ حَتَّى مَطْلَعِ الْفَجْرِ ۞

**«Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән! Һичшиксез, Без аны** [мәңгелек могҗиза булган Коръәни Кәримне] **Кадер кичәсендә** [Ләүхелмәхфүздән тулы килеш беренче кат күккә] **иңдердек. Кадер кичәсенең нинди икәнен син каян белә аласың? Кадер кичәсе** [Кадер кичәсе булмаган] **мең айдан да хәерлерәк.** [Шул сәбәпле, аңарда кылынган изге гамәл сиксән өч ел да дүрт ай буена бертуктаусыз кылынган гамәлгә тиң генә түгел, аннан да фазыйләтлерәк]**. Ул кичәдә, Раббыларының рөхсәте белән, фәрештәләр һәм Рух** [дип тә аталган Җәбраил [галәйһиссәлам] **һәртөрле эш өчен иңәләр. Таң атканчы** [фәрештәләр очраткан һәр иманлы ир һәм хатынга сәлам биргәннәре өчен] **ул** [кичә] **иминлек** [булыр]**».**

«Әл-Кадр / Кадер кичe», 97:1—5

Кадер киче — «кодрәт төне», «изге төн», «саваплы төн», «тәкъдир төне» мәгънәләрен аңлата. Шушы төндә бик зур вакыйга булган. Изге Коръән китабы иңә башлаган. Бер шиксез кешелек тарихында бу бик зур вакыйга. Коръән — Аллаһы сүзе, Аллаһы кагыйдәсе. Коръән кешегә Аллаһы белән ике арада, кеше белән кеше арасында нинди мөнәсәбәт булырга тиешлеген аңлатучы китап.

Сүрә дәвамында Аллаһы Тәгалә: «Кадер кичәсенең нинди икәнен син каян белә аласың?» — дип сорый. Аннан Үзе җавап биреп, Кадер кичәсенең 3 аерылып тора торган сыйфаты, өстенлеге турында әйтә: «Кадер кичәсе мең айдан хәерлерәк, мең айдан өстенрәк, бөегрәк, саваплырак. Бу төндә эшләгән изгелек, яхшылык, гыйбәдәт савабы буенча мең айда кылган изгелектән өстен, мең айда кылган гыйбәдәттән өстен. Мең ай 83 ел, 4 айга тәңгәл була. Бу — озак яшәүче бер кеше гомеренә тигез. Аллаһы Тәгаләнең, кешеләргә карата булган нинди рәхмәте, юмартлыгы бу. Аллаһы Тәгалә бер төндә кылган изгелек өчен ни кадәр савабын арттыра. Ягъни шушы төнгә туры килеп 2 рәкәгать кенә намаз укысак, 83 ел 4 ай көн саен шушы 2 рәкәгать намаз укыган кебек, савап языла. 2 бит кенә Коръән укысак, 83 ел 4 ай буе көн саен 2 бит

Коръән укыган кебек савап язылачак. Дога кылсак, Аллаһыдан дөнья, Ахирәт нигъмәтләрен сорасак, 83 ел 4 ай буе шул доганы кылган кебек була. Шушы төнне туры китереп, 100 сум садака бирсәк, 83 ел 4 ай көн саен 100 сум садака биргән кебек языла. Безгә, мөселманнарга, шуны аңлап, шушы зур форсаттан кулланып калырга кирәк. Шушы савапларга ирешү өчен, без санаулы калган төннәрдә бөтен көчебезне кулланып калырга тиешбез.

Кадер кичәсенең икенче аерылып тора торган сыйфаты, өстенлеге: бу төндә Аллаһы әмере белән Җәбраил галейһиссәлам һәм башка фәрештәләр җиргә төшәләр. Алар уяу торып, гыйбәдәттә булучы мөселманнар белән исәнләшәләр, аларга сәлам бирәләр.

Кадер киченең өченче өстенлеге: бу төндә тынычлык, иминлек була. Аллаһы Тәгалә Үзенең тынычлыгын, бәрәкәтен иңдерә һәм бу иминлек, бәрәкәт таң беленгәнче дәвам итә.

Күп кешеләр белмичә яки ваемсызлык аркасында бу фазыйләтле төнгә игътибар бирмиләр, гыйбәдәтләрен арттырмыйлар. Шуның аркасында алар бернинди акчага да сатып алып булмый торган, бары ихлас иман белән генә ирешеп була торган, чын, хакыйкый бәхет, тынычлыкны тоя алмыйча калалар.

Җәмәгать, шушы мең айдан хәерлерәк булган Кадер кичәсен табырга тырышыйк, шул кичәне фәрештәләр сокланырлык итеп гыйбадәттә, изгелектә үткәрергә омтылыйк. Шушы бәрәкәтле төндә тагын бер елга җитәрлек изгелек, тәкъвалык җимешләрен җыеп калырга тырышыйк. Аллаһы Тәгалә кылган изгелекләребезне кабул кылсын. Изгелекләребезнең файдаларын дөньяда һәм Ахирәттә күреп сөенергә насыйп итсен. Җәннәтләрдә күрешергә, бер-беребезне күреп шатланырга һәрбарчабызга насыйп кылсын.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рифат хәзрәт Ибраһимов,*
*Кукмара районы Зур Сәрдек авылы имам-хатыйбы,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме.*

*22нче март вәгазе,*

*Рамазан аеның 12нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# «Интернеттан фәтва алма!»

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватшәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп кылган гыйбадәтләребезне кабул кылсын. Атлап килгән һәрбер адымнарыбыз өчен әҗер-савапларын насыйп итсен. Ниндидер бик җитди сәбәпләр белән килеп җитә алмаган мөселман кардәшләребезгә күңелләрендәге булган ниятләренә, омтылышларына карап, Аллаһы Тәгалә савапларын насыйп кылсын. Вәгазьләнеп, иманнарыбызны куәтләргә, дөнья, Ахирәт өчен файдалы сүз, файдалы фикер аңларга һәрбарчабызга насыйп булсын.

Аллаһы Тәгалә кешеләргә, туры юл күрсәтер өчен, Коръән китабын иңдерде. Әлхәмдүлилләһ, безнең бүгенге көндә гыйлем алырга мөмкинлекләребез бик күп. Бүгенге нәсыйхәтем шуның белән бәйле.

Намазны хошугъ белән укырга кирәклеген барыбыз да беләбез. Ләкин кайчагында кешеләр, хошугълыкка ирешәм дип, төрле хаталар җибәрергә мөмкин. Мисал өчен, берәүләр, миңа шулай эшләргә өйрәттеләр дип, Аллаһы Тәгаләне ниндидер бер образ рәвешендә күз алдына китереп маташа. Ягъни аңа, шулай эшләсәң, Аллаһы Тәгаләне синең каршыңда кебек хис итәчәксең, шул рәвешле хошугълыгың арта, дип өйрәткәннәр. Әмма бу очракта кеше

кемгә гыйбадәт кыла соң? Үз башында үзе үк уйлап чыгарган шул ниндидер образга. Димәк, потларга табынучылар белән шушы кеше арасында нинди аерма кала? Потка табынучы теле белән шәһадәт кәлимәсен әйтсә дә, ул потка табынучы булып кала. Ә без бит беләбез: Аллаһы Тәгаләгә тиң бернәрсә дә юк, Ул урын һәм вакыт кысалары белән чикләнмәгән, Ул күктә дә, җирдә дә түгел — болай фикер йөртү ялгыш! Аңа охшаган бер генә нәрсә дә юк! Без Аллаһының нинди булуын күз алдыбызга китерә алмыйбыз, моңа безнең акыл сәләтебез дә җитмәс иде. Ул кеше сыман Тәхет өстендә утырып тормый.

Иман һәм гакыйдәгә бәйле әйберләрне кешеләргә аңлата башлагач, алар күпләгән сораулар яудыра башлыйлар: «Ә менә мин бер видеода болай дип ишеткән идем...», «Ә мин бер китапта Аллаһыны Тәхеттә дип укыган идем»... Нинди китапта? Кайсы телдән тәрҗемә ителгән? Авторы кем аның? Шушы сүзләрне әйткән кеше хакыйкый гыйлем иясеме?

Әгәр без Ислам динен өйрәнергә телибез икән, иң элек, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәткәннәрне өйрәнергә кирәк. Динне аңлау өчен, тел белү генә дә җитми, шәригать белеме кирәк! Димәк, ниндидер шәрыкъ телләре белгечләре (востоковедлар) тәрҗемә иткән китаплардан үзлектән уку — ул әле динне өйрәнү түгел. Аллаһы Тәгалә Коръәндә еш кына «фикерле белүчеләр өчен» дигән фикерне кабатлый. Шуңа да иң элек анализларга, фикер йөртергә өйрәнергә кирәк. Аллаһы Тәгалә безгә юкка гына акыл бирмәгән. Ибраһим галәйһиссәламне генә искә алыйк. Ул үз халкын туры юлга күндерер өчен аларны фикерләргә этәрә. Ул аларга күк җисемнәре турында уйланырга, аларның илаһ була аламы-юкмы икәнлеге турында уйларга куша. Фикерләгәннән соң, аңлап була: әлбәттә, юк, чөнки алар бер пәйдә була, бер күздән юк була, хәрәкәт итә, алар мәхлуклар.

Икенче мисал, төннең өченче өлешендә Аллаһы Тәгалә күкләрнең беренче катына иңә, дип әйтәләр һәм шушы сүзләрне турыдан-туры аңлыйлар. Ләкин, җәмәгать, сәхабәләр һәм тәбигыйннәр безгә әлеге сүзләрне ни рәвешле аңларга кирәклеген аңлатып калдырганнар инде: Аллаһы Тәгалә

төннең бер өлешенә өстенлек бирә, шул вакытта Үзенең рәхмәт фәрештәләрен иңдерә, фәрештәләр белән бергә Аның рәхмәте һәм бәрәкәте иңә. Мәсәлән, мондый мисал китерик: фәлән әмир фәлән шәһәрне төзегән. Әлеге җөмләдән әмирнең үз куллары белән һәр йортны торгызып, барысын да үзе эшләгән дип аңламыйбыз бит. Әлбәттә, аның ярдәмчеләре булган, ул аларга төрле эшләр йөкләгән, һәм күп кешеләрнең көче белән әлеге шәһәр төзелгән. Шулай ук шәһәр мэры юллар салган дибез, әлбәттә, ул бит аны үз физик көче белән эшләмәгән, аның җитәкчелеге астында булган кешеләр, аның әмерен үтәп, ул юлларны салган. Аллаһы Тәгалә мондый мисаллардан өстен, әлбәттә, әмма аңлар өчен бу мисаллар җитә.

Димәк, максат — дөрес гыйлем алуда, чөнки бар нәрсә дә гыйлемгә кайтып кала. Сәхабәләр, Әһле Сөннәт галимнәре өйрәтеп калдырган гыйлемнәргә кире кайтырга кирәк. Һәм әлеге гыйлемне интернеттан яки социаль челтәрләрдән түгел, ә чыннан да гыйлем алган, укытырга рөхсәте булган күркәм остазлардан алу бик мөһим. Әгәр бер укытучы гакыйдә буенча специалист булса, гакыйдәне аннан өйрәнергә кирәк; әгәр остаз Коръән һәм тәҗвид белгече булса, аннан шул гыйлем таләп ителергә тиешле. Шуны һәрвакыт истә тотарга кирәк: кешеләр гыйлемне гомер буе алсалар да, һәрнәрсәдә өстенлеккә ирешә алу мөмкин түгел, шуңа күрә кеше һәрвакыт үзе бер өлкәне сайлап ала һәм махсус шуны тирәнтен өйрәнә.

Сәләфләр дип нәкъ менә элекке заманда дөрес гыйлемгә ия булган кешеләрне атаганнар, алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң беренче гасырларда яшәгәннәр, алардан турыдан туры гыйлем алган кешеләрне дә сәләфләр дип атаганнар. Ләкин бүгенге көндә без шуны күрәбез: үзләрен бик гыйлемле кешеләргә санап, кемдер үзен дә сәләфит дип атарга җөрьәт итә. Без ваһһабчылык тарафдары булган кешеләрне катгый рәвештә шулай атап йөртүләренә каршы булырга тиеш, чөнки шул рәвешле алар күп кешеләрнең башын гына бутый. Бүгенге көндә әлеге сүзнең тискәре мәгънә төсмере алуы бик кызганыч. Әгәр кеше чыннан да сәләфләр юлын-

нан бара икән, бер сүзем юк, ләкин моны дөрес аңлау шарт, чөнки гакыйдә бик мөһим фән. Сәләфләр беркайчан да Аллаһы Тәгаләгә урын бирмәгән, юнәлешләр кысалары белән чикләмәгән, шул хактагы аятьләрне тәрҗемә итмәгәннәр, үзләре аңлаганча шәрехләмәгәннәр. Ә без бүген ни күрәбез?! Күп кеше, әгәр ул сәләфит булса, димәк, сәләфләр юлыннан баручы, дип уйлый. Дөреслектә, алар бары тик гыйлемне өстән-өстән генә аңлаучылар, турыдан туры мәгънә генә бирүчеләр. Чын сәләфләр беркайчан да кинаяле аятьләрне турыдан туры тәрҗемә итмәгәннәр. Алар ул аятьләрне шул килеш калдырган, башка аять һәм хәдисләр китереп шәрехләмәгән, ә бары тик: «Ничек бар, ничек әйтелгән булса, шулай иман китерәбез», — дип әйткәннәр. Мәсәлән, «истәвә галәл-гарш» кәлимәсен алар «әл-Гарешкә истәвә кылган» дип кенә калдырганнар, ягъни сәләфләрнең ысулы — ничек бар, шулай калдыру.

Бүгенге көндә без гарәп телен бөтен нечкәлекләре белән белеп бетермибез. Әгәр соңгы гасырларда яшәгән галимнәр сәләфләр чорында яшәгән булсалар, алар да шул килеш калдырган булырлар иде, чөнки моңа ихтыяҗ булмас иде. Шулай ук, әгәр әүвәлге чор галимнәре соңгы гасырларда яшәгән булсалар, алар да мондый аятьләргә аңлатма биргән булырлар иде, чөнки заманнар башка: Ислам динен гарәп булмаган бик күп халыклар кабул итә башлады. Аларның гарәп телен белүләре чикле, хәтта гарәпләр үзләре дә телдә ялгышлыклар җибәрәләр, чөнки тел тагын да катлаулана бара.

Шуңа күрә дә сәләфләр исемен пычратырга ярамый. Сәләфләр чоры — иң яхшы чор, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң булган иң күркәм өч гасыр. «Истәвә» сүзен Тәхетенә «утырды, ләкин без күзаллаганча утырмады», дип тәрҗемә итәргә ярамый, чөнки болай шәрехләгәндә, үзең аңлаганча тәрҗемә иткәндә, сәләфләр юлыннан тайпылган буласың. Шулай ук «вәҗеһ», «вәҗһуллаһ» сүзләрен дә «Мединский курс» яки «Бәйнә ядәйк» дәрәҗәсендә тәрҗемә иткәндә, «вәҗеһ» — ул «йөз» килеп чыга. Ләкин сәләфләр бит «вәҗһуллаһ»ны Аллаһының йөзе яки тәненең өске өлеше дип тәрҗемә кылмаганнар. Аллаһы Тәгалә башка бер мәхлукка да охшамаган,

Аллаһ җисем түгел, Ул тәннән һәм әгъзалардан тормый. Сәләфләр чорында кешеләр моны болай да аңлаган, чөнки гарәп теле алар өчен ана теле булган, аңлатып торуга ихтыяҗ булмаган: шул мохиттә туып, алар моны сеңдереп үскәннәр, гарәп теле кагыйдәләрен өйрәнү кирәк булмаган. Ә безгә гарәп телендә камил сөйләшә-аңлаша алу өчен нәрсә эшләргә кирәк? Гыйлем алырга! Әле күпме гыйлем алырга тырышсак һәм көн-төн укысак та, без инде алар дәрәҗәсенә җитә алмаячакбыз. Бик-бик тырышсак та, без алган гыйлем, аларныкы белән чагыштырганда, диңгездәге тамчы сыман булачак. Алар белгәннәр, дөрес аңлаганнар, һәм элек беркем дә шәрех кылмаганга, алар да үзләренчә шәрехләргә курыкканнар.

Соңрак, кешеләр Аллаһы Тәгаләгә ширек китерә башлагач, алар алдында аңлатуга ихтыяҗ килеп баскан. Вәҗеһ ул «йөз» генә түгел, аның башка мәгънәләре дә бар, мәсәлән, җисем, нәрсәнең дә булса өсте яки юнәлеше («җиһа» сүзе дә аның тамырдашы). Нигә кешенең йөзен дә «вәҗеһ» дип атыйлар, чөнки ул тәненең шул әгъзасы белән кая да булса юнәлә.

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَلِلَّهِ الْمَشْرِقُ وَالْمَغْرِبُ ۚ فَأَيْنَمَا تُوَلُّوا فَثَمَّ وَجْهُ اللَّهِ

> «**Көнчыгыш та, көнбатыш та — Аллаһныкы.** [Шулай булгач, намаз укыр өчен] **Кая гына юнәлсәгез дә, Аллаһының кыйбласы шунда булыр...**»

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:115

Ибне Габбастан китерелгән хәдистә вәҗһуллаһ — кыйбла юнәлеше дип аңлатыла: сәфәрдә вакытта нәфел намазын кылганда ат яки башка атланып йөри торган хайван кайсы тарафка юнәлсә, кыйбла шул тарафта була.

Әлеге аятьне турыдан туры аңлаучылар Аллаһының йөзе шул тарафта, дип фикер йөртәчәк, ягъни сәләфләр тәкъдим иткән ысулдан — тәрҗемә итми шул килеш калдырудан — ерагаячак.

Имам әл-Газали аңлатуынча: «Сәләфләрнең ысулы — башка (фарсы, төрки һ.б.) телләргә тәрҗемә итмәүдә». Ягъни, сәләфү салих юлыннан баруның бер шарты — тәрҗемә итмәү. Әгәр тәрҗемә итәсең икән, димәк, үзлектән ниндидер мәгънә саласың, нәтиҗәдә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кулланмаган төшенчә яки Коръәндә аңлатмасы килмәгән сүз кулланган буласың. Шулай итеп, сәләфләр юлыннан ерагаясың — дөрес юлда буласыңмы, ялгыш юлга кереп китәсеңме, билгесез, Аллаһы гына белүче. Моның хакта инде бик күп аңлатканнар, бик күп игътибар юнәлткәннәр.

Хәзерге заман галимнәрендә генә дә түгел, ә сәхабәләрнең тормыш азагында — тәбигыйннәрнең яшәү чорында да мондый проблемалар килеп чыга башлаган. Шул вакытта ук мөҗәсимнәр, ягъни Аллаһыга тән, әгъза, хис кебек сыйфат өстәүчеләр булган. Шул чор галимнәре үк аларның ялгыш юллда булуларына дәлилләрен китергән, аларның уйдырмаларын кире каккан, Аллаһыны мондый сыйфатлар белән сыйфатлау дөрес түгеллеген аңлатып бик күп хезмәтләр язганнар, шул хезмәтләрнең кайберләре буыннан буынга тапшырылып, бүгенге көнгә кадәр килеп ирешкән.

Заманнар үтә, буыннар алмашына, гыйлем җитмәү сәбәпле, күп нәрсә онытыла, ахыр чиктә, бу мәсьәләләр кабат калкып чыга. Ник дигәндә, гакыйдә мәсьәләләрен күтәрү җиңел түгел: аларны читләтеп узырга тырышалар, аңлатмыйлар, гыйлем җитми. Әгәр гаилә башлыгы үз туганнарына, хатыны һәм балаларына һәрвакыт иман нигезләрен аңлатып килсә, ә имамнар мөнбәрдән: «Аллаһыны күз алдына китерергә ярамый. Аллаһы җисем түгел, ниндидер урын биләми, берни белән дә чикләнмәгән, бер якта да урнашмаган һәм бернәрсәгә дә охшамаган. Аллаһы матди җисем формасын алмый, урынга мохтаҗ түгел, Ул, гомумән, бернәрсәгә мохтаҗ түгел. Аллаһының бер генә сыйфаты да мәхлукларның сыйфатларына охшамаган. Аллаһының тән әгъзалары юк, чөнки Ул җисем түгел», — дип гел тукып торсалар, аңлатып барсалар, халык арасында дөрес аңлау булыр

иде, иншәАллаһ. Интернеттан теләсә-кемне тыңламаслар иде. Шуңа да гакыйдәгә бәйле мәсьәләләр хакында һәрвакыт һәм һәр мөмкинлек саен сөйләргә кирәк!

Әгәр Коръән уку төрләре, тәҗвид, әхлак хакында гына сөйләсәк, кешеләрнең гакыйдәләрен бозып, башларын катыручылар үзеннән үзе табылачак. Иң элек кол хатын хакындагы хәдисне китерәчәкләр, ләкин аны үзләренчә шәрехләп аңлатачаклар. Янәсе, пәйгамбәребез Мөхәммәд бер кол хатыннан: «Аллаһы кая?» — дип сораган да, ул хатын: «Күктә», — дип җавап биргән. Ә ул кешеләр аны үзләренчә аңлаталар, янәсе, Аллаһы Тәхеттә, ничек булдырасың, шулай аңла, ләкин ышан». Әгәр без ничек дөрес аңларга кирәклеген һәрдаим сөйләсәк, ул кешеләрне ялгыш юлга кереп китүдән саклаган булыр идек. Гали радыяллаһу ганһе: «Гыйлем малдан кадерлерәк, чөнки гыйлем дөрес юлдан тайпылудан сине саклый. Ә син, урламадылармы икән дип акчаңны саклыйсың».

Яхшыны да, яманны да яратучы Аллаһы Тәгалә, барысы да Аның тәкъдире белән була. Әгәр Аллаһы Тәгалә кемне дә булса туры юлдан тайпылдырса, аны беркем дә туры юлга күндерә алмаячак, шулай ук, әгәр кемне дә булса Аллаһы Тәгалә туры юлга күндерсә, аны беркем дә аннан тайпылдыра алмаячак. Болар барысы да Әһле Сөннәт вәл-Җәмәгать гакыйдәсе. Боларны да кешеләргә һәрвакыт аңлатырга кирәк. Һәркем бу мәсьәләдә үзенең җаваплылыгын аңларга бурычлы: җәмгыятебезне сәләфләргә хас булмаган чит гакыйдә сеңдерелүдән саклыйбыз дисәк, бу мәсьәләләрне кешеләргә аңлату — безнең бурычыбыз.

Аллаһы Тәгалә алган һәм тараткан гыйлемнәребезне бәрәкәтле кылсын иде. Әмин, йә Раббил-галәмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рашид хәзрәт Сибгатуллин,*
*Казан Ислам университеты укытучысы,*
*Ислам фәннәре докторы*

*29нчы март вәгазе,*

*Рамазан аеның 19нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Монафикълык һәрвакыт ачык булмаска мөмкин

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрне, анда булган барча мәхлукларны юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә барча мактау, шөкраналарыбыз булсын. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә куңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез һәрвакыт ирешеп торса иде.

Гарәп телендә әл-монафикъ «нифак» сүзеннән төрләнеп ясалган. Нифак — яхшылыкны күрсәткән булып, начарлыкны яшереп калдыру дигәнне аңлата. Ислам динендә «монафикъ» дип, кешеләр алдында үзен мөселман итеп күрсәтеп, чынлыкта көферлегендә калучыларга әйтелә.

«Әл-Бәкара» сүрәсенең 8нче аятендә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай ди:

وَمِنَ النَّاسِ مَن يَقُولُ آمَنَّا بِاللَّهِ وَبِالْيَوْمِ الْآخِرِ وَمَا هُم بِمُؤْمِنِينَ

**«Кешеләр арасында: «Аллаһыга һәм Ахирәт Көненә иман китердек», — дип әйтүчеләр бар, әмма алар иман китерүчеләрдән түгел».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:8

Монафикълар дөньяда үзләрен мөселман итеп күрсәтеп, Ислам нуры яктылыгыннан файдалансалар да, үлгәннән соң, шул нур нигъмәтеннән мәхрүм булып, көферлек караңгылыгы эчендә калырлар.

أَوْ كَصَيِّبٍ مِّنَ السَّمَاءِ فِيهِ ظُلُمَاتٌ وَرَعْدٌ وَبَرْقٌ يَجْعَلُونَ أَصَابِعَهُمْ فِي آذَانِهِم مِّنَ الصَّوَاعِقِ حَذَرَ الْمَوْتِ ۚ وَاللَّهُ مُحِيطٌ بِالْكَافِرِينَ

**«Яки** [аларның хәле] **караңгылык, күк күкрәү һәм яшен китереп** [күктәге болыттан] **яуган көчле яңгыр** [астында калучыларның хәле] **кебек. Ул** [монафикълар күк күкрәү гөрелтесеннән] **яшен сугып үлүдән куркып, колакларына бармакларын тыгалар. Аллаһы исә — ул кяферләрне** [Гыйлеме һәм Кодрәте белән] **Чолгап алучы».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:19

Ягъни монафикълар, хак динне белергә теләмичә, бармакларын колакларына тыгалар. Алар өчен диннәрен калдырып, Исламга килү үлем белән бер.

Монафикълар элек тә булган, хәзер дә арабызда бар. Үзләренең бу чирләрен яшерергә тырышсалар да, аларның кайбер билгеләре күренә.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: «Монафикъны өч төрле сыйфат аерып тора: сөйләгәндә ялганлый, вәгъдә бирсә, боза, әманәткә хыянәт итә».

Тормышта, чыннан да, мөселманнар арасында мондый кешеләрне күп күрергә туры килә. Күп мөселманнар ялганлыйлар, вәгъдәдә тормыйлар, ышанычлы түгелләр. Берәр эш эшләтсә, килешенгән хакны түләми. Монафикълык чире белән авыручы мөселманнар күп.

Әйтергә кирәк, шулай ук кайбер мөселманнар, Рамазан аенда бик тәкъва булып, гыйбадәтләрен арттыралар. Бер көн калдырмыйча тәравих намазларына йөриләр, ләкин Рамазан ае бетү белән, икенче Рамазанга кадәр, аларны мәчеттә күрмисең. Аллаһы Тәгалә безгә Рамазан аенда гына түгел, һәрвакыт гыйбадәттә булырга боерды.

Тагын бер хәдисендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Монафикълар ястү һәм иртәнге намазларга мәчеткә килмәс», —

ди. Алар өчен бу бик авыр йөк булып тора. Монафикълык чире кермәсен өчен, без үзебезне дә һәрдаим тикшереп торырга тиешбез.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Хөзәйфә радыяллаһу ганһегә монафикълар исемлеген биргәч, Гомәр Әл-Хаттаб: «Мин бу исемлектә юкмы икән», — дип куркып йөргән. Сәхабәләр бу сыйфаттан курыкканнар.

Монафикълар турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

صُمٌّۢ بُكۡمٌ عُمۡيٌ فَهُمۡ لَا يَرۡجِعُونَ

«[Ул монафикълар хакыйкатькә карата] **Саңгырау, телсез, сукырлар.** [Моннан соң үзләре тайпылган туры юлга кире] **Кайта алмаячаклар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:18

Монафикъларга нинди җәза булачак соң? Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә «әл-Бәкара» сүрәсенең 10нчы аятендә җавап итеп әйтә:

فِي قُلُوبِهِم مَّرَضٌ فَزَادَهُمُ اللَّهُ مَرَضًا ۖ وَلَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ بِمَا كَانُوا يَكْذِبُونَ

«**Аларның күңелләрендә** [шикләнүгә һәм монафикълыкка бәйле бер] **чир бар. Аллаһы** [бер-бер артлы аятьләр иңдереп] **аларның чирләрен көчәйтте.** [Ышанмаган хәлдә иман китердек дип] **Ялган сөйләүләре сәбәпле, алар өчен тилмерткеч бер газап».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:10

Аллаһы Тәгалә барчабызга да тәүфыйк-һидаять биреп, саулык-сәламәтлек белән тыныч көннәрдә бер Үзенә генә гыйбадәт кылып яшәргә һәм бу дөньядан киткәндә дә иман белән китеп, Ахирәттә Фирдәвес җәннәтләрендә очрашырга насыйп итсә иде!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Арча районы Ташкичү авылы имам-хатыйбы*

*Рәдис хәзрәт Галәветдинов*

*5нче апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 26нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Рамазан ае белән саубуллашу

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Адәм баласына иксез-чиксез нигъмәтләр биреп, бер генә мизгелгә дә Үз рәхмәтеннән ташламаучы, ата-анабызга караганда да җитмеш мәртәбә ныграк яратучы Аллаһы Раббыбызга дан вә мактаулар булсын. Барча галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән, калебләребезнең табибы һәм нуры булып торучы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Яхшы әйбер тиз, күз ачып йомганчы үтә дә китә, гәрчә аны зарыгып ел дәвамында көтсәң дә. Әле генә курка-курка, булдыра алырбызмы-юкмы дип, шикләнә-шикләнә ураза тота башлаган идек. Сәхәр һәм ифтарлары, күмәк тәравих намазлары белән ел буе сагындырып торган Рамазан аеның соңгы көннәренә дә килеп җиттек, әлхәмдүлилләһ.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән шушы көннәргә ирешкәнбез икән, күбрәк шөкер итсәк иде. Рамазан аеның соңгы көннәрендә аеруча уяу булу кирәк, чөнки Рамазан аенда фарыз уразасын камил рәвештә тоткан мөэмин-мөселманнарга Аллаһы Тәгалә бик зур нигъмәтләр вәгъдә итә.

Рамазан аеның шәрәфле соңгы көннәре — һәр мөселман өчен тәүбә кылу, Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатенә ирешү өчен мөмкинлек вакыты. Әлхәмдүлилләһ, без ай буе яман гадәтләрдән котылырга, күбрәк күркәм гамәлләр кылырга тырыштык: күзләрне рөхсәт ителмәгән җирләргә караудан, телне буш сүз сөйләүләрдән, бәхәсләрдән, колакларны гайбәт тыңлаудан, аякларны харам урыннарга барудан, кулларны харамнарга кагылудан

тыйдык. Икенче төрле әйткәндә, мөселманның көндәлек кагыйдәләрен үтәүгә бик зур көч сарыф иттек. Хәзер шул күнекмәләрне ел буе дәвам итә алсак иде. Рамазан аенда тырыштык, инде хәзер ел дәвамында ял итсәк тә була, дип фикерләргә ярамый, чөнки Рамазан аенда кылган гамәлләребез безгә алга таба да шул тәртиптә яшәргә этәргеч бирү өчен кирәк.

Рамазан аеннан соң мондый «ялга китүләр» булмасын өчен нишләргә кирәк соң? Әйдәгез, фикерләп карыйк. Иң элек, Рамазан ае җиткәндә кеше, гадәттә, нинди максатлар куя, шуны искә алыйк: көн саен Коръән уку, булдыра алган кадәр хатем чыгу, нәфел намазларны даими укып бару, изге эшләр кылуны арттыру, нәфесеңне тыю, гөнаһ һәм хата гамәлләрдән булдыра алган кадәр ерагаю, әгъзаларыбызны һәр төр яманнардан һәм харамнан саклау. Менә боларның барысын да тәкъвалыгыбыз артсын өчен ихлас рәвештә кылырга тырышабыз, шулай бит? Нәрсәдер җиңел бирелде, нәрсәгәдер кул-аяк барып җитмәде, ихтыяр көче җитмәде, кайчагында ардырды, талчыктырды, ләкин, тулаем алганда, Рамазанның соңгы көннәрендә күңелдә рәхәт моңсулык, сагыну хисе уяна башлый. Әле Рамазан ае тәмамланып кына килә, шулай да аны никтер җибәрәсе килми, тагын да дәвам иттерәсе килә.

Ә хәзер, мөхтәрәм җәмәгать, узган елгы Рамазан аен исебезгә төшерик: анда да шул халәт иде: бик читенсенеп кенә җибәрдек, саубуллашасы килмәде, гаеттән соң да мәчеткә килергә тырыштык, нәфел гыйбадәтләрен калдырмаска иде, дип нәфесебезне контрольдә тотарга маташтык, шәүвәлнең алты көнен тагын ураза тоттык. Тик атналар үтә торды, гыйбадәтләр акрынлап азайды, дөнья мәшәкате кабат безне чолгап алды. Быелгы Рамазанны инде кабат авырсынып каршы алган идек, шулай бит? Һәм шулай ук яңа көч белән без нәфесебезне буйсындырдык, йөгәнләдек.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә: «Уразаның кабул булуның бер билгесе — ул мөселманнарның башка вакытта да ел буенча Рамазан аендагы кебек гыйбадәттә булуы», — дип әйтелгән.

Шушы Рамазан аенда ирешкән халәтне, хошугълык хисен, күңел пакьлеген ничек саклап кала алабыз соң? Әйдәгез, берничә ысулны карап китик.

1. Һәр кылган эшебезне Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен эшлим, дип ниятлик. Ягъни, нәрсә белән генә шөгыльләнсәк тә — гыйбадәт кылабызмы, дөньяви эшләр белән шөгыльләнәбезме — ниятебез һәрвакыт дөрес булырга тиеш. Кеше күрсен өчен түгел, Аллаһы безне риядан сакласын, ә һәр эшебезне чын ихластан кылсак иде. Һәр кечкенә генә гамәлебез алдыннан да «Бисмилләһ» әйтүне гадәткә кертсәк иде.

2. Биш вакыт намазыбызны вакытында үтәп барсак иде. Мәчетләрдә җомга намазында яки тәравихта гына түгел, ә теләсә-кайсы намазда рәтләр тулса иде. Әлхәмдүлилләһ, тәравихка килгән кебек иртәнге һәм ястү намазына да мәчеткә килергә ниятләсәк иде. Шуны да истән чыгармаска кирәктер: фарыз намазлары гыйбадәтнең ташлары булса, сөннәт һәм нәфел намазлары — аларның цементы. Бу нәфел намазлар — доха, тәһәҗҗүд, тәсбих һәм башка өстәмә намазлардыр. Әлеге гыйбадәтләр Рамазанда гына үтәлә торган булып калмыйча, даими гадәткә керсәләр иде.

3. Рамазан аенда күпләребез тырышып Коръән укыды, хәтем кылды, көненә кимендә 20—30 бит укырга тырыштык. Рамазан бетү белән бу гадәтне дә бер читкә куймасак иде. 20—30 түгел, 2—3 бит булса да һәр көн Коръән укырга тырышсак иде. Микъдар артыннан куу шарт түгел, көч-хәлегездән килгәнчә укысагыз, һичшиксез, нәтиҗәсе яхшы булыр. Хәтта көненә 3 кенә аять укысагыз да. Иң мөһиме, дәвамлы булсын, туктатмагыз. Әз булсын, ләкин сыйфатлы. Шул аятьләрне мәгънәсенә төшенергә тырышып, тәфсирен карап, ихластан укыгыз. Хәдисләрдә, аять хакында уйланып-фикерләп төннең бер сәгатен үткәрү төне буе намаз укудан яхшырак, диелгән.

Гали радыяллаһу ганһе Коръән уку хакында болай дип әйткән булган: «Ул — адаштырмый торган тугры киңәшче, юлдан яздырмый торган юлдаш, алдамый торган сөйләүче. Коръән җәмәгатендә торган һәрбер кеше һичшиксез арту һәм киму тәэсирендә булыр: туры юлда булуы артыр,

ә күңел-зиһен сукырлыгы кимер. Һәм белегез: Коръән — ул яклаучы һәм яклау сәләте булган ярдәмче, сөйләүче һәм раслаучы. Әгәр берәүне Коръән Кыямәт көнендә якласа, ул кеше иминлеккә ирешер. Коръәндә Раббыгызга юл эзләгез, җаныгыз вә күңелегез белән эш итүдә Аннан гына киңәш сорагыз, һәм үз фикерегезнең шикле булуында торыгыз, мәгәр Коръән белән киңәш иткәнегезгә хәтле. Коръән сезгә гөнаһларыгызга каршы торырга ярдәм итәр».

4. Аллаһы Тәгаләгә дога белән мөрәҗәгать итүдән туктамагыз: үзебез өчен, туганнарыбыз өчен, башка мөэмин-мөселманнар өчен даими догада булсак иде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселман дин кардәше өчен дога кылган вакытта, фәрештәләр: „Әмин, сиңа да шулай булсын“», — дип дога кылып торырлар, — дип әйткән булган.

5. Гыйлем алудан туктамагыз. Бу мөбарәк шәриф ай дәвамында һәркем үзе өчен яңа әйберләр өйрәнде, гыйлемнәрен арттырды, яңа аятьләр ятлады, китаплар укыды, вәгазьләр ишетте. Әлеге гамәлләр барысы да тәкъвалыгыбызны арттырып торырга ярдәм итте. Белгәнебезчә, хәдисләрдә гыйлемне бишектән алып ләхеткә кадәр алырга кирәклеге искәртелә. Рамазан аенда шушы күркәм гамәлне, гыйлем алуны гадәткә керткәнбез икән, аны дәвам итәргә кирәк. Бүгенге көндә гыйлем эстәү өчен әллә кайларга кадәр җәяү, сәфәр авырлыкларын күреп йөрисе юк, өйрәнәм дигән кешегә мөмкинлекләр күп — мәчет саен диярлек курслар эшләп килә, зур мәдрәсәләребез бар.

6. Нәфел уразалары. Рамазан ае тәмамланса да, Аллаһы Тәгалә безгә киләсе Рамазанга кадәр ел дәвамындагы сәфәребездә көч туплау өчен кечкенә тукталыш-пристаньләр билгеләгән. Ягъни, нәфел уразалары. Ай буе ураза тотып, шәүвәл аенда алты көн ураза тотучыларга Аллаһы Тәгалә ел буе ураза тотучы кешенең әҗер-савабын вәгъдә иткән. Моннан тыш, һәр дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе уразаларын, һәм яңа туган һәр айның 13нче, 14нче һәм 15нче көннәрендә ураза тотарга мөмкин.

Шунысын исебездән чыгармасак иде: без Рамазан аена түгел, Раббыбыз Аллаһыга гыйбадәт кылабыз. Рамазанда гына гыйбадәтләрне арттырып, ай үтү белән шул халәтне оныту — шулай ук бик дөрес булмас. Мәчеткә намаз укырга кергәндә без үзебезне мөселманнарча тотып, урамга чыккач та мөселманлык кайдадыр артта калган кебек булмаса иде. Раббыбыз Аллаһ әлеге вәгазьләр белән вәгазьләнергә, алда калган Рамазан көннәрен уйфикердә, ихлас гыйбадәттә үткәрергә насыйп әйләсен. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» нәшрият бүлеге*

# Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللّٰهُ وَاَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ سُبْحَانَ مَنْ
نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ
وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ❁ اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا
إِلَهَ إِلَّا اَللّٰهُ وَاَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ
أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَزَيَّنَ قُلُوبَ الْمُحِبِّينَ بِتِلاَوَةِ الْقُرْآنِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ
أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ❁ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ
كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلَّا
الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ
وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ❁ اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللّٰهُ وَاَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ
أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ وَأَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ
وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَهَادَةً نَاطِقَةً بِالْحُجَّةِ وَالْبُرْهَانِ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى
عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى أَبِي
بَكْرٍ الصِّدِّيقِ وَ عُمَرَ الْفَارُوقِ وَ عُثْمَانَ ذِي النُّورَيْنِ وَ عَلِيٍّ الْمُرْتَضَى الأَئِمَّةِ
رِضْوَانَ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ❁

أَمَّا بَعْدُ: أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

## خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذَ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَاحِمِينَ ۞

# Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хотбә

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәввәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти вәл-иимәән, вә шәрахә судүүрас-саадикыйнә би шәрхил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән, вә әкрамә гыйбәәдәһүл-мү'миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саа'имиинә әбүәәбәр-рахмәти вәл-гуфраан, вә зәййәнә кулүүбәл мүхиббәйни битиләәвәтил Куръәни, вә галләка галәс-саа'имиинә әбүәәбән-нииραани фи шәһри рамәдаан. Вәгадә лис-саа'имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йукаалу ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа'имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләẓии үнзилә фииһил-Куръәәнү һүдәл-линнәәси вә бәййинәәтин минәл һүдәә вәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһуу ẓүл-гафьүи вәл-гуфраан, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһуу. Шәһәәдәтән нәәтыйкатән билхүҗҗәти вәл бүрһәәни. Салләллааһу Тәгаалә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән. Хусуусан минһүм галәә Әби Бәкринис-Сыйддикый вә Гумәрал-Фәәрукый вә Гусмәәнәз-ẓиннүрайни вә Галиййинил-Мүртәдал ә-иммәти, ридъвәәналлааһи галәйһим әҗмәгыийнә.

Әммә бәгъде: әййүһәннәәс, үсыйкүм гыйбәәдәллааһи вә нәфсии әүвәлән-битәкъүәллааһ. Әгууẓу билләәһи минәш шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгалләẓиинәт-тәкау вәлләẓиинә

һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә вә ләкүм фил-куръәәнил-гаҙыйим, вә нәфәганәә вә иййәәкүм бил-әәйәәти үәҙҙикрил-хәкиим, иннәһуу һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-гаҙыйиму сәмиигуд-дүгаа'.

## Икенче хотбә

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһуу вә нәстәгыйнүһу вә нәстәгъфируһу вә ну'минү биһии вә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгууҙү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү вә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Вә әшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһ, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһ. Иннәллааһә вә мәләә-икәтүһү йүсаллүүнә галәннәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли вә сәллим галәйһи вә галәә җәмигыйль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин, вә галәә мәләә'икәтикәл-мүкаррабиин. Вә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйн, вә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйн, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыйн. Аллаһуммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм вәл-әмъүәәт, вәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәәмәр-раахимиин.

# Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы Тәгалә исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһы Тәгаләгә якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидаять һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы Тәгалә) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Раййән» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтә, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу Итүче һәм мәгъфирәт Иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһы Тәгаләнең коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм.

Ташлар белән кыйналып, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шәйтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы Тәгалә безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта, Ул (Аллаһы Тәгалә) гафу Итүче, Рәхимле, юмартлык Иясе, олуглык Иясе, бөек Зат һәм догаларны Ишетүче, кабул Итүче.

## Икенче хотбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһы Тәгаләгә үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидаять бирсә — аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса — аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә — күк әһелләреннән һәм җир әһелләреннән булганнарының барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

*10нчы апрель вәгазе,*

*шәүвәл аеның 1нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Ураза гаете вәгазе

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Рамазан аенда безгә хисапсыз нигъмәтләрен насыйп иткән, ураза тотарга, гыйбадәтләребезне үтәргә мөмкинлекләр биргән Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын! Бер ай дәвамында җир шарының бар мөселманнары, Коръәни Кәримдә китерелгән «Без ишеттек һәм буйсындык» сүзләренә нигезләнеп, ураза тотты, гөнаһлардан тыелып торып, көннәрен вә төннәрен гыйбадәттә үткәрде. Әлхәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән без фарыз булган уразаны тоттык, инде хәзер изге Рамазан аен озатабыз. Бер яктан, без хәзер көндезге вакытта ашап-эчү мөмкинлеге булганга сөенәбез һәм шул ук вакытта моңсуланабыз, чөнки Рамазан аенда гына бирелә торган бихисап савап алу мөмкинлегеннән мәхрүм калабыз.

Хөрмәтле мөселман кардәшләребез! Сезне шушы олуг көн — Ураза бәйрәме белән котлыйм. Бүген 1нче шәүвәл — барлык дөнья өчен бәйрәм көн. Раббыбыз Аллаһ җир йөзе өчен ике олуг бәйрәмне билгеләде: беренчесе — Ураза, икенчесе — Корбан гаете. Бер ай буена җөмһүриятебез чын мәгънәсендә бәрәкәттә яшәде: мәчетләребез тулы, көннәребез гыйбадәттә, төннәребез Коръән укуда иде. Тәннәребез ял итте: Раббыбызның хикмәте белән билгеләнгән ураза гыйбадәте безне ашау-эчүдән генә түгел, шулай ук төрле гөнаһлардан да ерак тотты: кул-аякларыбыз да безнең гөнаһлы гамәлләребездән ял иттеләр. Әйе, адәм баласы хаталана, Раббыбыз Аллаһ шушы Рамазан аен безне гөнаһларыбызга кәффарәт итеп кылса иде.

Рамазан аеның бәрәкәте икенче Рамазанга кадәр җитсә иде. Сизгәнсездер: көне буе эштә булсак та, кичләрен тәравихларны бергә укыдык,

төннәрен торып сәхәрләр ашадык, әмма бернинди дә ару тоймадык. Бу бәрәкәт ел буена калса иде. Әмин.

**1. Рамазан ае әҗер-саваплар күп мәртәбә арта торган ай.**

Чынлыкта, Аллаһы Тәгалә Рамазан ае гыйбадәтләре белән бик зур әҗерләр дә әзерләде: Үзенең коллары өчен Рамазанны бер хәзинә, ышанмаучыларга үкенеч итте.  Кыямәт көнендә, Рамазанны ничек үткәрүгә карап, кеше тиешлесен алыр: йә ул үзенең уразаларын, намазларын, тәравихларын күреп сөенер, йә гамәл дәфтәрендә аларны күрмичә (дөньяда вакытта ул аларны кылырга кирәк дип тапмаганы өчен) — үкенер.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сабырлык — иманның яртысы», — дип әйткән. Шулай ук ул: «Ураза — сабырлыкның яртысы», — дип әйткән.

Раббыбыз Аллаһ Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اسْتَعِينُوا بِالصَّبْرِ وَالصَّلَاةِ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الصَّابِرِينَ

**«Ий, иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша** [Аллаһы Тәгаләдән] **ярдәм сорагыз. Һичшиксез, Аллаһ сабыр итүчеләр белән».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:153

Шулай ук Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

إِنَّمَا يُوَفَّى الصَّابِرُونَ أَجْرَهُم بِغَيْرِ حِسَابٍ

**«Сабыр итүчеләрнең әҗере** [үлчәүләргә салынмыйча] **хисапсыз биреләчәк».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:10

Ураза тотучының әҗер-савапларын үлчәп тә, санап та бетереп булмас. Калган гыйбадәтләргә карата 10, 20 әҗер-саваплар бирелә дип әйтелсә дә, ураза әҗерен күз алдына китереп булмый.  Раббыбыз Аллаһ: «Ураза — Минем өчен», — диде. Әҗерен дә Раббыбыз Үзе бирә. Шулай ук Раббыбыз ураза

тотучыга Кыяметтә дә аерым әҗерләр бирер. Хәдисендә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җәннәттә Әр-Раййән исемле капка бар. Ул капкадан ураза тотучылар гына керә алыр», — дип әйткән. Шулай ук ул: «Ураза тотучының ике шатлыгы бар: беренчесе — ифтар вакыты, икенчесе — Раббысы белән күрешү», — дип әйткән.

**2. Рамазан ае — берләшү ае.**

Соңгы елларда берләшү өчен сәбәпләр аз булмады. Дөньякүләм авырулар, хәрби операция, Төркиядәге җир тетрәү, Палестинадагы вәхшәт… Раббыбыз Аллаһ шул фаҗигаләрдә вафат булган, зыян күргән кардәшләребезнең гөнаһларын ярлыкаса иде, яраларын дәваласа иде, югары җәннәтләре белән бүләкләсә иде.

Шул вакыйгалар барлык җир шарын тетрәндерде. Күп кешенең дөньядагы кыйммәтләрен, дөньяга карашын үзгәртте. Рамазан аенда шәйтаннар богауда булып, кеше нәфесе белән икәүдән-икәү генә калганда, кешеләр үзләренең нәфесләрен өйрәнә башлый: Рамазан аенда кылына торган гөнаһ тулысы белән кешенең нәфесеннән генә. Кешеләр үз-үзләренә күрә бер төрле иләк аша карый башлыйлар. Чынлыкта, бу вакыйгалар да безгә шундый бер мисал булды.

Рамазан ае берләшү ае, ләкин берләшү Рамазанда гына булмаса иде. Бүгеннән шәүвәл аена кердек, алда зөлкагъдә, зөлхиҗҗә кебек мөбарәк айлар бар. Шушы гаеткә җыелган кебек, якынча 70 көннән Корбан гаетенә дә җыелырбыз, Аллаһ насыйп итсә. Әмма шушы айда мәчетләргә карата барлыкка килгән җылылык бер генә көнгә дә сүнмәсә иде. Ифтарлар кунакка йөрешергә, тәравихлар төнге намазларга йөрүне, сәхәрләр — тәһәҗҗүд намазларына торуны, ураза үзе — гөнаһлардан ерак булуны, нәфесебезгә карата көрәшү гадәтен барлыкка китереп калдырсалар иде.

**3. Рамазан ае — Коръән ае.**

Рамазан ае безне тагын бер күркәм гадәткә ияләштереп калдырды — Коръән уку. Бик тырышкач, күпләребез бер ай эчендә Коръәнне тулысы белән

укып чыга алды. Кемдер яртысын, кемдер өчтән, кемдер дүрттән берен укыгандыр. Арабызда Рамазанда беренче тапкыр Коръән укый башлаган гына кешеләр дә юк түгелдер. Әмма Рамазанга кадәр бу гамәлне башкару авыр тоелган булса да, шушы ай Аллаһының Китабын тулысынча укып чыгарга мөмкин икәнен исбатлады. Шушы гамәлебез дәвамлы булып калса иде. Коръән турында пәйгамбәребез Мөхәмәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә Китабы — анда сезгә кадәр һәм сездән соңгы буыннар турында мәгълүмат, шулай ук сезнең арадагы мәсьәләләрне хәл итү юллары бар. Коръән — дөреслекне ялганнан аера торган китап. Аңа җитди мөнәсәбәттә карамаган яки аны тәкәбберлек аркасында калдырган кешене Аллаһы Тәгалә җәзалар. Коръән кушканча яшәмичә, үзенә башка төрле кулланма эзләгән кешене Аллаһы туры юлдан яздырыр.  Коръән — ныклы иман, хикмәтле искә төшерү һәм туры юл. Кеше Коръән белән булса, нәфесенә ияргәндә дә адашмас, аны укыганда телләр ялгышмас. Галимнәр Коръәнне укый-укый беркайчан да арымаячаклар һәм аның күп санлы кабатлаудан күңелләре төшмәс. Андагы гаҗәплекләр шуның кадәр күп ки, аларны барлап бетерү мөмкин түгел! Коръәнне тыңлаган җеннәр тыелып кала алмадылар һәм болай дип әйттеләр:

قُلْ أُوحِيَ إِلَيَّ أَنَّهُ اسْتَمَعَ نَفَرٌ مِّنَ الْجِنِّ فَقَالُوا إِنَّا سَمِعْنَا قُرْآنًا عَجَبًا ۝ يَهْدِي
إِلَى الرُّشْدِ فَآمَنَّا بِهِ وَلَن نُّشْرِكَ بِرَبِّنَا أَحَدًا

> [Расүлем!] **Әйт: «Миңа җеннәрдән бер төркем** [Коръән укылганын] **тыңлаганы вәхи ителде, алар әйттеләр: «Һичшиксез, без** [төзелеше һәм мәгънәсе белән башка китаплардан башка булган] **гаҗәеп Коръәнне ишеттек. Ул туры юлга илтә. Без дә аңа иман китердек.** [Шул сәбәпле] **Раббыбызга беркемне дә ширек кушмаячакбыз.**
>
> «Әл-Җинн / Җеннәр», 72:1—2

Коръән сүзе белән (үзенең сүзләрен Коръән белән куәтләп) сөйләшкән кеше хак сүз сөйләр, ә гамәлләрен аңа таянып башкарган кеше — әҗерен

алыр. Карарларын аңа таянып чыгарган кеше гадел булыр, аңа чакырган кешене Аллаһы туры юлга күндерер».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Коръәнгә карата хәдисшәрифләре бик күп. Шушы айда Коръәнгә карата мәхәббәтебез арткан булып, киләчәктә Коръәнне өйрәнергә бер этәргеч булса иде.

**4. Рамазан ае — бөек мөгаллим.**

Имам әл-Газали рахимәһуллаһи уразаны өч төргә бүлеп карый:

1. Гади кешеләр уразасы — ашау эчүдән һәм якынлык кылудан баш тартып тотыла торган ураза.

2. Сайлап алынганнар уразасы — беренчесенә өстәп, күз, колак, тел, кул һәм аякларны гөнаһтан саклап тотылган ураза.

3. Аерым сайлап алынганнар уразасы — йөрәкне дөнья мәшәкатьләреннән ерагайтып, дөньяви фикерләрне калдырып тоткан ураза. Бу төр ураза — пәйгамбәрләр уразасы. Аларның һәр гыйбадәте шундый булган да.

Икенче төр, сайлап алынганнар уразасына килгәндә, ул — без шушы Рамазанда тотарга тырышкан ураза да инде. Ай дәвамында күзләребезне гөнаһлы күренешләргә карамаска, колакларыбыз белән гөнаһлы сүзләр тыңламаска, телләребез белән гөнаһлы сүзләр сөйләшмәскә, кул, аяк, башка органнар белән гөнаһлы гамәлләр кылмаска кирәк дип вәгазьләр сөйләдек. Хәләл ризык булса да, ифтар вакытларында кирәкле кадәр генә ашап, ашау әдәпләрен дә көйләргә тырыштык. Чынлыкта, Рамазан аенда зур мәдрәсәдә идек. Ул бәлки диплом да бирмәс, әмма безнең диплом — безнең изге гамәлләребез.

**5. Рамазан ае — рухи сыйфатларны камилләштерү вакыты.**

Һәм, ниһаять, Рамазан кешене сүтеп җыя, дип әйтсәк тә ялгыш булмас. Бик күп төрле күңел авырулары, тән хасталары белән дә шушы айны каршы алган кеше, ихластан, Раббыбыз ризалыгы өчен уразасын тотып, тәравихларда катнашып, шушы авыру-хасталардан арына, чистарына. Җәмгыятебездә гайбәт сату, бер-береңә карата нәфрәт таралган дип сөйләшергә яратабыз. Әмма ба-

рысы да безнең гамәлләребезнең нәтиҗәсе бит. Һәр гыйбадәтнең тышкы һәм эчке ягы бар. Тышкы яктан ураза бары тик якынлык кылу һәм ашау-эчүдән тыелып тору кебек. Әмма ике егет һәм бер бабай кыйссасын исегезгә төшерәсем килә. Бервакыт намаздан чыгып, өйләренә кайтып барганда, ике егет бер бабайның нәрсәдер ашап утырганын күреп алалар. Алар гаҗәпләнеп:

— Бабай, син ураза тотмыйсыңмени? — дип сорыйлар. Бабай җавап итеп:

— Мин ураза тотам. Мин бит гайбәт сатмыйм, кеше өлешенә кермим, кыерсытмыйм, гөнаһ кылмаска тырышам. Әмма миңа Раббым авыру бирде, һәм мин ризыктан башка озак тора алмыйм. Шуңа мин ураза тотам, әмма ашыйм гына, — дип әйтеп, үзе дә сорау бирә: — Ә сез, егетләр, уразадамы соң?

Егетләр башларын аска иеп: «Юк, бабай, без уразада түгел, без бары тик ашамыйча гына торабыз», — дип җавап кайтаралар.

Вәгазебезнең башлам өлешендә әйткәнебезчә, тәравих намазларына йөрү гадәте — ястүгә йөрү гадәтенә, ифтарларга җыелу — кунакларга йөрешү гадәтенә әверелеп калса иде.

Аллаһы Тәгалә безне гыйбадәттән һәм изге гамәлдән аермасын! Тоткан уразаларыбызны, кылган гыйбадәтләребезне кабул кылсын! Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз — Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# СЕНТЯБРЬ–НОЯБРЬ

## Алабугада уктан ату буенча «Туган батыр» II Бөтенроссия турниры узды

Рабигыль-әүвәл аеның 1нче көнендә (16нчы сентябрьдә) Алабугада уктан ату буенча «Туган батыр» II Бөтенроссия турниры узды. Аны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Алабуга шәһәре һәм Алабуга районы мөхтәсибәте, Алабуга шәһәре һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы хакимияте, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, Казан шәһәренең «Туган авылым» милли-туристик комплексы, Башкортостан Республикасының «Мәргән уксы» атка утырып ату һәм традицион җәядән атуны үстерү буенча автоном коммерцияле булмаган оешмасы, «МАКСАТ» ир-атлар спорт клубы, Татарстан Республикасының җәядән ату федерациясе оештырды. Турнирда катнашучыларны һәм кунакларны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сәламләде.

II Бөтенроссия турниры халыкларның тарихи, этник, фольклор һәм мәдәни мирасын пропагандалау һәм өйрәнү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау; яшьләрне даими рәвештә спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү; уктан атуны популярлаштыру; Татарстан Республикасында вакыйгалар белән бәйле туризмны үстерү; Татарстан Республикасы һәм Россия күләмендәге ярышларда Россия Федерациясен тәкъдим итә алучы югары квалификацияле җәядән атучыларны ачыклау, әзерләү һәм камилләштерү максатыннан үткәрелә.

## Бөгелмәдә «Милли моң» Россиякүләм мөнәҗәтләр фестивале узды

Рабигыль-әүвәл аеның 1нче көнендә (16нчы сентябрьдә) Бөгелмәдә тугызынчы тапкыр «Милли моң» Россиякүләм мөнәҗәтләр фестивале узды. Быелгы чара Татарстан Республикасында игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышлап үткәрелде. Бәйгене Татарстан Республикасы

мөселманнары Диния нәзарәте, Бөгелмә мөхтәсибәте һәм Бөгелмә шәһәренең Татар мәдәнияте үзәге оештырды. Татарстан Мөфтие исеменнән сәламләү сүзләрен аның беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов җиткерде һәм фестивальне оештыручыларга Нәзарәтнең рәхмәт хатларын тапшырды.

Конкурс «Соло» һәм «Ансамбльләр» номинацияләрендә узды. Быел анда Самара өлкәсеннән һәм Башкортостан Республикасыннан, Татарстанның Бөгелмә, Лениногорск, Әлмәт, Баулы, Сарман, Кукмара, Ютазы, Мөслим, Чирмешән, Теләче, Югары Ослан, Яңа Чишмә, Зәй, Арча районнарыннан 200гә якын мөнәҗәт башкаручы катнашты.

## Мөфти мөселман волонтерлары белән очрашты

Рабигыль-әүвәл аеның 2нче көнендә (17нче сентябрьдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөселман волонтерлары белән очрашты. Анда Нәзарәтнең социаль башлангычларын тормышка ашыручы активистлар, волонтерлар, сәләтле мәдрәсә шәкертләре, өметле яшь белгечләр – барлыгы 70тән артык егет һәм кыз катнашты.

Камил хәзрәт яшьләргә иң элек үгет-нәсыйхәт сүзләре белән мөрәҗәгать итте. Ул республиканың актив мөселман хәрәкәте вәкилләренә Коръәнне уку һәм аңа нигезләнеп гомер итүдә тырышлык куярга киңәш итте. Яшьлекнең һәм вакытның кадерен белергә чакырды, Коръәннән һәм Сөннәттән, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм, галимнәр тормышыннан мисаллар китерде, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, киңәшләрен бирде, гыйбрәтле хәлләргә тукталды. Өммәт яшәеше, Ислам инфраструктурасы үсеше, Нәзарәт һәм аның карамагындагы оешмалар эшчәнлеге белән таныштырды. Яшьләрнең мөселман мәгарифе үсеше, хәләл мәсьәләләре, команда белән эшләү, мөселманнарга хас сыйфатларга кагылышлы сорауларга җавап бирде.

Очрашу ахырында ул XVI Бөтенроссия мөселман яшьләре форумында җиңү яулаучыларга грантлар тапшырды.

Аннан соң яшьләр команда булып эшләү тәҗрибәсен үстерү буенча уеннарга таралышты һәм табигатьтә ял итте.

## «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Татарстан мөселман уку йортларына ярдәм итүгә багышланган сөйләшү узды

Рабигыль-әүвәл аеның 3нче көнендә (18нче сентябрьдә) «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә «Мәдрәсәгә игелек кыл» яки мөселман уку йортларын финанслау мәсьәләләре» темасына түгәрәк өстәл узды. Анда Татарстан Мөфтие урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры, Россия Ислам мәгарифе советы рәисе Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин, Ислам кабул ителүнең 1000-еллыгы исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Урыссуның «Фәнис» мәдрәсәсе директоры Марат хәзрәт Мәрданшин, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе директорының беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов, Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды җитәкчесе Булат хәзрәт Мәрданов һәм журналистлар катнашты.

Утырыш башланыр алдыннан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә беренче курста белем алучы 100 шәкерткә РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе хәйрия фондының финанс ярдәме белән сатып алынган гарәп теле дәреслекләре тапшырылды. Бу гамәл республика эшмәкәрләре тарафыннан мәдрәсәгә ярдәм күрсәтүнең ачык мисалы булып тора.

Түгәрәк өстәлнең төп темасы татар-мөселман җәмәгатьчелегенең Ислам уку йортларына финанс яктан ярдәм күрсәтүенә кагылышлы иде. Утырыш бүген мөселман мәгариф системасы алдында торган проблемаларның берсе – мәдрәсәләрне, Ислам югары уку йортларын финанслау мәсьәләсенә багышланды. Анда катнашучылар уку йортларының бюджетын формалаштыру юллары хакында киңәште. Милли кадрлар әзерләүче мәдрәсәләр язмышында киң җәмәгатьчелекнең, эшмәкәрләр даирәсенең финанслата катнашуына кагылышлы фикерләр әйтелде. Чыгыш ясаучыларның барысы да татар милләте

тарихындагы яңарыш чорының мәктәп-мәдрәсәләр күпләп ачылуы белән бәйле булуын һәм аларның җәмгыять, аерым кешеләр башлангычы белән эшләгәнен һәм, нәтиҗәдә, милләтебез мәнфәгатьләрен истә тотып, көчле шәхесләр тәрбияләп чыгарганлыгын ассызыклап узды. Алар бертавыштан, әгәр дә бүген татар халкының чын асыл йөзен саклап калу мәсьәләсе кискен куела икән, бу эшне, һичшиксез, мәдрәсәләрдән башларга кирәклеген әйтте. Татарстан мәдрәсәләрендә татар телле кадрлар тәрбияләнүен белдерде һәм халыкны Татарстанда мөселман уку йортларына матди яктан ярдәм күрсәтергә чакырды. Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды җитәкчесе Булат хәзрәт Мәрданов Татарстанда мөселман уку йортларына садака һәм зәкят бирү буенча оештырылган онлайн-хезмәт эшчәнлеге һәм аның нәтиҗәләре белән таныштырды.

## «Казан» халыкара аэропортында тагын бер намаз бүлмәсе ачылды

Рабигыль-әүвәл аеның 7нче көнендә (22нче сентябрьдә) Г. Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортының 2нче терминалында рәсми рәвештә намаз уку бүлмәсе ачылды. Анда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, намаз уку бүлмәсен булдыруга үзеннән зур өлеш керткән Илнар Гыйрфанов, РФ Дәүләт Думасы депутаты Рөстәм Кәлимуллин, «Казан» халыкара аэропорты генераль директор урынбасары – техник үсеш һәм эксплуатацияләү буенча директор Ринат Гыйззәтуллин, Лаеш районы имам-мөхтәсибе Наил хәзрәт Әбелханов һ.б. катнашты. Җитәкчеләр беренче эш итеп намаз уку бүлмәсен карады, аңа булган ихтыяҗ һәм бүлмәдән файдалану турында фикер алышты, мондагы беренче намазны укыды.

Намаз уку бүлмәсе терминалның икенче катында урнашкан. Кырык квадрат метрлы намаз уку бүлмәсе 7–8әр кеше сыйдырышлы ир-атлар һәм хатын-кызлар залыннан тора. Михраб куелган, келәм җәелгән, Коръән китаплары, намазлыклар бар, тәһарәтханә корылган. Намаз уку бүлмәсенең дизайны уникаль, кабатланмас итеп, татар һәм мөселман стилистикасын берләштереп эшләнгән.

Хәзерге вакытта «Казан» халыкара аэропортында 2 намаз уку бүлмәсе эшли.

## Мөслим мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Рабигыль-әүвәл аеның 8нче көнендә (23нче сентябрьдә) мөбарәк Мәүлид аенда Мөслим мөхтәсибәтендә күркәм вакыйга булды — Мөслим районы үзәгендә дүртенче мәчет үз ишекләрен ачты. Тантанада Татарстан Мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, Мөслим муниципаль район башлыгы Альберт Хуҗин, район имам-мөхтәсибе Илгиз хәзрәт Сөнгатуллин, республиканың Түбән Кама, Минзәлә, Мамадыш, Азнакай, Лениногорск, Тукай районнары имам-мөхтәсибләре, мөхтәрәм дин әһелләре, район халкы, килгән кунаклар катнашты. Аллаһ йортын төзүдә матди ярдәм күрсәткән өчен мөхтәрәм затларга Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Мөслим мөхтәсибәтенең рәхмәт хатлары тапшырылды.

Бер катлы яңа гыйбадәт йортына «Разалия» мәчете дип исем бирелде. Мәчетнең имамы итеп Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мөселман мәдрәсәсен тәмамлаган Ислам хәзрәт Шәфыйков сайланды. Кырык биш кеше сыйдырышлы мәчет инженер-коммуникация челтәрләренә тоташтырылган. Ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен намаз уку заллары һәм тәһарәтханәләр булдырылган.

Бүгенге көндә Мөслим авылында — 4 мәчет, мөхтәсибәт күләмендә 37 мәчет эшли.

## Мобилизацияләнгән солдатларның кулына Татарстан мөселманнарыннан гуманитар йөк тапшырылды

Сентябрь ахырында Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатларга махсус хәрби операция зонасына гуманитар йөкне илтеп тапшыру өчен оештырылган чираттагы сәфәр уңышлы тәмамланды. Бу Луганск өлкәсендә урнашкан хәрби

подразделениегә өченче командировка булды. Анда хезмәт итүче солдатларның 90 проценты — чыгышы белән Татарстанның Биектау, Питрәч, Саба, Арча, Балык Бистәсе һәм башка район һәм шәһәрләреннән, аларның 50дән артыгы — намаз укучы дин кардәшләр.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте делегациясенең сәфәре йөкне турыдан-туры солдатлар кулына тапшыруы белән кадерле. Сугышчылар өчен төнлә яхшырак күрергә мөмкинлек бирә торган приборлар, радиостанцияләр, маскировка челтәрләре, колакчыннар, фонарьлар, компаслар, газ плитәләре һәм баллоннар, шөреп борып кертә торган җайланмалар, саморезлар, җылыткычлар сатып алып илттеләр. Моннан тыш, солдатларга туган якларыннан азык-төлек (шул исәптән хәләл тушенкалар), бронежилетлар, шлемнар, шәхси гигиена чаралары, медикаментлар, бинтлар, оекбашлар, эчке киемнәр һ. б. — барысы 1 тоннадан артып киткән йөк барып җитте. Гуманитар ярдәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан республиканың барлык почмакларындагы битараф булмаган мөселманнар җыеп тапшырган акчага сатып алынды. Нәзарәт сугышчыларга кирәкле товарлар сатып алу өчен акча җыюга үз өлешен керткән һәркемгә рәхмәт белдерә.

## Татарстанда Мәүлид кичәләре узды

15 сентябрьдә, кояш баеганнан соң, һиҗри календарь буенча мәртәбәле айларның берсе — пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган рабигыль-әүвәл ае башланды. Татарстан мөселманнары өчен мәчетләрдә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүенә ихлас күңелдән шатлануны белдереп, ай дәвамында төрле чаралар үткәрелде. Алар Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын өйрәнүне, аңа күпләп салаватлар әйтүне, Коръән аятьләрен уку, догалар кылу, вәгазьләр сөйләүне үз эченә алды. Мәүлид мәҗлесләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм узган юлны һәм аның сөннәт гамәлләрен искә төшерүне, аның күркәм әхлакый үрнәген өлге итеп алуны, рухыбызны тәрбияләү һәм ныгытуны максат итеп куйды.

26нчы сентябрьдә, рабигыль-әүвәл аеның 12нче көне кергәч, ахшам намазыннан соң Казан шәһәренең Галиев мәчетендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган көне уңаеннан Мәүлид ән-Нәби үткәрелде. Мәүлид белән Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин тәбрикләп, әлеге истәлекле көннең фазыйләтләре, Мәүлид үткәрүнең мөһимлеге турында сөйләде. «Мөселманнар, Мәүлидкә җыелып, шатлыкларын белдерә, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтә һәм сәламнәрен җиткерә, чөнки сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу дөньяга килүе – Аллаһының олуг бүләге. Раббыбыз безгә бер рәхмәт җибәрә икән, без шатланырга тиеш булабыз. Ә рәхмәтләр арасында иң олысы, иң зурысы – ул да булса Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүе. «Әнбия» сүрәсендә «Ий, Мөхәммәд, без сине галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрдек» диелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм туганга шатланган өчен, хәтта аның дошманы Әбү Ләхәбнең газабы дүшәмбе саен җиңеләя икән. Без Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яратып, аның Сөннәте буенча яшәсәк, әҗер-савабыбыз күбрәк булыр, иншәАллаһ», — диде Мөфти хәзрәт.

Мәүлид ән-Нәби бәйрәменең күркәм бизәге булып татар мәкаме белән мәшһүр «Мәүлид» касыйдәсен башкару торды. Моннан тыш, мәҗлеснең яңалыгы булып пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәселе дәвамчысы Сәиддауд Сөеновның нәшидләр һәм мөнәҗәтләр башкаруы торды.

Ә рабигыль-әүвәл аеның 12нче көнендә (27нче сентябрьдә) Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көненә багышланган традицион Мәүлид ән-Нәби шәһре Болгардагы «Ак мәчет»тә үтте. Шәрәфле кунаклар арасында Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Болгар Ислам академиясе ректоры Фәрхәт Хөснетдинов һ. б. бар иде.

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган көне билгеләп үтелә торган мөбарәк ай — Мәүлид белән тәбрикләде. Ул үзенең чыгышында Мәүлидне үткәрүнең мөһимлеген һәм фазыйләтләрен билгеләп үтеп, татар дин галиме Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» китабыннан өзек китерде. Биредә Кәүсәр чишмәсеннән су эчәчәк, беркайчан сусау тоймаячак биш төркем кеше китерелә: беренчесе — Сөннәткә иярүчеләр, икенчесе — Мәүлид бәйрәмен үткәрүчеләр, өченчесе — мөдәррисләр, хаҗилар һәм газилар (сугышта катнашучылар), дүртенчесе — ятимнәргә өлеш чыгаручылар; бишенчесе — шәкертләргә һәм мосафирларга куну өчен урын бирүчеләр.

Минтимер Шәймиев Мәүлид бәйрәменең зур тарихи җирлектә — шәһре Болгарда үтүен билгеләп үтеп, биредә тарихи, мәдәни, дини ядкәрләрне саклау буенча алып барылган эшчәнлек турында сөйләде. Ул, Мәүлид ән-Нәби бәйрәме белән котлап, балаларның матур итеп салават әйтүенә соклануын белдерде. Татарстан Дәүләт Киңәшчесе, Болгар Ислам академиясендә шәкертләр белән очрашып, Шәймиевләр нәселеннән алтмыш томда дәреслекләр, гарәп телендә китаплар бүләк итте.

Ә рабигыль-әүвәл аеның 13нче көнендә (28нче сентябрьдә) пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланган мөбарәк кичә – театральләштерелгән Мәүлид Нәзарәттә үткәрелде. Әлеге очрашуның максаты — Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булган яратуның нинди булырга тиешлеген аңлатудан, киң җәмәгатьчелектә Мәүлид үткәрү традицияләрен ныгытудан гыйбарәт булды. Ике сәгатьлек программаны 150 кеше карады.

Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Мәүлидне үткәрүнең фазыйләтләре, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булган ярату, Сөннәт юлыннан баруның әһәмияте хакында вәгазь сөйләп, Мәүлиднең асыл мәгънәсе — галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә алу кирәклеген искәртте.

— Безнең динебездә камил кеше концепциясе бар — ул Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Без Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә охшарга тырышсак, Исламда барысын да дөрес эшләячәкбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм барлык эшләрдә дә иң яхшысы булган: ул иң яхшы дус, галим, укытучы һ.б. — дип, Камил хәзрәт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иярү кирәклеге турында билгеләп үтте.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булган яратуның мөһимлеге хакында сөйләү өчен педагогика фәннәре докторы, Әл-Әзһәр университетының Чыгарылыш лигасы каршындагы Мәгариф һәм фән департаменты җитәкчесе, Ислам хокукы һәм гакыйдә буенча әйдәп баручы белгеч, шәех Хамдаллаһ Хафиз Мөхәммәд әс-Сафти килгән иде. Ул үз чыгышында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күрмичә торып, аны ярату ничек булырга тиешлеген аңлатып узды, күпләгән аятьләр, хәдисләр, мисаллар китерде.

## Казанда Россия Ислам институтының 25 еллыгына багышланган чаралар узды

2023 елның 27–30нчы сентябрендә Россия Ислам институты Татарстан мөфтияте һәм Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды белән берлектә Россия Ислам институтының 25 еллыгына багышланган «Россия мөселман мәгарифендә традицияләр һәм инновацияләр» дип исемләнгән халыкара симпозиум үткәрде. Анда 500дән артык мөгаллим, мөселман мәгарифенең башлангыч, урта һәм югары баскычы җитәкчеләре, халыкара Ислам мәгариф үзәкләре вәкилләре, мөселман дин әһелләре, галимнәр һәм хакимият вәкилләре катнашты.

Симпозиум кысаларында мәчет каршындагы курсларда белем бирүчеләр, урта һәм югары дини белем бирү оешмалары хезмәткәрләре катнашында мөселман уку йортлары мөгаллимнәре форумы узды. 28нче сентябрьдә тәҗрибә уртаклашу өчен җыелган пленар утырышта Татарстан Мөфтие Камил

Сәмигуллин чыгыш ясады. Ул белем биргәндә заманча технологияләрне куллануның уку йортлары мөмкинлекләрен киңәйтүен һәм укытуның нәтиҗәлелеген арттыруын, уку процессын яңа дәрәҗәгә күтәрүен билгеләп үтте. Аның фикеренчә, интерактив техник җиһазлар Ислам уку йортларына квалификацияле укытучыларны җәлеп итәргә, кыйммәтле һәм сирәк чыганаклар белән эшләргә, күбрәк студентны предмет белән тирәнрәк таныштырырга мөмкинлек бирә.

Татарстанда күп еллар дәвамында Ислам мәгариф системасының һәр баскычында — мәчет каршындагы курслардан һәм мәдрәсәдән алып РИИ һәм Болгар Ислам академиясенә кадәр – дистанцион укыту формалары гамәлгә ашырыла, кыйммәтле чыганак базасы булган «Даруль-кутуб» бушлай электрон китапханәсе эшли, интернет-конференцияләр оештырыла, бушлай мобиль кушымталар, рус һәм татар телләрендә онлайн-мәдрәсә, татар телен өйрәнү буенча онлайн-платформа һәм башкалар бар. Бу мөмкинлекләр студентларны укыту өчен яңа методикалар эшләргә ярдәм итә, димәк, һөнәри белем бирүнең сыйфатын күтәрә, шулай ук массакүләм халыкның дини грамоталылыгын арттырырга мөмкинлек бирә. Камил хәзрәт Ислам мәгарифендәге проблемаларны да күтәреп чыкты: алар үзәкләшкән система булмау, Россия мөселман җәмгыятенең дини уку йортларын үстерү белән кызыксынмавы, кадрлар кытлыгы, методик яктан тәэмин ителешнең җитәрлек булмавы белән бәйле.

## Питрәч Җәмигъ мәчетенә ярымай куелды

Рабигыль-әүвәл аеның 11нче көнендә (26нчы сентябрьдә) Питрәч авылы Җәмигъ мәчетенә ярымай куелды. Төзүчеләр, Аллаһы Тәгаләгә мактау сүзләре әйтеп, ярымайны 32 метр биеклектәге манарага күтәрде.

Татарстан Республикасы Мөфтие урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләп, мәчетләр һәм социаль объектлар төзүдә катнашканнарга Аллаһыдан зур әҗер-саваплар бирелүе турында сөйләде.

## «Зәкят» хәйрия фонды 300дән артык гаиләгә 10 тоннадан артык гошер таратты

Рабигыль-әүвәл аеның 14нче көнендә (29нчы сентябрьдә) ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗларга чираттагы гошерне таратты. Питрәч районы мөхтәсибәтеннән китерелгән 1,5 тонна гошер Казанның 35тән артык аз керемле һәм күпбалалы гаиләсенә, ялгыз яшәүче өлкәннәргә өләшенде. Шулай итеп, «Зәкят» хәйрия фонды 29нчы сентябрьгә башкаланың 300дән артык гаиләсенә Алексеевск, Әлки, Әтнә, Балтач һәм Питрәч районнарыннан килгән 10 тоннадан артык гошер таратты.

Гошер — садаканың махсус төре, ул мөселман кешесенең, үстергән уңышын җыеп алганнан соң, аның уннан берен мохтаҗларга бирүдән гыйбарәт. Гошер көне Татарстанда барлык мөхтәсибәтләрдә үзәкләштерелгән рәвештә 2017 елдан бирле үткәрелә.

## Әлмәттә «Дуслык» мәчетен ачу тантанасы булды

Рабигыль-әүвәл аеның 13нче көнендә (28нче сентябрьдә) Әлмәт шәһәренең «Дружба» микрорайонында «Дуслык» мәчете ачылды. Тантанада Татарстан Мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, имам-мөхтәсиб Исмәгыйль хәзрәт Сингатуллин, Әлмәт районы имамнары катнашты. Ачылыш шәһәр имамнарының яңа мәчет янында агачлар утыртуыннан башланды.

Равил хәзрәт Зөфәров, мәхәллә кешеләрен әлеге мөһим вакыйга белән котлап, Исламда мәчетләр төзүнең изге эш икәнлеген һәм Аллаһы Тәгалә йортын төзүдә ярдәм иткән кешегә әҗер-савапның зур булачагын билгеләп үтте. Биш ел дәвамында мәчет төзелешенә ярдәм иткән оешмалар һәм шәхси затларга Нәзарәтнең һәм Әлмәт мөхтәсибәтенең рәхмәт хатлары тапшырылды.

Йөз утыз кеше сыйдырышлы ике катлы кирпеч мәчет барлык инженерлык челтәрләренә тоташтырылган, ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәт алу

бүлмәләре ясалган. Мәчетнең беренче катында — ир-атлар өчен фарыз залы, никах үткәрү өчен бүлмә, имам кабинеты, ә икенче катта хатын-кызлар өчен намаз залы урнашкан. Цоколь катында уку сыйныфлары, кухня, мәҗлесләр үткәрү өчен бүлмә җиһазландырылган.

## Татарстан мөфтие халыкны кабул итте

Рабигыль-әүвәл аеның 25нче көнендә (10нчы октябрь) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ТР мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясендә халыкны кабул итте. Мөселман активистлары, җәмәгать эшлеклеләре Мөфти хәзрәткә дини мәсьәләләр буенча киңәш сорап мөрәҗәгать итте һәм үз проектлары белән таныштырды. Аерым алганда, сүз мәчетләр төзү, тарихи мирасны саклау һәм мөселман яшьләренең проектларын үстерү турында барды. Барлык сораулар да, кабул ителеп, җентекләп өйрәнү өчен ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең җаваплы бүлекчәләренә тапшырылды.

Татарстан Мөфтие шулай ук махсус хәрби операция зонасында хәбәрсез югалган татарстанлыларның хатыннары һәм кыз туганнары белән очрашты.

## Казанда яшь мөслимә киленнәр өчен курслар узды

Казанда октябрь-ноябрь айларында Диния нәзарәтенең мөселман яшьләре арасында зур популярлык казанган проектларның берсе — «Яшь килен» курслары эшләде. Тугызынчы тапкыр тормышка ашырылган проектта 40 мөслимә катнашты.

Киленнәр мәктәбе Аллаһы Тәгалә кануннары буенча бәхетле гаилә корырга һәм гаилә учагын саклап калырга теләүчеләр — 17 яшьтән алып һәм өлкәнрәк, кияүдә булмаган, ярәшелгән мөслимәләр һәм кызларын кияүгә бирергә җыенган әниләр өчен оештырыла. Белем бирү курслары Коръән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сөннәте һәм Ислам дин галимнәренең гыйлемнәренә нигезләнгән.

Мөслимәләр биредә академик белемнәргә ия, танылган остазлар һәм шәехләрдән никахта ир-хатынның бурычлары һәм хокуклары, мәһәр, никахлашу өчен хәерле ир сайлау, яшь гаиләдә проблемалар, балалар тәрбияләү, никахта җенси мөнәсәбәтләр һ.б. турында тәфсилле лекцияләр тыңлады. Никах, үз хокуклары һәм бурычлары турында хакыйкый гыйлемнәр алды һәм үзләренә ир сайлаганда төптән уйланган карарлар кабул итәргә өйрәнде.

## Россия Ислам институтында партнерлык финанслары буенча эш төркеме төзелде

Рабигыль-әүвәл аеның 27нче көнендә (12нче октябрьдә) РИИда узган «Бүгенге көндә Россиядә партнерлык финансларына кагылышлы мәсьәләләр: үсеш мөмкинлекләре һәм заман таләпләре» дип исемләнгән түгәрәк өстәл утырышы вакытында РИИның Россия Ислам икътисады һәм финанслары үзәге каршында партнерлык финанславы буенча эшче төркем булдыру турында игълан ителде. Эшче төркемгә партнерлык финанславын үстерү буенча экспериментта катнашучы дүрт төбәкнең — Татарстан, Дагыстан, Башкортостан һәм Чечен Республикасының Ислам хокукы һәм Ислам финанслары өлкәсендәге экспертлары керде.

## Нәзарәттә «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең уникенчесе башланды

Рабигыль-әүвәл аеның 29нчы көнендә (14нче октябрьдә) Нәзарәттә «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 12нче сезоны ачылды. Беренче дәрес Нәзарәт бинасында узды: бу агымда 200дән артык кеше намаз укырга һәм Ислам нигезләренә төшенергә теләк белдерде. Алар алдында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль үсеш бүлеге башлыгы Айгөл Биктимирова чыгыш ясады. Ул, Аллаһ юлында белем алуның фазыйләтләрен аңлатып, һәркемнең тормышында аны үзгәртүче вакыйгалар булуын билгеләп үтте һәм «Ислам.

Беренче адымнар»ның шәкертләр тормышын тулысынча үзгәртүен телдә һәм шәкертләрне белем алудан туктамаска чакырды.

«Ислам. Беренче адымнар» мәктәбе 5 ел буе мәчет каршындагы курсларга йөрергә мөмкинлекләре һәм вакытлары булмаган, әмма мөселман үтәргә тиешле гыйбадәтләрен башкарып яшәргә теләүче дин кардәшләр өчен оештырыла. Проект Татарстан мөфтияте тарафыннан дәгъват эшчәнлеге кысаларында 2018 елда тормышка ашырыла башлады. Унбер сезон дәвамында әлеге курсларда 1078 кеше белем алды һәм намазга басты.

## Чистайда XI Саматов укулары узды

Рабигыль-ахыр аеның 4нче көнендә (19нчы октябрьдә) Чистай шәһәренең «Нур» мәчетендә XI Саматов укулары үткәрелде. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм Чистай районы мөхтәсибәте оештырган җыен татар халкының күренекле дин галиме, Татарстанның беренче казые, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы күренекле дин әһеле Габделхак хәзрәт Саматовка багышлап оештырылды. Конференция Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында «Имамнар — милләтебезнең рухи көзгесе» дигән исем белән үтте.

Габделхак хәзрәт Саматов — инкыйлабка кадәр булган татар дини мирасын дәвам итүче, Ислам диненә багышланган күп китаплар авторы. Бүгенге көндә дин өлкәсендә хезмәт куючы имамнарның күпчелеге — нәкъ менә Габделхак хәзрәтнең шәкертләре. Укулар вакытында Габделхак хәзрәт Саматов шәхесе татар-мөселман мәдәнияте традицияләрен дәвам итүче югары рухка ия шәхес буларак каралды.

Конференциядән соң кунаклар, Чистайның тарихи мөселман зиратында булып, анда татар дин галиме, ишан, Чулман-Урал төбәгендә суфыйчылык хәрәкәте мөршиде, Габделхак хәзрәт Саматовның остазы Мөхәммәдзакир Габделвахаб Камалов-Чистави каберен зиярат итеп, Коръән аятьләре укып, дога кылды.

## РИИда Татарстан казыйлары өчен гаилә хокукы буенча белем арттыру курслары узды

Россия Ислам институтында Татарстан Республикасы казыйлары өчен «Шәхси статус (Гаилә хокукы)» дип аталган белем арттыру курслары узды. Аны ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Россия Ислам институты һәм Ислам мәдәнияте, мәгарифе һәм фәненә ярдәм фонды оештырды. Әлеге курслар тәҗрибә уртаклашу һәм Исламда гаилә хокукы буенча белемнәрне системалаштыру өчен үткәрелде.

Казыйларга белемне КИУ проректоры, Ислам фәннәре докторы, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы сәркатибе, КИУның дини фәннәр кафедрасы өлкән укытучысы Рөстәм хәзрәт Нургалиев; тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые, «Фәнис» мәдрәсәсе директоры Марат хәзрәт Мәрданшин; Казан казые, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең шәригать мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе Булат хәзрәт Мөбарәков бирде.

## Мисыр принцы һәм Татарстан мөфтие Каһирәдә дин галиме Муса Бигиев каберенә истәлек билгесе куйды

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Каһирәгә (Мисыр) эш сәфәре вакытында Каһирәнең Әл-Карафа некрополендә — башкаланың көньяк-көнчыгышындагы мөселман зиратында булды. Ул бирегә күренекле татар дин галиме Муса Бигиев каберендә Истәлек билгесе куелу уңаеннан килде. Татарстан Мөфтие, Коръән укып, күренекле татар-мөселман галиме рухына багышлап дога кылды. Муса Бигиевның кабере әлеге зиратның Король каберлеге территориясендә (Мисыр король династиясе Мөхәммәт Али каберлеге) принцесса Хадига (Хадиҗә) кабере янында урнашкан.

Бу мөһим вакыйга уңаеннан каберне шулай ук Мисырның Король йорты лидеры, Мисыр һәм Суданның соңгы хәдиве (оттоман җитәкчесе) оныгы, принц Аббас Хилми бәй, Мисыр Гарәп Республикасы туризм һәм борынгылык министрлыгының Ислам һәм коптларның борынгылык идарәсе башлыгы, профессор Әбү Бәкер Әхмәт һәм Бәйсез Дәүләтләр берләшмәсе, чит илләрдә яшәүче ватандашлар эшләре һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек буенча федераль агентлыкның Мисырдагы вәкиллеге башлыгы Марат Гатин зиярат кылды.

Муса Бигиевның җирләнгән урыны моңа кадәр билгесез иде һәм Камил хәзрәт үтенече буенча Чит илләрдә яшәүче ватандашлар эшләре һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек буенча федераль агентлыкның Мисырдагы вәкиллеге һәм Мисырның туризм һәм борынгылык министрлыгы ярдәме белән табылды.

## Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды Мәүлидкә багышланган хәйрия чарасы үткәрде

Рабигыль-ахыр аеның 8нче көнендә (23нче октябрь) ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Мәүлид ән-Нәбигә багышланган хәйрия чарасы үткәрде. Тантанага үзенчәлекле балалар тәрбияләүче һәм авыр тормыш хәлендәге күпбалалы аналар — барлыгы 25тән артык кеше чакырылган иде.

Мәҗлесне вәгазь белән КИУ мөгалиммәсе Миләүшә ханым Зарипова ачып җибәрде. Ул Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм авырлыкларны ничек җиңәргә кирәклеге турында сөйләде. Чара тәмле төшке аш һәм «Бәхет ачкычы» иҗат төркеменнән сабын ясау буенча мастер-класс белән дәвам итте.

## Татарстанда 826,9 тонна гошер садакасы җыелды һәм мохтаҗларга өләшенде

Татарстан Республикасы Диния Нәзарәте башлангычы белән тормышка ашырылган гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын

азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе тәмамланды. Кампания нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасында барлыгы 826,9 тонна гошер сәдакасы җыелды һәм мохтаҗларга өләшенде. Мөхтәсибәтләр арасында беренче өчлекне Сарман (88 тонна), Балык Бистәсе (60 тонна), Балтач (59,2 тонна) районнары алып тора. Шулай ук Арча районы (58 тонна), Саба районы (43 тонна), Әтнә һәм Чирмешән районнары (40шар тонна), Теләче районы (35 тонна), Чүпрәле районы (32,3 тонна), Буа районы (30 тонна), Зәй һәм Апас районнары (25шәр тонна) зур активлык күрсәтте.

## Кама Тамагы мөхтәсибәтендә Мәгърифәт үзәге ачылды

Рабигыль-ахыр аеның 17нче көнендә (1нче ноябрьдә) Кама Тамагы районы Үзәк мәчете каршында Мәгърифәт үзәге ачылды. Тантанада Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашып, Мәгърифәт үзәге төзелешендә катнашучыларга рәхмәт сүзләрен җиткерде, иганәче Рафаэль Насыйбуллинга Нәзарәтнең «Бердәмлек» медален тапшырды. Вәгазь укып, район имамнары сорауларына җавап бирде.

Мәгърифәт үзәгенә 2022 елның июль аенда нигез салынып, октябрь аенда төзелеп беткән. Иганәчеләр, эшмәкәрләр һәм җирле халык ярдәме белән сафка баскан белем бирү үзәге 50 кешегә исәпләнгән. Гомуми мәйданы — 96 квадрат метр. Анда уку сыйныфлары, кухня, ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханәләр урын алган. Бинада дини чаралар, никахлар, Рамазан аенда авыз ачу мәҗлесләре үткәрү мөмкинлеге бар.

## Казанда Коръән укучыларның IV Республика бәйгесе узды

Рабигыль-ахыр аеның 21нче көнендә (5нче ноябрь) «Казан» ат-спорт комплексында мөселман уку йортлары шәкертләре арасында Фатыйма Гыймадова истәлегенә Коръән укучыларның IV Республика бәйгесе узды. Чара-

ны ТР мөселманнары Диния нәзарәте, РИИ һәм КИУның Госман Ибн Аффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәге, Гыймадовлар гаиләсе РФ Мөселман эшкуарлары ассоциациясе ярдәме белән оештырды.

## Нәзарәт махсус хәрби операция зонасындагы Татарстан сугышчыларына дүртенче тапкыр гуманитар йөк һәм автомобиль илтте

Диния нәзарәте белгечләре Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатларга махсус хәрби операция зонасына чираттагы гуманитар йөкне илтеп тапшырды. Бу Луганск өлкәсендә урнашкан хәрби подразделениегә дүртенче командировка булды. Анда хезмәт итүче солдатларның 90 проценты – чыгышы белән Татарстаннан. Алар арасында намаз укучы дин кардәшләр дә бар.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте делегациясенең сәфәре йөкне турыдан-туры солдатлар кулына тапшыруы белән кыйммәтле булды. Алар өчен азык-төлек (хәләл тушенка), җылы киемнәр (курткалар, башлыклар, термоноскилар, итекләр, яңгырдан саклаучы плащ-пончо, перчаткалар) сатып алдылар. Моннан тыш, аларга маскировка челтәрләре, юеш сөлгеләр, махсус бинтлар, газ баллоннары, төнлә яхшырак күрергә мөмкинлек бирә торган приборлар, зарядкалар һәм туганнарыннан күчтәнәчләр — барлыгы 0,5 тонналап йөк алып барды.

Гуманитар ярдәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан республиканың барлык почмакларындагы битараф булмаган мөселманнар җыеп тапшырган акчага сатып алынды.

Бу юлы хәрби операция зонасына, хәрби бурычны үтәр өчен, «Ярдәм-Помощь» гомуммилли хәйрия фондыннан һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтеннән «УАЗ» автомобиле илтеп тапшырылды.

## «Зәкят» хәйрия фонды Газә секторына гуманитар ярдәм күрсәтте

Рабигыль-ахыр аеның 26нчы көнендә (10нчы ноябрьдә) изге җомга көнендә иртән «Казан» халыкара аэропортыннан Татарстаннан Мисырга Газә секторы өчен гуманитар ярдәм белән РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының беренче борты кузгалды. Очкычка кием-салым, балалар ризыгы, озак саклана торган азык-төлек, санитария һәм гигиена әйберләре (шул исәптән, балалар өчен дә), пледлар, яктырткычлар, кайнаткычлар, көнкүрештә куллану өчен башка кирәк-ярак — барлыгы 25 тонна йөк төялде. Әлеге акция Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе белән оештырылды.

Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды Газә секторы халкы өчен хәйрия ярдәме җыю хакында 2нче ноябрьдә игълан итте. Тугызынчы ноябрьгә кадәр фондта 35,7 млн сум акча җыелды. Шул акчадан 5 180 531,64 сумлык 20 тонна азык-төлек: 3 тонна томалап пешерелгән хәләл сыер ите, 3 тонна ярма, 1 тонна көнбагыш мае һәм Газә секторына гуманитар ярдәм белән беренче бортны җибәрү өчен башка азык-төлек сатып алды. Акция дәвамында җыелган беренчел кирәк-ярак һәм азык-төлек 500 килограммнан артып китте. Татарстан Мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов фәләстыйнлеләргә ярдәм күрсәткән кешеләргә рәхмәт әйтте.

## Балтач районында төзекләндерүдән соң мәчет ачылды

Рабигыль-ахыр аеның 28нче көнендә (12нче ноябрьдә) Балтач районы Салавыч Сәрдегәне авылында яңартылган мәчет үз ишекләрен ачты. Мөселманнарының сөенечен Татарстан Мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Балтач районы башлыгы Рамил Нотфуллин, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел

исемендәге Казан мөселман мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин һәм башка башка кунаклар, иганәчеләр бүлеште.

Илфар хәзрәт Хәсәнов мәчетне төзекләндерүдә катнашкан иганәчеләр Финат Мөхәммәдиевка, Илнур Әхмәтҗановка, Наил Сафиуллинга һәм 1996 елдан имам-хатыйб вазифаларын башкаручы Ирек хәзрәт Әхмәдуллинга Нәзарәтнең рәхмәт хатларын тапшырды.

70–80 кеше сыйдырышлы гыйбадәт йорты 1995–1996 елларда төзелгән. 2021–2023 елларда төзекләндерү эшләре алып барылган: түбә һәм манара, мәчетнең нигезе яңартылган, идән-түшәмнәр, җылыту системасы алмаштырылган һәм тәһарәтханә ясалган. Мәчет каршында курслар эшли, Рамазан аенда ифтарлар үткәрелә.

## Казан Хәрби госпиталендә намаз уку бүлмәсе ачылды

Рабигыль-ахыр аенының 30нчы көнендә (14нче ноябрьдә) РФ Оборона министрлыгының Казан шәһәрендә урнашкан Хәрби госпиталендә намаз уку бүлмәсе ачылды. Әлеге чарада Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Хәрби госпиталь җитәкчесе подполковник Дамир Ижбирдеев, намаз бүлмәсе имамы Ирек хәзрәт Җиһаншин, госпитальдә дәваланучы мөселман кардәшләребез катнашты.

Госпитальнең беренче катында урнашкан 12 квадрат метрлы гыйбадәт бүлмәсе Камил хәзрәт Сәмигуллин хәер-фатыйхасы һәм Казан шәһәренең «Габдерәхим Утыз Имәни исемендәге Ал Таң» мәчете имамы Ирек хәзрәт Җиһаншин башлангычы белән булдырылган. Иганәчеләр ярдәме белән келәмнәр, намазлыклар, кирәк-яраклар сатып алынган, дини әдәбият тупланган. Биредә берьюлы 10 кеше намаз укый, дога кыла һәм үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап таба ала.

## Мөфти Фәләстыйн студентлары белән очрашты

Рабигыль-ахыр аеның 30нчы көнендә (14нче ноябрьдә) Галиев мәчетендә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казан шәһәренең югары уку йортларында белем алучы Фәләстыйн студентлары белән очрашты. Очрашуда барлыгы 18 егет катнашты, аларның 10сы — Газә секторыннан. Казанда Фәләстыйннан килгән 33 кеше яши, шуның 26сы — студент. Алар Казан (Идел буе) федераль университетында, Казан дәүләт медицина университетында, Казан милли тикшеренү технология университетында, Казан дәүләт энергетика университетында белем ала.

Камил хәзрәт аларның гозерләрен тыңлады, «Зәкят» фонды белән берлектә ярдәм оештыруның күздә тотылуын, һәр студентның яшәү шартлары, мохтаҗлыгы өйрәнеләчәген хәбәр итте. Студентлар укудан буш вакытта эшкә урнашу мөмкинлеге турында белеште, Фәләстыйн һәм Әл-Әкса мәчете тарихы буенча телевидение тапшырулары, вәгазь кичәләре оештырырга тәкъдим итте. Моннан тыш, мөфтият мәйданчыгында мөселман яшьләре белән төрле тематик очрашулар уздыру мөмкинлеге каралды. Очрашу ахырында һәр студент Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фондыннан азык-төлек җыелмалары алды.

## Казанның Киров һәм Мәскәү районнары мөхтәсибәтендә «Сөләйман» мәчете комплексы ачылды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 2нче көнендә (16нчы ноябрьдә) Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары мөхтәсибәтендә яңартылып салынган иман йорты — «Сөләйман» мәчете комплексы ачылды. Яңа мәчет бинасы ике ел ярым эчендә 2021–2023 елларда төзелде.

Мәхәлләнең сөенечен бүлешергә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, Мөфтинең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе, Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары имам-

мөхтәсибе Илдар хәзрәт Баязитов, дин әһелләре, абыстайлар, иганәчеләр, мәхәллә халкы һәм башка кунаклар катнашты.

Камил хәзрәт, мәчет салуның фазыйләтләрен искә төшереп: «Кем Аллаһы ризалыгы өчен мәчет төзесә яки катнашса, Аллаһы Тәгалә бу кешегә шундый ук сыйфатта җәннәттә йорт бүләк итәр», — диде. Ул әлеге мәчетнең үсеп килүче буында рухи-әхлакый кыйммәтләрне үстерүдә зур таяныч булачагына ышанычын белдерде. Мөфти мәчет комплексын төзүгә зур өлеш керткән хәйрияче Мәсгуть Латыйповның хәләл җефете Разия Еникееваны Нәзарәтнең рәхмәт хаты белән бүләкләде.

Әлеге комплекс мәчеттән һәм Ислам мәдәнияте үзәгеннән тора. Имам-мөхтәсиб Илдар хәзрәт Баязитов аңлатып узганча, «Сөләйман» мәчете динебезгә, милләтебезгә күп хезмәт кылучы мәчет булачак. Биредә 36 бала өчен тәхфиз (Коръән ятлау) курслары оештырылачак.

Рәсми чыгышлардан соң, барлык җыелган халык яңа бинага узды һәм мөфти Камил хәзрәткә ияреп, өйлә намазын укыды. «Сөләйман» мәчете — ике катлы, зурлыгы 1000 квадрат метрдан артып китә. Беренче катта 300 иратны сыйдырышлы намаз залы, гардероб, барлык уңайлыклары булган тәһарәтханәләр урын алган. Икенче катта 80 хатын-кызга исәпләнгән намаз уку урыны, төрле кабинетлар бар.

## Питрәч мөхтәсибәтенең Көек авылында икенче мәчет ачылды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 3нче көнендә (17нче ноябрьдә) Питрәч районы Көек авылында («Яңа Салмачы» коттедж бистәсе) «Фәрвәз» мәчете ачылды. Анда Татарстан Мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов, Питрәч районы имам-мөхтәсибе Габбас хәзрәт Шляпошников, эшмәкәрләр, мәхәллә халкы, башка кунаклар катнашты.

Әлеге мәчет яңа сафка баскан коттедж бистәсендәге дин кардәшләребез өчен күтеп алынган бүләк булды. Мәчет өчен җирне мәхәлләгә 2019 елда Рөстәм Әбзалов бүләк итә һәм шул ук елны мәхәллә ТР Юстиция министрлыгында теркәлү уза. Мәчет төзү эшләрен Хөсәен хәзрәт Кашапов оештырып җибәрә. 2021 елда төзелеш эшләрен алып бару өчен рөхсәт алына, бина күтәрелә, түбә ябыла. Мәчет иганәчеләр һәм халык ярдәме белән сафка баса.

## Казанда «Юмарт сишәмбе» бөтендөнья акциясе кысаларында бушлай автобус йөрде

Җөмәдәл-әүвәл аеның 14нче көнендә (28нче ноябрьдә), Казанда 30нчы автобус «Юмарт сишәмбе» бөтендөнья акциясе кысаларында иртәнге сәгать җидедән кичке җидегә кадәр шәһәр халкын түләүсез йөртте. Мондый бүләкне башкала халкына быел инде икенче тапкыр ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды ясады: ул барлык пассажирларның юл хакын түләде.

Беренче тапкыр мондый хәйрия акциясе Рамазан ае хөрмәтенә «Рамазан – изге гамәлләр ае» кысаларында узды: аны 800гә якын кешене җылылык белән кабул итте. Шуңа күрә фонд быел «Юмарт сишәмбе» бөтендөнья акциясенә кушылырга һәм гражданнарның игътибарын хәйриячелеккә җәлеп итәргә һәм башкаларны да саваплы гамәлләр кылырга этәрергә карар кылды.

Көн дәвамында «Зәкят» фонды вәкилләре әлеге хәйрия акциясе, «Зәкят» хәйрия фонды, Ислам диненең матурлыгы, күркәмлеге, саваплы гамәлләр башкару фазыйләтләре турында сөйләде. Бу көнне шулай ук qr-код ярдәмендә иганә кертергә дә мөмкин иде. 30нчы маршрут очраклы сайланып алынмаган: ул шәһәрдә иң озын маршрутларның берсе санала һәм анда халык һәрвакыт күп була. Бу маршрут Казанда иң озын маршрутларның берсе — ул Совет, Идел буе, Вахитов, Киров районнарын тоташтыра.



# Ураза гаете

*мөбарәк булсын!*